PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН 2020 ИЮЛЬ № 7

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

КҮЗЛӘРЕМНЕҢ
төсе үзгәрмәде
бер ярату тарихы

АБЬЮЗЕР
синең яныңда
кем?

меренгалы рулет
ЧИКЛӘВЕКЛЕ,
җиләк тәмле


Лилия
ГАРӘФИЕВА:
«Балалар терәк булса, үзе зур бәхет...»

75 ЖИҢҮ! 1945–2020

Хәтер – мәңгелек...

Бөек Җиңүгә миллионлаган гап-гади кешеләрнең каһарманлыгы бәрабәренә ирешә алдык. Алар арасында безнең татар егетләре, татар кызлары да байтак. Минем бабам, синеке, аныкы... Сугыш афәте кагылмаган, сугыш ишек шакымаган капка, гаилә калды микән? Җиңү таңы безгә шуңа да кадерле... Инде бу хакта бүгенге яшьләребезгә дә аңлатасы, төшендерәсе, күңелләрендә горурлык хисләре уятасы килә. Бу проект – шул хакта. Мондый ядкарьләр, бәлки, сезнең гаиләләрдә дә сакланадыр. Юк икән, аларны шушы сайттан табып алырга мөмкин: https://pamyat-naroda.ru. Бабаларыгызга орден-медальләр ни өчен бирелде икән? Балалар, оныклар белән бергә утырып эзләп карагыз әле. Әлеге тарихи документларны үз күзләре белән күргәч, Җиңү сүзенә алар инде берничек тә битараф калалмас...

Табышларыгызны безнең белән дә уртаклашыгыз. Хатларыгызны көтәбез.




Соңгы хат

Әнинең сандыгын актарганда, кечкенә генә дәфтәр битенә гади карандаш белән гарәп хәрефләрен тезеп язылган хат килеп чыкты. Бу – фронттан килгән әти хаты! Эх, укыйсы иде моны. Әтием Гаязов Галләм 1940 елның җәендә фин сугышына алынганда миңа бары яшь ярым гына булган. Телем дә ачылмаган, «әти» сүзен дә әйтә белмәгәнмен. Аннан Бөек Ватан сугышы башланган. 1945 елның 2 февраленә кадәр сугышкан әти. Батыр артиллерист-наводчик булган, «За отвагу» медале белән бүләкләнгән. Менә 54-нче укчы дивизия приказыннан өзек: «За период Отечественной войны тов. Гаязов, стреляя прямой наводкой, разрушил 10 ДЗОТов со станковыми и ручными пулеметами и истребил 27 белофиннов». Үлеменнән бер көн элек язылган хатында да: «Армый-талмый дошманны үз җирендә куып, хур итеп алга барабыз», – диелгән. Үзем укыдым бит бу юлларны!

Әнием Әминә буй-сынга да, төс-биткә дә төшеп калганнардан түгел, эштә дә бик уңган иде. Мине кайната-кайнана белән тәрбияләп, азмый-тузмый гомер кичерде. Сүз кушып караучылар да булгандыр, ә ул кузгалмады. Кайвакыт үзем дә: «Ник болай ялгыз яшәде икән?» – дип уйлап куя идем. Моның да җавабын хаттан таптым. Шул кечкенә генә хатта дүрт урында «бәгърем» сүзе кабатлана. Күрәсең, әнинең йөрәгендә әтинең соңгы хатында: «Түз, бәгърем! Тиз көндә, сау булсак, Аллаһ кушса, гомер булса, кайтырбыз. Хуш, бәгърем» сүзләре мәңгегә урын алган. Константин Симоновның «Жди меня и я вернусь» юллары – һәр солдат хатының күңелендә. Көтмәдекме соң, бик көттек... Гаяз бабай да, Хафаза әби дә, әнием белән мин дә. Алар барысы да ахирәт тормышына күчте, мин дә 82 яшьтә. Гомеремдә «әти» дип әйтергә кешем булмады. «Син кайтмадың киткән җиреңнән...»

Сәет ГАЯЗОВ,
Казанның Дәрвишләр бистәсе «Ислам» мәчете мөәзине.



СЕКРЕТНО
Экз. № 2

114


ПРИКАЗ
По 86 Артиллерийскому полку 54 Стрелковой Дивизии
11 Июня 1943 года
№ 037

От имени Президиума Верховного Совета Союза ССР, за образцовое выполнение боевых заданий командования на фронте борьбы с немецкими захватчиками и проявленное при этом доблесть и мужество НАГРАЖДАЮ:

Медалью «ЗА ОТВАГУ»

1. Наводчика 1 батареи-младшего сержанта ГАЯЗОВА Гаяз Шарафутдиновича за то, что он при выполнении боевой задачи по захвату разведгруппой безымянной высоты в районе Кис-Кис /кв.4404-б/ 30 Мая 1943 года проявил себя, как одного из мужественного бойца. Под непрерывным обстрелом артиллерией противника огневой позиции батареи, на которой находился Гаязов, он не прекратил вести огонь ни на одну минуту. Быстротой и точной наводкой он дал возможность разведгруппе выполнить поставленную боевую задачу с наименьшими потерями. В этом бою он благодаря смелости и хладнокровия в работе, точности своего огня уничтожил 15 белофиннов и подавил огонь станкового пулемета, мешающий продвижению нашей разведгруппе. За период отечественной войны тов. Гаязов стреляя прямой наводкой разрушил 10 ДЗОТ-ов со станковыми и ручными пулеметами и истребил 27 белофиннов.

1918 года рождения, кандидат в члены ВКПб с 1943 года, татарин, призван в РККА Чкаловским РВК Чувашской АССР, домашний адрес: [illegible]



Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Тышлыкта:
Лилия Гарәфиева
Фото: Анна Арахамия

Верстка:
Резеда Галиуллина
Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 19.06.2020 ел.
Заказ А-1439
Тираж 4850

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



Фото: Анна Арахамия

Баш мөхәррир сүзе



Без журналистларның һәр елы икегә бүленә: беренче һәм икенче яртыеллыкка. Тормышыбызның шундый бизмәнгә салып үлчәнү сере бик гади: ярты ел саен абунәчеләр кампаниясе уза. Яңа гына тагын шул чикне уздык менә... Журналның бу санын кулга алучылар арасында тугрылыклы укучыларыбыз байтактыр. Әмма, һичшиксез, яңалары да өстәлгәндер дигән өметтә мин!

Ә беренче яртыеллык җиңел булмады. Чөнки... Көннәрдән бер көнне без төштәге сыман башка дөньяда яши башладык: урамнар буш, сәүдә үзәкләре эшләми, самолетлар очмый... Табибларыбыз гына хастаханәләрдә көнне төнгә ялгап эшли... Бу чор безне үзгәртәчәк. Беренчедән, ниһаять, табиб хезмәтенең авырлыгын, җаваплылыгын, фидакарьлеген аңладык.


Икенчедән, кинәт уянгандай, яныбыздагы мохтаҗларга игътибар итә башладык. Моңа мисаллар бик күп. Шуларның берсен сезнең белән дә уртаклашасым килә. Бер ир волонтерлар оешмасына язылырга тели, әмма аны чиратка фәлән меңенче итеп теркиләр. Озак көтә ул, ә чират һаман җитми дә җитми. Бер көнне ул мәрхүм әнисенең телефон дәфтәрен табып, ахирәтләренең барысына да шалтыратып, исәннәрен барлап чыга. Һәм... даими рәвештә аларга азык-төлек илтә башлый. Әбиләрдән акча алмас өчен: «Миннән түгел, хәйрия оешмасыннан», – дип әйтә.

Тагын... Бу катлаулы көннәрдә үзебез өчен интернетның бик күп яңа мөмкинлекләрен ачтык. Баксаң, байтак эшне онлайн да башкарырга мөмкин икән. Без дә май һәм июньне – махсус саннарыбызны (ә алар, гадәттә, аерым җаваплылык белән әзерләнә!) өйдән эшләп әзерләдек. Геройларыбыз белән дә онлайн «очраштык». Күзгә-күз карап аралашуга җитми инде, әлбәттә... Әмма тырыштык, һәрвакыттагыча, сезгә булган бөтен яратуыбызны кушып эшләдек.

Шагыйрь Ләбиб Леронның хәләл җефете Фидания ханымның инстаграм битендә *#тормышдәвамитә* дигән хэштег бар. Әйбәт хэштег...

Тормыш дәвам итә. Барысы да әйбәт булыр!

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА



Безнең тышлыкта



«Шөкрана кылып, үткәннәрне хөрмәт белән искә алып, алга карап яшим...»

14 «Ышан миңа...»
Чулпан Галиәхмәтова

Заман һәм без

6 Абьюзер
Чулпан Галиәхмәтова

Өмет катыш көтү
Раилә Хәялиева
10






20 Алҗыган әни халәте
Раилә Хәялиева

Татар дөньясы



24
Димче диңгез кичерер
Айгөл Минһаҗева

28
Чирмешәннең балта остасы
Лилия Гәрәева



Яшәеш



44
Сыгылганнар гел сынмый
Гөлнур Сафиуллина

48
Күзләремнең төсе үзгәрмәде...
Фәния Сәетгәрәева

54
Зәңгәр шәһәр
Раушания Полосина-Сөләйманова



Мәдәни тормыш



38
Куен җылысы
Камил Кәримов

Хуҗабикә



60
Меренгалы рулет

АБЬЮЗЕР

Еланның агуы – тешендә, адәмнеке – телендә, диләр. Ә ул агу бөтен назыңны, бар җылыңны бүләк иткән якын кешең теленнән тамса? Аның һәр әйткән сүзе йөрәккә хәнҗәр булып кадала икән, күңел көчсезләнә, яшәүнең яме югала, ахыр чиктә, өметеңне өзәргә мөмкин. Өйдәге золым турында бик күп сөйлиләр. Гомерен өзгән, кул күтәргән дигән хәбәрләр еш ишетелә. Болары фаҗига итеп кабул ителә. Сүз белән гайрәтләнеп яшәүчеләр дә бар бит әле. Юк, алар бармак белән дә чиертмиләр, бары тик сүз белән кыйныйлар. Һәм, нигездә, моны хатын-кыз ялгызы гына күтәрә. Эндәшми. Түзә. Бу – олы бер фаҗига. Көн саен дәвам иткән психологик һәм эмоциональ басым бервакыт кешелектән чыгармый калмый. Бу дөньяда һәр кеше – шәхес. Шәхеснең үз дөньясы, үз чикләре бар. Ул чикне беркем дә таптап керергә тиеш түгел. Хәтта бик яраткан кешеңнең дә моңа хокукы юк...



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА




Фото: www.pixabay.com

Хокуксыз хатын-кызлар

«Мин өйдә мебель...» Һәрвакыт үзен карап, брендлы киемнәр киеп, соңгы модельле машинада йөргән танышымнан шундый сүз ишеткәч, бер мәл аптырап калдым. Читтән карaганда, тормышы күпләр көнләшерлек югыйсә. Бернәрсәгә интегеп яшәми кебек. Тик интегә икән шул... иреккә. Ул һәрвакыт өйдә булырга тиеш. Шәһәр үзәгендәге кыйммәтле спортзалга барып шөгыльләнгәннән

соң да, андагы таныш хатыннары белән каһвә эчәсе түгел, туры өйгә йөгерәсе. Институт тәмамлап кияүгә чыккач, беренче баласы туганчы үз һөнәре буенча эшли әле ул. Соңыннан моңа чик куела. «Син өйдә балалар янында булырга тиеш», – ди аңа ире. Балалары үсеп итәктән төшкәч тә, эшкә чыгарга талпынып карый. Тик ире бу хакта ишетергә дә теләми. «Тәҗрибәң юк, син өйдә генә утырырга тиеш», – ди. Аның бернәрсәгә хокукы юк, балаларны кайсы мәктәптә укытуны хәл итү түгел, ялгызы гына кибеткә барып үзенә күлмәк тә сайлый алмый. Барысын да ир контрольдә тота. Каршы сүз әйтү турында уйларга да ярамый. «Син нәрсә күргән соң, бөтен эшең минем муенда утыру», – дигән шелтә сүзләрне кабат ишетәчәк. Хәер, моны ишетергә әллә ни сәбәп тә кирәкми. Ире аны болай да бу сүзләр белән еш «иркәли». Иргә финанс бәйлелеге булгач нишләсен инде, диярсез. Ләкин тагын бер очрак китерәсем килә. Янып торган, тормыш йөген үзе тарткан хатын. Эшли, акчасын таба, нәрсәгә тотынса, шуны булдыра. Һәркем белән уртак тел таба. Ә менә ире каршында коела да төшә. Юктан гына тавыш чыгарган булдыксыз иренә каршы бер сүз әйтә алмый. Нинди генә яман сүзләр ишетми уңган хатын! Барысына да түзә: кара тавыш кына чыкмасын да, ире кул гына күтәрмәсен, балалары гына атасыз үсмәсен. Бөтен курыкканы шул. Кычкырып алҗыган ире соңыннан тагын аны гаепләп куя: эндәшмәскә иден, күрәсең бит, кәефем начар, янәсе. Һәрвакыт хатын гаепле. Өйдә бу инде – канун. Үзгәрер дип өметләнеп яши хатын. Тик үзгәрерме соң?..

«Тау югалды дисәләр ышан, кеше холкы үзгәрде дисәләр ышанма»

«Бу хатыннар психологик абьюзерлар корбаны», – ди «Сердәш» хезмәте психологы Гүзәл Хөснетдинова. Абьюзер: abuse – көчләү, abuser – көчләүче кеше дигән сүз. Өйдәге золым хакында сөйләгәндә еш кулланыла. Психологик абьюз да – көчләүнең бер төре. Абьюзер манипуляцияли, куркыта, эмоциональ басым ясый, гомумән, корбанына психологик зыян сала.



«Сердәш» хезмәте психологы Гүзәл ХӨСНЕТДИНОВА:
«Абьюзер: abuse – көчләү, abuser – көчләүче кеше дигән сүз. Ул якын кешеләрен мыскыл итә, кимсетә, мәсхәрәли...»

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы күрсәткечләренә караганда, кешеләрнең 75 проценты мөнәсәбәтләрдә бу проблема белән очраша. Моны һич тә норма итеп кабул итәргә кирәк түгел. Ул гаиләдә икән, аның бик еш кабатлануы көн кебек ачык. «Иреннән гомер буе сүз белән мыскыл ителеп яшәгән хатыннар күп, – ди психолог. – Алар каядыр барып киңәш сорарга ояла, хәер, барыр урын да юк».

Ирем мине кыйный дип полициягә мөрәҗәгать итүчеләргә дә әллә ни ярдәм итәргә ашкынып тормыйлар. Ирем миңа психологик басым ясый дип килсәң, чигә турында бармак бөтерергә дә мөмкиннәр, чөнки безнең җәмгыятьтә ул проблема буларак кабул ителми. Ир эчми, сукмый, читкә йөрми, өйгә акча алып кайта икән, башкалар өчен ул идеаль. Әмма кеше күңеле – кара урман. Ир белән хатын мөнәсәбәтләре дә шундый ук урман. «Бездә психологик белем бик түбән дәрәҗәдә. Чикне белмиләр. Мәсәлән, ирең белән чия-пычак килеп талаштың ди. Бу психологик абьюзмы, әллә инде югары тонга күчеп аңлашумы? Моны тәгаен әйтә алмыйлар», – ди Гүзәл Хөснетдинова. Белгечләр исә бу чикне аера белә. Кәефе начар булып, ир хатынын кимсетә икән, үз гаебен таный һәм, билгеле, гафу үтенә. Әйе, абьюзер да гафу үтенә, ләкин бар гаепне хатынына ташлый: эндәшмәскә идең, яныма килмәскә идең... Гадәти конфликтлар нинди дә булса бер сәбәп аркасында чыга: ремонт, тормышка планнар кору йә каядыр бару... Уртак фикергә килә алмаганда югары тонга күчкәнне үзебез дә сизми калабыз. Ә абьюзерлар кечкенә генә бер сәбәп өчен дә уттай кабына. Помаданың төсен, юыну бүлмәсендәге юеш сөлгене, ашның тозлырак булуын да тормыштагы иң зур хатага әйләндереп, бала-чаганы әрләгән кебек шелтәләп ташлаячаклар. Алар бервакытта да үзләрен гаепле итеп тоймый. Җитмәсә, бик яхшы манипулятор үзләре. Гади итеп әйтсәк, үз сүзләрен сөйләп, үзенекен эшләтәләр. Барысы өчен дә хисап таләп итәләр: кая барасың, нишлисең, күпме акча тотасың... Һәм иң кызыгы – хатын-кыз моңа ияләшә, норма итеп кабул итә башлый.

Битлекле ир-ат

Абьюзерлар хатыннарын ничек кенә мыскыл итеп, юкка чыгарсалар да, аерылып китмиләр, чөнки болай яшәү рәхәт һәм уңайлы. Корбаннарына караганда әхлакый һәм психологик яктан көчсезрәк алар. Эчәк паразиты кебек, янәшәләрендә үзләреннән көчлерәкләр булганда гына яши алалар. Тик моны бервакытта да сиздермиләр, бәлки, белмиләрдер дә. Алар үзләре турында бик югары фикердә. Җитмәсә, алдакчылар. Булачак ярыңның абьюзер булу-булмавын никахны рәсмиләштергәнче белергә була. Сөйләүләренә караганда, алар дөньядагы иң яхшы кешеләр. Элек йөргән кызлары начар, тиле, барысына да үзләре гаепле булган. Бу инде маяк булырга тиеш. Психолог әйтүенчә, абьюзерлар әйләнә-тирәдәгеләргә бик яхшы тәэсир тудыра: һәрвакыт пөхтә, энәдән-җептән киенәләр, матур сөйләшәләр, романтиклар.

Шуңа да яши башлагач кисәк кенә үзгәрүләрен аңлап бетереп булмый. «Ул бит шундый романтик иде!» – дип аптырыйлар. Күрәсең, болар барысы да битлек. Яулауның кирәге калмагач, битлекләрен салып аталар.

Гаиләдә тыныч мыскыл итү алымы да бар әле: дәшмәү! Бу – манипуляциянең иң киң таралган очрагы. Кайта, син әзерләгән ризыкны капмыйча, үзе әзерләп ашый. Нидән канәгать булмавын аңлатмый. Хәтта күтәрелеп тә карамый. Ир бу алымны еш куллана икән, димәк, абьюзер. Кеше алдында мыскыллап көлү, сүз белән чеметеп, төртеп алу да абьюзерлык сыйфаты. Бернинди зыянсыз, бар кешегә дә көлке булган әйбер түгел инде бу. Мәзәк ул бөтен кешегә дә көлке булганда кызык. Ә бер кеше көлдергәндә икенчесе уңайсызлана икән, бу инде психологик басым, чөнки ул кешенең үзенә карата булган бәясе какшый. Абьюзерларның төп максаты әнә шул инде: партнерның бәясен төшерү, аны мескен хәлгә калдыру. Шуңа да алар игелекле, конфликттан курыккан, сабыр, үзләрен һәрвакыт икенче планга куйган кешеләрне сайлый. Корбаннар, сабыр итеп, шундый халәттә яшәргә күнегә. Китәм дип әйтә башласа, психологик көчләүче бөтенләй башка кешегә әверелә: чәчәкләр алып кайтып, тезләнергә дә мөмкин. Үзгәрде бит дип, ничәмә-ничә тапкыр алданып яши хатын-кыз. Тик еллар үткән саен, мондый гафу үтенүләр бетәчәк. «Үзгәрмәячәк тә! Чөнки абьюзер холкында психопатларда булган сыйфатлар бар. Аларда эмпатия, жәлләү, хәлгә керү дигән әйбер бөтенләй юк», – ди психолог. – Миңа үзгәрергә кирәк дип уйлап та карамыйлар, чөнки шулай уңайлы. Ә менә аларның корбаннарына бердәнбер ярдәм кулы сузучы – психологлар.

Гүзәл Хөснетдинова әйтүенчә, ярдәм сорап килүчеләр аерылырга теләми. Һич юк. Психологка килгән икән, партнерын аңларга, мөнәсәбәтләрне үзгәртеп, яңа тормыш башларга тели. Даими стресста яшәгән әлеге хатын-кызларга психологлар иң элек үз бәяләрен күтәрергә ярдәм итә. Аларга тынычлану өчен стресс чыганагыннан китеп торырга кирәк.



«Фатыйма» хатын-кызлар кризис үзәге җитәкчесе Марина ГАЛИЦКАЯ: *«Җәмгыятьтә хатын-кызларга карата дискриминация балалар бакчасыннан ук башлана».*

Авыр чакта ата-ана янында бераз ял итеп алу комачау итмәс. Психологик абьюзерлар белән яшәгәннәрнең, гадәттә, тирә-ягында беркем булмый, чөнки аларга аралашырга мөмкинлек бирелми. Психологлар иң элек сине аңлаган, тыңлаган кешеләр мохитен булдырырга киңәш итә. Аек акыл белән уйлап, партнерның мыскыл итү сәбәбен ачыклау, аннан көчлерәк, акыллырак икәнеңне аңлау мөһим. Балалар хакына!

– Өйдәге мөнәсәбәтләрне күреп үскән балалар, нигездә, әни яклы була. Ләкин ата тарафыннан булган негатив тора-бара аларга да күчә, һәм тормыш кора башлагач, бу психологик проблемага әйләнергә мөмкин. Ә иң куркынычы: эти кеше үрнәгендә әниләрен мыскыл итеп, рәнҗетеп яшәргә дә мөмкиннәр. Балалар – хатын-кызга үзгәрү өчен менә дигән мотивация, чөнки бар ана да балаларның бәхетле булуын тели, – ди Гүзәл Хөснетдинова.

Үз бәяңне күтәреп, абьюзер белән катгый итеп позицияләреңне куеп сөйләшә башлагач, ул власте бетүен аңлаячак. Абьюзер белән кешечә аңлашып булмаганын төшендегез инде. Монда сугыштагы кебек тактика һәм стратегия кирәк!

Психологик басымның иң куркыныч төре – газлайтинг. Әлеге термин безнең тормышка кереп бара. Димәк, ул кайчан да булса проблема буларак күтәреләчәк. Әлегә бу хәлдә дә хатын-кызлар ялгызы кала. «Газовый свет» инглиз пьесасыннан алынган бу сүз психологик көчләүнең бер формасы. Һәм үтә куркыныч формасы. Ул, нигездә, кул күтәрү, җенси көчләү белән бергә алып барыла. Абьюзерның максаты: корбанын психик яктан нормаль булмаган итеп күрсәтү, чынбарлыкны адекват кабул итүдә шикләнү тудыру. «Бу бик авыр очрак, – ди Гүзәл Хөснетдинова. – Һәрвакыт җүләргә чыгарган саен, корбан үзенең җүләр булуына ышана башлый. Үзендә шикләнә. Монда инде психосоматика килеп чыга: корбан авыруга әйләнә. Ә авырулар – өйдәге сәламәт булмаган мөнәсәбәтләрнең нәтиҗәсе ул».

Кая барыйм?

Күпләр гаиләдәге психологик басымны колагыннан тартып үстерелгән проблема дип кабул итә. Хатын-кызларны артык иркә, инфантиль булуда гаеплиләр. Әмма бу проблема бар. «Фатыйма» хатын-кызлар кризис үзәге җитәкчесе Марина Галицкая әйтүенчә, кайнар элемтәгә шалтыратучыларның 40 проценты физик көчләүдән зарланса, 4 проценты психологик көчләнүдән җәфа чигә. Бик кечкенә сан диярсез, күпләр тыныч кына басылып яшәвен дәвам итә. Бу 4 процент әлеге проблема үзәгенә үтеп, алга таба яшәргә өмет югалтканнар түгел микән?!

– Үзәккә мөрәҗәгать итүчеләр, нигездә, эшләп акча табучы хатын-кызлар, – ди Марина Галицкая. – Финанс бәйлелектә булу абьюз мөнәсәбәтләргә сәбәп дип әйтмәс идем. Психологик көчләүчеләр нигә синең итәгең кыска дип тә бәйләнә башлый. Мондый авыр хәлдә калган хатын-кызлар психологка гына мөрәҗәгать итә ала. Татарстанда аларга ярдәм итә торган оешмалар юк. Дөрес, хәйрия нигезендә эшләүче берничә приют бар. Тик анда балалы хатын-кызларны гына кабул итәләр.

Авыр хәлдә калган хатын-кызларны канат астына алырлык сак хезмәте булган дәүләт приютлары булырга тиеш. Ә дәүләттән моны финанслау өчен иң элек махсус канун кирәк. Өйдәге золым буенча канун проекты әлегә кадәр эшләнеп бетмәгән.

Нигә хатын-кыз корбан?

Статистика буенча, өй золымчыларының 90 проценты ир-атлар. Җәмгать эшлеклесе, «ФемКызлар» активисты Тасиа Альбариньо фикеренчә, күп очракта нәкъ менә хатын-кызларның психологик абьюз корбанына әйләнүенә җәмгыятьтәге стереотиплар сәбәпче булып тора.

– Чын ир-атлар әйдәп баручы булырга тиеш, аларга пар чыгарырга кирәк, ә хатын-кызлар зирәк, сабыр, шул ук вакытта ир-атның ачуын чыгармыйча, аны рухландырып яшәргә тиеш дигән сексист фикерләрнең бөтен мәкерлеге дә шунда: алар безгә бик кечкенәдән үк иррациональ дәрәҗәдә түгел, ә эмоциональ дәрәҗәгә салына һәм, әлбәттә, киләчәктәге эш-гамәлләребезгә тәэсир итми калмый. Бу нормалар күп очракта психологик абьюзны гадәти хәл итеп кабул итәргә җирлек бирә. Ирнең даими рәвештә контрольдә тотуын, аралашу мохите сайлавын абьюз дип түгел, ә аның кайгыртучанлыгы дип уйлыйбыз. Җитмәсә, әле шуны романтикалаштырабыз. Бу безнең төп хатабыз», – ди ул.

Тасия әйтүенчә, безнең җәмгыятьтә әлеге проблема артык күтәрелми, чөнки корбан хатын-кыз тешен кысып, түзеп яши. Ә чүпне читкә чыгармыйм дип яшәү гомер бәһасенә торырга мөмкин.

Абьюзер хатын-кыз буламы?

Гаделлек өчен шуны да язарга кирәктер: җәмгыятьтә бик аз булса да хатын-кыз абьюзерлар да бар. Аларны анекдотлардагы кебек, чәченә бигуди куйган, кулына уклау тотып, җебегән иренең эштән кайтуын көткән йөз килограмм авырлыктагы хатын-кыз итеп күзаллау дөрес булмас. Көләч, укымышлы, сарказмга ия, заманча, карап торышка бернинди зыян сала алмаган хатын-кызлар алар.

Психолог Гүзәл Хөснетдинова: «Бу проблема белән ир-атлар да мөрәҗәгать итә», – ди. Дөрес, алар, хатыным миңа эмоциональ басым ясый дип зарланмый, ә гаиләне саклап калу өчен ярдәм сорап киләләр. «Бер клиентым бар иде, – дип сөйли психолог. – Өйләнешкән вакытта хатыны, егермешәр тапкыр эшенә шалтыратып, аны гел контрольдә тоткан. Ахыр чиктә, хатын-кызлар карап утырасың дип, телевизор караудан тыйган. Көнчелек тә абьюзга әйләнергә мөмкин. Әгәр партнерың ирегеңне кысса, тормыш рәвешеңне үзгәртергә теләсә, ышанычы булмаса, үз милке итеп караса, бу инде психологик көчләү дигән сүз. Хатын-кыз эмоциональ көчләүче булган гаиләләрдә бала тугач вазгыять тагын да катлаулана. Ул ирен бала белән шантажлый башлый. Бик сирәк очракта гына ир-ат түзеп яши. Йә ул гаиләдән китә, йә аракы белән дуслаша».

Мондый мөнәсәбәтләрдә шагыйрьләр мәдхия җырлаган саф, чиста мәхәббәт юк. Дөрес, үрмәкүч тә пәрәвезенә тотылган чебенне ярата. Тик бу башка төрле ярату. Ул аның исәбеннән үз мәнфәгатен генә кайгырта. Мәхәббәткә салынган хөрмәт, аңлау, гафу итү, зыян салырга, борчырга теләмәү кебек төшенчәләр абьюз мөнәсәбәтләрдә була алмый. Гарип күңелле кешеләр өчен ул бары тик декорация генә. Ә алар янәшәсендә алданып, мыскыл ителеп, өметләнеп яшәгәннәр бик көчле кешеләр. Кызганыч, бу хакта үзләре генә белми...

КАЙДАН КИЛӘ МОНДЫЙ ЯВЫЗЛЫК



Лилия МИҢНЕТДИНОВА, Казан дәүләт медицина академиясенең психиатрия һәм суд-психиатрия кафедрасы доценты, медицина фәннәре кандидаты, психиатр.

Бик авыр холыклы кеше, энергетик вампир. Аларны ничек кенә атамыйлар. Соңгы вакытта «абьюзер» дип әйтә башладылар. Ир-ат та, хатын-кыз да абьюзер була ала. Алар якыннарына төрлечә негатив тәэсир ясый. Ир-атлар күпчелек очракта абьюз көчләүнең барлык алымнарын да кулланса (психологик, физик, җенси), хатын-кызлар психологик басым гына ясый.

Ник соң кешеләр абьюзерга әйләнә? Бу авыр психик үзгәрешләр нәтиҗәсендә барлыкка килергә мөмкин. Шулай ук ул психик тайпылышлы кешеләрдә дә сизелә. Аны «холык үзенчәлеге» дип атыйлар. Кечкенә чакта баланың эчке дөньясына һәм аңына ата-анасы җимергеч тәэсир ясаса, кеше психик яктан сәламәт булып үссә дә, көчләүчегә әйләнергә мөмкин. Абьюз мөнәсәбәтләр булган гаиләдә тәрбияләнгән бала, үскәч, шул сыйфатларны үз тормышына күчерергә мөмкин.

Психологик яктан имин булмаган гаиләләрдә тәрбияләнгән балалар төрле комплекслар белән үсә. Ярату җитмәгән балаларның үз бәясе түбән, психологик яктан да тотрыксыз була. Агрессивлык, тиз ярсып китү, власть ярату, үзен кулда тота алмау, кансызлык, башкаларга ышанмау, алдашу кебек сыйфатлары барлыкка килә. Социаль норма һәм кагыйдәләрне боза, башкалар белән үзен бик тәкәббер тота. Болар барысы да абьюз тәртип формалашуга сәбәпче булырга мөмкин.

Баланы, максатларыңа ирешү өчен, кешеләрне манипуляцияләргә кирәк дип тәрбияләү дә дөрес түгел. Гаебен таный белмәү, эмоциональ салкынлык киләчәктә абьюз мөнәсәбәтләр тудыруга җирлек булып тора. Абьюзерлык холык һәм нәселдәнлектән килә. Әхлаксыз тәрбия, мохит моны ныгыта гына.



ӨМЕТ КАТЫШ КӨТҮ

Раилә ХӘЯЛИЕВА

Каршымда җиде катлы таш бина. Тәрәзәләрендә батып баручы июнь кояшы чагыла. Госпиталь каршында басып торам. Бу – без әле кайчан гына аш бүлмәсендәге телевизордан ишетеп белгән Covid белән көрәш мәйданы. Алгы сызык. Үлем белән күзгә-күз. Һәр икенче мизгелдә үзләре дә пациентка әйләнергә мөмкин икәнлекләрен белгән табиблар хәтәр вирус белән көрәшә. Ул безгә зур тизлек белән килеп җитте. Никадәр ваемсыз булуыбызны искәртте. Госпиталь тәрәзәләрендә тоныклык кына утлар яна. Битлек, махсус костюм кигән табибларның узып йөргәне күренә. Кайберәүләр, әнә, ишек төбенә һава суларга чыккан. Тормышны икегә аерып торган ишекләрне ачып теге якка узарга хакым да, рөхсәтем дә юк минем (язмасын да!). Якындагы сукмактан битлекләрен ияк астына төшереп кигән битараф кешеләр уза. («Вирусның барлыгына ышанмыйм!» «Безгә тимәс әле!» «Мин сакланмаганнан гына берни дә булмый!»...) Бу якта – кояш, чәчәкләр, яшеллек, ә диварларның теге ягында байлык һәм ярлылык, картлык һәм яшьлек төшенчәләрен аямаган, күңелләргә курку булып кереп урнашкан коронавирус газабыннан җан тартышучылар. Әйләнә-тирәдәге һавада ук куркыныч эленеп тора сыман. Шомлы сирена тавышлы ашыгыч ярдәм машинасы килгәне күренә. Руль артында утырган абзыйдан башлап, машинадагыларның һәрберсе саклагыч махсус костюмнардан. Кемнең кем икәнен аерып булмый. Мондагыларның миссияләре уртак – гомереңне куркыныч астына куеп булса да, үз теләгең белән башкалар тормышы өчен көрәшү...

Казанда һәм башка шәһәрләрдә коронавирус йоктырган кешеләрне дәвалау өчен махсус мәйданнар булдырылды. Аларның эшчәнлеген яңалыклардан күзәтеп, барлап барабыз. Моңа чаклы бер-берсен белмәгән, күрмәгән медицина хезмәткәрләре, бергә тупланып, вирус белән көрәшкә чыкты. Яңа режимда эшләү, үз тәҗрибәң аша дәвалау чараларын табу, барысын да яңадан башлау... Табиблар монда эшкә килеп кенә китмиләр. Алар монда яши. Бер атна, ике, өч... бер ай, ике... Биредә алар барысы да бертөрле – махсус саклагыч костюмнан, шлем, битлек, перчатка, күзлектән. Аркаларына кара маркер белән язылган исемнәр генә аерыла. Безнең героебыз – Covid белән беренче көннән үк алгы сызыкта көрәшүче табиб-инфекционист, егерме ел эш тәҗрибәсе булган Илдар Газим улы ИДРИСОВ.
Күргәннәре, кичергәннәре, тәҗрибәсе – аның пандемия чоры көндәлегендә.

ГЫЙНВАР

...Һәр яңа елны яңача булыр дип көтәбез. Табибларны да бу елда яңалык көтеп торган икән. Кытайда яңа вирус барлыкка килгән дип кисәтәләр. Коронавирус. Юк, мин моны алай ук яңа димәс идем. 2000 һәм 2012 елларда Көньяк-Көнчыгыш Азия илләрендә күтәрелеп алган вирус. Ул вакытта да үпкә ялкынсынулары, үлем очраклары белән узган, әмма киң таралмаган. Өченчесен туктатып кала алмаганнар менә. Әлегә Кытайны күзәтәбез, бу темага төрле материаллар укыйбыз. Безгә килеп җитмәс әле дип уйлыйбыз.

ФЕВРАЛЬ

...Коронавирус Европаны «яулый». Бездә дә укулар оештырдылар. Табиблар куркыныч тудыручы һәр яңалыкны алдан белеп торырга тиеш. Безгә килеп җитмәс дигән өметне бер дә югалтасы килми. Мөмкин булганча коронавирус турында барлык мәгълүматны кулга төшерергә тырышабыз. Бездә әлегә авыручылар юк. Чит илләрне күзәтәбез. Дөнья буйлап нинди генә чирләр, эпидемияләр йөрми, монысына да дәва табылыр кебек. Медицина дөньясында яңа чирләр турында ишетеп, белеп тору гадәти хәл.

МАРТ

...Дөньяда ниндидер киеренкелек сизелә. Коронавирустан үлүчеләр турында сөйли башладылар. Чит ил табибларының тәҗрибәсен карап, күзәтеп барабыз.

...Азия, Европа... Вирус акрынлап безгә якынаерга мөмкин... Шундый фаразлар өчен сәбәпләр җитәрлек. Укулар бара. Коронавирусны йоктыручылар белән эшләү ысулларын өйрәнәбез.

...«Бездә дә бар» дигән беренче мәгълүмат яңгырады. Өметләр акланмады... Нәрсәгә әзер булырга – әлегә аңлашылмый. Киләчәк үзе күрсәтер.

АПРЕЛЬ

...Тормыш көтмәгәндә кискен борылыш алды. РКБның Травматология үзәге коронавирус белән авыручылар госпитале итеп үзгәртелде, һәм тиз арада алдынгы белгечләрне җыеп, команда тупланды. Минем дә яңа эш урыным шунда хәзер – шәһәр читендә. Кизү торабыз. Эшчәнлеген минем кебек үзгәрткән табиблар күп монда. Вакытлыча госпитальгә әйләнгән Травматология үзәге яңа эш режимына җайлаша.

...Бүген «массовое поступление» булды. Үпкәләре шешеп авыручы олы яшьтәге кешеләрне китерделәр. Мазоклар алып, РКТ ясап тикшердек. Тыгыз эш көне...

...Кичәге анализларның күбесе уңай булып чыкты. Көтмәгән идек сине, вирус! Килеп җитмәс дигән ышаныч курку йомгагына әйләнә бара. Әйе, табиблар да курка. Аек акылы булган һәркемгә курку хисе хас. Чөнки син билгесезлекне дәвалыйсың.

...Улларым Нияз белән Наилгә минем өйдә булмавымны әниләре җайлап аңлатыр әле. Өйгә кайтмаска, әлегә гаиләдән аерым яшәргә булдым. Олы яшьтәге әнием дә бар. Вирус ияртеп йөрисем килми. Эш тә тыгыз: иртәдән

Һәр вирус мутациягә сәләтле, аның кайчан, ничек үзгәрәсен беребез дә белми.

кичкә кадәр авырулар янында. Госпитальдә койкалар күплегенә гаҗәпләнгән идем, бик тиз тулдылар...

...Коронавирусны берничек тә фаразлап булмый. Ул шуның белән куркыныч та. Организмга кергән вирус һәр органга, системага зарар сала. Ис, тәм тоемлау юкка чыга, үпкәләргә зыян килә, сулыш алу кыенлаша, температура күтәрелә. Башта хәл җайлашкан кебек була да, аннан кисәк тагын авырлаша. Вирус бер кешедән икенчесенә бик җиңел күчә. Кешеләрнең тиешенчә сакланмавы шуңа куркыныч тудыра да.

...Госпитальгә иң әйбәт белгечләр җыелган. Хирург, онколог, невропатолог, терапевт... Коронавирус кына түгел, бирегә бит гомер буе җыелган авырулары белән киләләр: кан басымы, йөрәк, шикәр авыруы, астма... Өстәмә диагнозы булганнарга вирус астыртын һөҗүм итә – хәл тагын да катлаулана.

...Кинәт үземнең дә температура күтәрелде – 38,9. Икенче көн инде мин урын өстендә. Баш авырта, бөтен тән сызлый. Хәлемнең кай якка үзгәргәнен аңлыйм...

...Ун көнләп хастаханәдә ятып чыктым, аннан тернәкләнү көннәре булды. Ашкайнату системасына, бөерләргә зыян килде. Иң авыры – югары температура, тән сызлауга түзәр әмәл юк. Соңрак ютәлли башладым. Йогышлы авырулар хастаханәсендә һәм 7 нче сырхауханәдә эшләүче коллегаларыма рәхмәтлемен – аякка алар бастырды.

...Эшкә чыктым. Ә госпитальдә берни үзгәрмәгән. Табиблар һаман өйләренә кайтмый эшли, авыручылар саны арта бара. Бу ай бигрәк озакка сузылды...

МАЙ

...Үзизоляция тәмам. Урамдагы кешеләрне күзәтәм. Перчатка, битлекләрсез йөрүчеләр очрый, күбесе бүгенге ситуациягә бик җиңел карый. Һаман да ышанмыйлар... Алып килеп, мондагы авыруларны күрсәтәсе иде шуларга! Кеше, үзе аңлап, сакланырга тиеш, кушкан өчен генә түгел. Барысы да ситуацияне дөрес күз алдына китермәүдәндер, мөгаен.

...Бөтен дөнья шау чәчәктә. Алмагачлар, сиреньнәр... Сап-сары тузганаклар... Ә без һаман күпләп авырулар кабул итәбез. Газаплана лар, көрәшәләр... ә кемнәрнеңдер инде көрәшергә дә көче калмый... Шуны күрү авыр...

...«Кызыл зона»дан чыктым. Өс-башымны алыштырып ял итеп алырга 20 минут вакытым бар. «Кызыл зона»га кергәндә барлык шик-шөбһә, фәлсәфәләр коридорда кала. Монда син – алгы сызыктагы солдат. Күп уйларга вакыт юк. Бирегә һәркем тигез: табиб, шәфкать туташы, санитаркалар, хәтта ситуацияне күреп бәяләргә килгән министр да. Һәркем бер-берсенә булышып, иңгә-иң куеп эшли. Нәкъ фронттагы кебек. Дәрәҗәләр, исемнәр, чиннар юк бирегә, хәтәр вирус һәм аның белән көрәшүчеләр

Фото: www.pixabay.com

Кыска гына вакыт эчендә җайлашырга да, көрәшергә дә, дәваларга да өйрәндек.

генә бар. Көн дәвамында саклагыч махсус костюмнан эшләү шактый катлаулы: эссе, һава җитми. Ләкин болар кечкенә бәла генә булып тоела. Сине ничә авыру көтә, син аларга кирәк! Бирегә бернәрсә дә алып керергә ярамый. Мондагы планшетлардан мине көтеп калган телефоныма авырулар турында мәгълүмат җибәрәм. Чыккач, үз-үземә юллаган хәбәрләрне анализлап, авырулар тарихын язам. «Кызыл зона»да өч сәгать тә эшләгән бар, җиде сәгать тә... Көнгә бер дә керелә, ике дә... Ситуациягә карап. Үзем авырып терелгәч, башкаларга күбрәк ярдәм итәсем килә. Бөтен барлыгым, бар күңелем белән авырулар янында мин.

...Төрле препаратлар, дарулар, аппаратлар... Кемнеңдер әнисе, кемнеңдер баласы, кадерле кешесе авыр хәлдә ыңгыраша... Күчлерәк буласы килә! Барысына да җитәрлек игътибар бирәсе иде! Аларны да бит өйләрендә көтәләр...

...Табиблар арасында чир йоктыручылар һаман да байтак, менә шунысы үзәккә үтә. Без әле һаман да бу вирусны ничек туктатырга белмибез. Вирусның үзен түгел, ул зарар китергән әгъзаларны гына дәвалыйбыз. Кайчан туктатып булыр вирусны, әлегә аңлашылмый. Әмма бу сорауга бик тә җавап табасы килә.

...Олы кешеләрнең хәле авыр. Аларның авыруы катлаулырак уза. ИВЛга тоташтырабыз... ИВЛдан соң кешене яңадан сулыш алырга өйрәтү, сулыш органнарын табигый халәткә кайтару җиңел түгел. Һаман да шул хроник авырулар комачаулый.

...Бертуктамый пациентлар кабул итү бара. Көне буе ашыгыч ярдәм машиналары чабыша. Казаннан да, башка районнардан да күпләп алып киләләр. Эш сәгате сигездән – сигезгә, ә кайвакыт кара төнгә чаклы. Атнага бер якшәмбең булса, бәхет инде ул! Хәер, ял иткәндә дә телефон аша эшлибез...

Авыручылар хәле шактый авыр – үпкәләре эштән чыга, бөерләре зарарлана, организм күзгә күренеп таушала.

...Миннән һаман: «Курыкмыйсыңмы?» – дип сорыйлар. Үзем авырып терелгәч курыкмыйм. Инде өйгә дә кайтып йөри башладым. Улларымның шатлануы!

ИЮНЬ

...Бүген олы яшьтәге бер абзый елый-елый рәхмәт әйтте. Терелеп чыгачагына ышанмаган булган... Андыйлар күп. Өмет белән өметсезлек арасы бик якын. Рәхмәтле күзләрне дә күрергә туры килә, Аллага шөкер. Озак авыручылар бар, тиз терелүчеләр. Авыру төрлечә уза.

...Кайберәүләр үзләрендә бу диагноз икәнен аңлагач, өметсезлеккә бирелә. Кемнең иммунитеты нык, кем сәламәт яшәү рәвеше алып бара – алар җиңелрәк кичерә. Кеше организмының мөмкинлекләре чиксез. Ышанырга кирәк...

...Әнием яшендәге бер апага сокланам. Ул һәрвакыт тыныч булырга, хәле авыр булса да, сабыр итәргә тырыша. Кайчак күзләрендә яшь күрәм. Балаларын сагынамы ул, үзе өчен борчыламы, куркамы... Мине дә өйдә һәр көнне әнием көтеп ала. Саклыйсы иде аны!

...Вакыт булганда Америка табиблары язганнарны укырга тырышам. Төгәл, шактый кызыклы мәгълүмат белән бүлешә алар. Бөтендөнья табиблары бер теләк белән яши: вакцина кирәк. Болай барса, бу хәлләр берике елга да сузылырга мөмкин әле. Вирус афәтен җиңәр өчен кешелекнең гомуми иммунитеты формалашырга тиеш. Гриппны без 70% халык авырып чыкканнан соң гына җиңә алдык. Ә коронавирусны иярләрлек көч күренми әлегә...

...Алҗыттты. Мораль яктан да, физик яктан да...

...Сулыш алуы авырлаша. Күкрәк кыса. Һавасыз калудан курку барлыкка килә. Урта яшьләрдәге бер ханымны менә шул хәлдә алып килделәр. Беренче симптомнар башлангач, өйдә генә уздырам дип уйлаган ул. Берничә көннән хәле яхшырган сыман тоелган. Терелдем, дип шатланганда гына, хәле кинәт начарлана, ашыгыч ярдәм чакыра. Covid – бик мәкерле вирус, инде барысы да артта калды, авыруны җиңдем дип уйлаганда гына, икенче фазасы да башланырга мөмкин.

...Яңалыкларны соңгы тапкыр кайчан караганымны хәтерләмим. Кайчак көнгә кырыктан артык кеше кабул итәбез. «Исән калырмынмы?» – дип ялварган күзләр белән һәр көнне очрашам. Бар көчемне биреп авыруларны аякка бастырырга тырышам. Мондагы режимга да ияләштем кебек инде. Әйтерсең, шушында күптән эшләгәнмен. Элеккеге эш урынымдагы пациентларымны да сагындым. Алар да мине көтәдер...

...Маска уелып кергән йөзләр, бер-берсенә охшаш борчулы көннәр, билгесезлек, җаваплылык... Хезмәттәшләрем гаиләләрен сагына. Икешәр ай өйләренә кайтмаучылар бар! Телефондагы видеолар аша «күрешеп» торсалар да, җанлы аралашуга җитми. Кемнеңдер улы-кызы мәктәпне тәмамлады, балаларының туган көннәре табиб әти-әниләреннән башка гына узды... Әмма күңелне төшермәскә тырышабыз. Элеккеге урыннан шалтыратып, язып, көч биреп торалар. Инде ике айдан артык дөньяга чыкмаучылар өйләренә кайткач тормышны башкача кабул итәр. Барыбызның да эчке халәтендә ниндидер үзгәрешләр бара сыман. Табиблар да сынау уза...

...Госпитальдә өр-яңадан эшләргә өйрәнгән 300 дән артык табиб – инде бер гаилә кебек. Бер-беребезнең тәҗрибәсенә таянып эш итәбез. Катлаулы көннәр әле дәвам итәчәген аңлыйм. Дистанцияне сакламыйча, якыннар белән кул биреп, җылы итеп күрешәсе көннәр тизрәк килеп җитсен иде... Вакцина көтәбез...

P. S. Бу язма медицина хезмәткәрләренең һөнәри бәйрәме көннәрендә әзерләнде. Дөньяда куркыныч авыру белән көрәш барган бүгенге авыр көннәрдә үз тормышларын аямыйча кеше гомере сагында торган барлык табибларга, шәфкать туташларына «Сөембикә» журналы редакциясе тирән хөрмәтен, зур рәхмәтләрен җиткерә.

Илгә ябырылган олы кайгы – миллионнарча корбаннар биргән сугыш афәте без – балалар өчен дә зур сынау, балачагыбызны урлаган, бик күпләребезне ятим иткән кара көннәр булып йөрәккә уелып калган. Безнең чор баласы авыр физик хезмәт белән иза чигүләрдән тыш, сәяси яктан кыерсытылу газапларын да башыннан уздырды шул. Искә төшереп, күз алдына китерсәң, җаннар телгәләнә. Ләкин без барысына түздек...

КЫЗЫГЫПЛАР КАРАП КАЛГАН ИДЕК...



Фото: Гөлнара Ибраһимова

Тәкъминә апа белән без авылдашлар. Хәтта күршеләр дә. Сабый чакның рәхәтен тоярга да өлгермәгән балаларның берсе ул. Шул чор кешеләре белән аның да хатирәләре уртак – ачлык, юклык, авыр хезмәт...

Тормышларына кара кайгы булып кергән ул көн – 1941 елның 22 июне гел хәтерендә әле.

– Шомлы хәбәрне кәнсәләрдәге радиодан ишетеп кайттык, – дип искә ала Тәкъминә апа ул көнне. – Минем дүртенче классны тәмамлаган ел. Әти өйдә түгел иде. Сугыш башлануын ишетеп, ул да кайтып җитте. Иртәгәсен аны инде озаттык. Әти китеп бер атна узгач, сеңлем Талия туды. Симетбаш ул елларда Әтнә районына керә иде (хәзер Арча районы). Безнең капка төбеннән генә олы юл уза. Шул юлдан сугышка китүчеләрне сулар эчереп озатып калабыз. Атлар китә, ир-егетләр, яшь-яшь кызлар китә... Шулкадәр матур, янып торган кызлар. Аларның сугышка китүләрен балалык белән уйламаганбыз да, киемнәренә карап бик кызыга идек. Башларында пилотка, итәк-гимнастеркадан, аякларында итек. Алар да утка керәселәрен күз алдына китерми әле, көлешәләр, шаяралар. Берсе дә елап китмәде...

Озата торгач, авылда атлар да, ирләр дә калмады. Җыен бала-чага да хатын-кыз гына... Ә эш коточкыч күп, печәннәр җитеште, игеннәр, аннары бәрәңгесе... Гектарлаган басулар бит алар. Шул елдан мин чын колхозчы булып эшкә кердем. 11 яшем дә тулмаган иде әле...

Тәкъминә апа да кул белән борчак йолкый, чүп утый, башак җыя, гектарлаган иген кырында көлтә бәйли. «Ат белән урак урганда, яланаяк камыл ерып йөреп, балтырлар кып-кызыл кан була», – дип сөйләгәндә җан тетрәнә. Бераз үсә төшкәч, комбайннан салам ташларга куялар, тракторга плугарь итеп утырталар – язы, җәе, көзе кырда уза. Кыш җитте исә, яңа наряд – урман кисәргә барасы!

– Молотов өлкәсендә алты ай буе паровозларга ягарга утын кистек. Кап-кара урманнар, күтәрелеп карасаң, күк кенә күренә. Безнең белән немец әсирләре дә эшләде. «Кайчан өйләребезгә кайтырбыз?» – дип елыйбыз. «Сез кайчан да бер кайтырсыз, безнең андый өметебез дә юк», – дип, алар безне юаткан була.

Урман кисүче кызларны мал вагоннарына төяп, өйләренә озаталар. Тәкъминә апа вагонга утырырга өлгерми кала, юл буе баскычта басып кайтып, бик каты салкын тидерә, кулларын өшетә. Аннары тагын ике тапкыр Лаеш урманнарына бара әле, колхоз урманнарын кисә, Олы Мәңгәр дамбасын салыр өчен таш чыгара...

– Ул суыкларда ничек исән калдык икән, – дип гаҗәпләнә бүген үзе дә.

Тылдагыларның тормышы бик авыр. Әмма тагын да авыры – сугыштагы якыннарының хәлләрен белә алмау...

– Әтием Гәрәй «Кайгырмагыз, ике айдан кайтып җитәрбез», – дип киткән иде... Сугышчыларга ашарга пешергән ул. Баштарак хатлары килде, аннары югалды. Немецларга әсирлеккә эләгә әти. Германияне алгач, үзебезнекеләр коткара аларны. Әмма бер лагерьдан котылып, икенчесенә генә барып керә.

Әтине Арча станциясендә берәү поезддан күреп кала. «Гәрәй исән икән», – дигән хәбәр таралды. Көтәбез-көтәбез, әти юк. Ничәнче елда кайтканын хәтерләмим, «Гаиләмне алып киләм дип, салда агып кайттым», – дип сөйли иде. Кире анда җибәрмәделәр аны, тик монда да тынычлап яшәргә бирмәделәр. Әтнәгә гел сорау алырга чакырып тордылар. «Башка күрешә алабызмы, юкмы», – дип, һәр киткәнендә бәхилләшеп китәр иде...

Бер телем ипи булса иде дип йөргән ул вакытлар инде бер төш кебек кенә. Тыл һәм хезмәт ветераны Тәкъминә Галимҗанова бүген Арча районы Кышкар авылында яши. Авылыбызның иң ихтирамлы кешеләреннән берсе. Бүгенге матур тормышыбызда аның өлеше әйтеп бетергесез зур.

Гөлнара ИБРАҺИМОВА,
Эльмира ИСЛАМОВА.





«ЫШАН МИҢА...»



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

Бу сүзләрне бик якын кешеңнән генә ишетергә мөмкиндер. Монда мәхәббәт тә, хөрмәт тә, кайгырту да, наз да сыйган. Ышанычыңны белдерәсең икән, ул кешедә таулар күчерердәй дәрт-дәрман барлыкка киләчәк. Яратуы чын булса, әлбәттә. Арча районының «Металл» оешмасы җитәкчесе Лилия ГАРӘФИЕВАга 30 ел элек ире Фәнил әнә шул сүзләрне әйтә. Ышана ул аңа. Бик ышана! Шуңа да эшләре гөрләп бара. Үзләре түгәрәк бәхеттә яши... Хәзер инде бу сүзләрне улы Фәнистән ишетә...

Тимер белән сәүдә итүче «Металл» оешмасына эше төшеп килгән һәр кешене аның хуҗасы каршы ала. Тәүлек әйләнәсе шулай. Кыш-җәй, кар-яңгыр булуга карамастан. «Минекеләр сиңа ярдәм итми калмас, – дип әйтәдер сыман ул. – Ышанам аларга». Лилия ханым Гарәфиева янына килгәч мин дә иң элек аның белән очраштым. Куркусыз, тәвәккәл, уйчан күзләр сынап карап торадыр кебек. Үзеннән-үзе баш кагып исәнләшәсе килә. Югыйсә беләсең: ул – фотода гына. Ә фотосурәт – үткәннәрдәге җылы хатирәләрне саклаучы. Әмма ул хатирә генә түгел икән, ул бөтен барлыгы белән монда! Моның шулай икәнен Лилия белән күрешүгә аңладым. Безнең янга килеп исәнләшүгә беренче сүзе: «Менә болар барысы да Фәнилнеке инде, ул булдырды», – диде, фотога карады. «Ә бүген бит сез җитәкче», – дим. «Юк, юк, мин Фәнилнең эшен алып баручы гына, аның исемен яшәтүче...» Тол калганына инде тугыз ел, ә Лилия иренең якты истәлеген хөрмәтләп яши, башкача яши дә белми. Теләге дә юк. Яраланган бәгырьне якты хатирәләр, аның исеме җылытып тора. Үткәннәрне искә алганда Лилиянең күзләре ялтырап китә, көлә башлый. Ә бит бар да матур башлана...

Хатирәләр җылысы

Лилиянең Казан медицина училищесында укып йөргән чагы. Авылга кайткач, күрше егете: «Мин гармунда уйнармын, сез биерсез», – дип, Әтнә авыл хуҗалыгы техникумына чакыра. 20 яшь – күңелдә яз, дәрт ташып торган вакыт. Иптәш кызы белән ияреп китәләр. Ә язмыш

Тормышының бөтен мәгънәсе – балаларында, «Фәнил эшендә». Ул аның ышанычын акларга тиеш.

шулай сәбәбен табып, аны булачак яры белән очраштырырга алып барган икән. Техникумда укыган Арча егете Фәнил беренче күрүдә үк ошата кызны һәм озата кайта. Икесенең дә йөргән егете, кызы була. Ике арада кабынган мәхәббәт көче барысын да оныттыра. Техникумны тәмамлагач, Фәнил армиягә китә, Лилия аны озата да Менделеевскига юл тота. Медицина училищесыннан дүрт кызны юллама белән шул шәһәргә җибәрәләр. Бик озак, җиде сәгать баралар. Шәһәргә килеп кергәч, Лилияне озата килгән әнисе: «Бигрәк ерак, караңгы шәһәр, монда ничек яшәрсез инде?» – дип хафага кала. Хастаханәнең баш табибы кызларны кире җибәрү турында ишетергә дә теләми. «Үзем чакырдым. Өч ел эшләмичә беркая да китмисез. Кияүгә чыгып котылсагыз гына инде», – ди. Дүрт кызның өчесе ничек итсә итә, качалар. Фәнил исә Лилиягә: «Анда фатир алырга уңайлырак булыр, син шунда кал», – дип киңәш итә. Аның сүзенә ышана Лилия: беркемне белмәгән шәһәрдә ялгызы кала. Эшли һәм көтә. Фәнил армиядән кайтуга Лилиясе янына ашыга. Килеп урнаша. Шәһәрдә төзелеш гөрләгән чорлар. Фатир алырга җайлырак булыр дип, йортларга сантехника системасын үткәрү бригадасында эшли башлый. Бер-берсен дүрт ел буе сынаган егет белән кыз өйләнешәбез дигән карарга килеп, күңелле мәшәкатьләргә чума. Ә Фәниллләр гаиләсенә көтмәгәндә кайгы килә. Яшьләр туй балдагы алган көнне энесе юл һәлакәтенә очрап, вафат була. Алар гаиләсе бик авыр кичерә бу фаҗигане, тик Лилия белән Фәнилнең вәгъдәләшкән туйларын кичектерергә рөхсәт итмиләр. Яшьләр Менделеевскида кала.
Тиз арада фатир алалар. Тормышларын ямьләндереп, кызлары Алсу туа, аның артыннан ук уллары Фәнис дөньяга килә. Фәнил металл сату белән шөгыльләнә башлый.
90 нчы еллар бу. Гаилә башлыгы ике эшен дә алып бара. Җитешә алмагач, сәүдәгә генә күчә. Ире эшеннән киткәч, Лилия бик борчыла. «Ышан миңа. Барысы да яхшы булыр», – ди шулчак Фәнил. Гомумән, бу сүзләрне еш кабатлый ул. «Син миңа ышансаң, бар да булыр...»



■ «Дөньямның яме дә, ярдәмчеләрем дә, шатлык-борчуларымны уртаклашучы да, ышанычлы партнерларым да – балаларым...»

Фото: Анна Арахамия

Авыр вакытлар булса да, Фәнилнең эшләре гөрләп бара. Тик күңелнең бер ягы китек: дуслары күп Менделеевскида, ә менә туганнар – юк. Уйлашалар да Арчада өй салалар. Бик затлы ике катлы йорт җиткергәч, 1997 елны күченеп кайталар. Ачык йөзле, харизмалы, теләсә кем белән уртак тел таба белүче Фәнил Арчада да әлеге бизнесын ачып җибәрә. Абыйсын чакыра, танышларын, классташларын җыя. Төннәр буе исәп-хисап белән утырган ирен бик җәлли Лилия. Белә бит: иртә таңнан торып тагын эшкә чабачак. Фәнилгә: «Лилия булдыра торган хатын, өйрәт син аны», – дип киңәш бирәләр. «Мин бит хисапчы түгел, медик», – дип икеләнгән вакытта, иренең мин ышанам сиңа, дигән бер сүзе җитә – Лилия үзлегеннән диярлек эшкә өйрәнә. Әнә шулай гаилә бизнесына әйләнә «Фәнилнең эше». Бик бәхетле еллар була ул. Балалар үсә. Бергәләп ялларга йөриләр, чит илләргә сәяхәт итәләр. Кызлары Алсу Казан финанс-икътисад институтына укырга керә. Фәнилнең эшмәкәрлек уңышы иң югары ноктасына җитә. Аны бар да хөрмәт итә, үзе дә ярдәм сорап килгән бер кешене дә кире борып җибәрми.

– Күпләргә булышты ул. Күпме гаиләгә тынычлык иңдерде. Ул заманнарда эчкечелек көчле иде. Ә хәмер капкан кешенең гаиләсендә дә, эшендә дә гаме булмый. Фәнил ул чорда бик күп кешене айнытты. Дәваларга үзе ташыды аларны. Берсе дә кире ул юлга басмады. Хәтта дингә килгәннәре дә бар. Фәнилнең кулы җиңел булгандыр инде. Бик ярдәмчел иде шул. Арча районының иң ерак авылларына кадәр барып җиткән игелеге», – дип искә ала Лилия, күзләреннән яшь бөртеген чыгармаска тырышып. Әле ул игелекләрнең чиге булмас иде. Тик җәйнең бер көне барысының да астын өскә китерә. Барысының да!


«Язмышыма шулай язылган»

– Ул көнне Алсу институтта бик авыр фәннән имтихан тапшырырга тиеш иде. Бик борчылды инде. Аның өчен без борчылдык. Бала бит! Әтисе имтиханга үзе алып барырга булды. Иртүк торып җыендылар. Чыгып киткәндә: «Сине үбеп китим әле, си-

PRESSA

Улында иренең идарә итү ысулларын күрә Лилия. «Әтиеңә охшагансың», – ди ул аңа.









не үпсәм юлым уңа», – дип үбеп алды. Соңгы назы булган икән... Алар – Казанга, мин әниләргә өй юарга киттем. Үзем өй юам, ә күңелем алар янында. Фәнил институт янында Алсуның имтиханнан чыкканын көтеп утырды. Гел шалтыратып тордым. Берзаман хәбәр килде: «Бирде, борчылма». Казаннан кайткач мине килеп алды. Өйгә кереп тә тормады. Бик ашыкты. Очыртып кына кайтарып куйды да: «Казаннан килгән кешеләр белән очрашасы бар, әзерләнергә кирәк», – дип чыгып чапты. Кич бер шалтыратып алдым әле. «Лилия, мин китеп барам», – диде. Ул аның миңа әйткән соңгы сүзе... Очрашуга әзерләнгәндә бер җирдән икенче җиргә баруын күздә тотып кына әйткән иде югыйсә... Улыбызның иртәгәсе көнне чыгарылыш кичәсе иде. Кич буе шау-гөр килеп шуңа әзерләндек. Бәхетнең түп-түгәрәк вакыты. Ләкин ул беркайчан да түгәрәк була алмый икән. Түгәрәкләнә башласа, бер җире кителә дә төшә, күрәсең.

Йокыга гына киткән чак булгандыр... Берзаман өйгә кешеләр керә башлады. Ә мин йокы аралаш аңышып бетә алмыйм. Фәнилнең абыйсы: «Лилия, Фәнил авыр хәлдә», – ди. «Әйдәгез, табибларга шалтыратыйк, хастаханәгә илтик», – дим. «Лилия, тукта әле... авыр, бик авыр аның хәле», – диләр. Фәнисне күреп алдым – күзләре кызарып беткән. Барысын да аңладым шунда... Ул минутларны искә төшерү дә куркыныч. Сөйләп аңлата алмаслык кайгы! Әмма Фәнилнең әнисенә тагын да авыррак булды. Нәкъ егерме елдан соң икенче улын җирләде...

Лилия сөйләгәннәрдән бер картина күз алдына килеп баса. Төнлә өенә – хатыны, балалары янына ашыгучы Фәнил. Машина коточкыч юл фаҗигасенә очрый. Ул гомере буе шулай яшәп калырга ашыгып яши. Гомеренең һәр минутының кадерен белгән кешенең егәрле йөргәге машинада да әкрен бара алмый. Чаба! Ирсез, әтисез тормыш башлана.

Бу хакта күз алдына китерә дә алмаган, ире артында иркә хатын булып кына яшәгән Лилиягә тол хатын исеме алырга, көчле булырга өйрәнергә туры килә. Фәнилне җирләгәннең икенче көнендә Лилия янына иренең дусты килеп: «Болай ярамый, әйдә, производствога мен, кешегә эш кирәк», – ди. Лилия аңлый: бәрелепсугылып елаудан файда юк, яшәргә, «Фәнилнең эшен» дәвам итәргә тиеш. Эшкә баруын бара, тик аның оешма белән идарә итәргә хокукы юк. Барысы да Фәнил исемендә.

Ә эшләргә кирәк. Күпләп сатып алучылар тезелешеп көтеп тора: «Лилия, ничек булса да җибәр безне, документын аннан бирерсең, эшләргә кирәк бит», – диләр.

– Ни өчен болай булды соң дигән сорауга җавап эзләмәдем. Шулай кирәк булган, димәк, язмышыма шулай язылган дип кабул иттем. Ире үлгәннәр, борчылып, чиргә сабышып, хастаханәләргә эләгә дип сөйлиләр. Минем анда ятарга вакыт та булмады. Әнием: «Бу кайгыларны җиңәргә эш кенә булышты инде сиңа», – ди. Фәнилнең бизнесы көйләнеп бетсә дә, идарәне үземнең кулга алыр өчен бик күп юристларда булырга туры килде. Анысы да җайланды. Эшчеләр янында елап йөреп көчсезлегеңне күрсәтергә ярамый. Елак җитәкче кемгә хаҗәт?! Ул бит иртәгәсе көнгә ышаныч юк дигән сүз. Сәүдә иткән партнерлары белән дә очраштым: «Сез дә Фәнил шикелле эшли торган булсагыз, бернинди сорау юк», – диделәр. Хәлгә керделәр, кредитлар бирделәр. Әле бит Фәнилдән калган кредитларны да түләп бетерергә кирәк иде. Исәп-хисап эшләренә өйрәнеп калуыма шунда бик сөендем. Белмәсәң, ничек таркатмый алып барыр идең. Ул вакытта дусты Илмар Рәхимов бик булышты. «Лилия, борчылма, син булдырасың», – дип, һаман үсендереп торды. Фәнилнең туганнары белән киңәшләштек тә, компания эшләрен алып барырга ярдәмгә өченче буын туганы Инсаф Габделгазизовны чакырдым. Нәрсә дисәң дә, ирләр бизнесы бу. Әлеге сфе-

рада гел ир-атлар. Очрашырга кирәк, алар белән ирләрчә утырырга кирәк. Ирләр арасында хатын-кыз барыбер икенче инде. Сүз дә ябышмый.

Яңа буын эшмәкәре

Фәниснең әтисе кебек бизнесмен буласы килә. Тик металл сатмаячак ул, икенче сферада эшләячәк. «Әти, башлап җибәрергә акча биреп торырсың, яме. Аннан соң кайтарырмын», – дип, зур хыяллар белән яши. Яшь буынга Арча да тар тоела. Казанда яшәячәк ул. Тик фаҗигале җәйге төн аның бөтен хыялларын чәлпәрәмә китерә. «Улым, син әтиең эшен дәвам итәргә тиеш. Бөтен ышаныч синдә инде», – ди әнисе. Үзенең гаиләдә бердәнбер ир-ат булуын аңлый Фәнис. КФУның икътисад факультетында II курста укыган чагында ук: «Әни, үзең генә булдыра алмассың», – дип бизнеска аяк атлый да, җаны-тәне белән кереп китә. Әтисенең эшен саклап калыр өчен производствоны зурайтырга, продукцияне төрләндерергә кирәклеген аңлый. Фәнис идеясе белән 2014 елда профнастил ясау линиясе ачалар. Гаилә бизнесына килгән Алсу бик булыша ул вакытта. Диллерлар табуны үз җаваплылыгына ала. Җылылыкны да саклый, кирпечтән дә очсызрак йөри торган сэндвич-панель җитештерү цехы ачарга теләмисеңме, дигән тәкъдимгә шунда ук риза була Фәнис. Әлеге тармак яңа әле, Татарстанда берничә җирдә генә. Инсаф абыйсы белән киңәшләшә-киңәшләшә (әнисе аны кечкенәдән үк: «Белмисең икән, сора. Белмәү оят түгел, белергә теләмәү оят», – дип үстерә), бу юнәлешне өйрәнә башлый, станоклар табып алып кайта. «Әни, ышан миңа, барысы да яхшы булачак», – ди. 2016 елда цехны эшләтеп җибәрә. Беренче линиясендә әле кул көче кирәк булса, икенче линиясенә автомат станоклар эзләп таба Фәнис. Сатып алучылары да Татарстаннан гына түгел, Россиянең төрле төбәкләреннән. Хәзерге буын яшьләре бөтенләй башка. Нәрсә теләгәннәрен белеп яшиләр. Яшь эшмәкәрләре дә гел эзләнүдә.
Күп укыйлар, аралашалар, төрле вебинарлар үтәләр, үзләрен рухи яктан баеталар, динне хөрмәт итәләр, төрле күргәзмәләргә дә йөриләр.

Компания дә үсә, әйләнеш тә арта. Фәнис килгәч, эшчеләр саны да ике тапкырга артып, җитмешкә җиткән. Барысы да бериш: солдатлар кебек. Нигездә, яшь егетләр. Төрле холыклы җитмеш ир-атны бер йодрыкка җыеп тору да зур осталык сорыйдыр. «Эшчеләр өчен җаваплылыкны бик сизәм мин, – ди Лилия. – Кеше без биргән хезмәт хакына яши. Монысын да яхшы аңлыйм. Шуңа да аны арттырырга тырышабыз. Анысы да җитештерелгән продукциянең сатылуы белән бәйле, бездән генә тормый. Эше булу-булмау өчен дә без җаваплы. Улыма да шуны аңлатам».

Компаниядә ике җитәкче була алмый. Идарә дилбегәсен улына тапшыра: Фәнис оештыра, Лилия исәп-хисап эшләрен башкара. «Әле ярый пенсия яшен арттырдылар. Юкса киләсе елга пенсиягә китәсе елым иде», – дип сөенә. Кызы Алсу Казанга китсә дә, гел ярдәм итеп тора. Ир-ат бизнесы икәнен белә, энесенә ышана, шуңа да күңеле тыныч.

Спорт мастерлыгына кандидат булган Фәнил хоккей уйнаган, чаңгы шуган. Районда турнирлар үткәргән. Хәзер аның матур традициясен гаиләсе дәвам итә. Арчада Фәнил Гарәфиев исемендәге турнирлар үтә. Гыйнвар аенда – ул туган көнне хоккей турнирлары үткәрсәләр, февраль аенда районадагы мәктәп балаларын, колледж укучыларын җыеп, чаңгы ярышлары оештыралар. Фәнилнең изге гамәлен – хәйриячелек эшен дәвам иттерәләр. Фәнилнең исемен әнә шулай да яшәтәләр әле.

Һәрвакыт истә...

– Бу сезнең идеяме? Күргәч, йөрәгем тетрәнеп китте. Сезгә бик авыр булгандыр, – дип сорыйм Лилиядән, Фәнил абый фотоларыннан ясалган плакатка күрсәтеп.

– Әйе, минеке. Фәнил үлгәннең икенче елында элдек. Сигез ел инде яңартып торабыз. Минем шул рәвешле бу компанияне Фәнил оештыргаының күрсәтәсем килде. «Ул – хуҗа. Фәнилнең рухы яши монда», – дип әйтәсе килү теләге көчле булды. Онытылмасын иде...

Лилия, бәлки, моны үзе өчен дә ясагандыр. Төшләрендә йомшак итеп башларыннан сыйпаган ире, күзен ачуга югала. Эшкә килгәч кабат очрашалар. Каршы ала ул аны, озатып кала... Лилия белә: Фәнил кебек башка кеше юк. Кем белән чагыштырсаң да, аның ягындагы бизмән тәлинкәсе баса. «Мин бик бәхетле, янәшәмдә яраткан хатыным», – дип әйтә торган була ул. Кочак-кочак чәчәкләр бүләк иткән... Ул бәхетле мизгелләрне бер көн дә исеннән чыгара алмый Лилия. Бөтен нәрсә аны хәтерләтә... Фәнилнең әнисе, туганнары белән дә бик якын алар. Һәрвакыт аралашып торалар.

– Элек Фәнил янымда булганда канатланып яши идем. Хәзер бар да инерция буенча гына бара. Артык сөенүдән дә куркам. Бәхетнең түгәрәк булмавын беләм. Балалар, эш – беренче урында. Ә калганы, бәхетең – кырыйда торып тора...

«Мине бик идеаллаштырып язмагыз, яме. Фәнил башлаган эш бара, мактанырлык берни юк», – дип озатып калды безне Лилия ханым.

...Арча районының тар һәм сикәлтәле юлында машина тәрәзәсеннән ямь-яшел болыннарга карап, уйга чумып кайтам. Лилияне идеаллаштыру өчен аның хакында бернәрсә дә ишетмәдем бит. Теленда бары тик Фәнил. Ул һаман ирем дип яшәвен дәвам итә. Чын мәхәббәт әнә шундый буладыр инде ул.
Ә аны саф, чиста күңелле, көчле рухлы, җилләрдә сыналмыйча, үзенә хыянәт итмичә яшәгән кешеләр генә тормыш маягы итеп алып барадыр. Очрашу мизгелләрен кабат күз алдыма китерәм. Район үзәгенең төрле почмакларына бардык – Лилия ханым рульгә утырмады. Югыйсә замана бизнесвуменнарын тимер атсыз күз алдына да китереп булмый. Шалтыратып: «Бер соравым калган: сез машина йөртәсезме?» – дип сорыйм.


– Юк, Чулпан, рульгә утырмадым инде. Фәнил миңа йөрмә дип әйтә иде...

Фәнил әйтә... Ир хакы барысыннан да өстен!

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм иту
1920-2020

Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да... Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

БАССЕЙНЛЫ, СӘХНӘЛЕ... ФЕРМАБЫЗ































Фото: Эльвира Әхтәмова

Гөлфия МУЛЛАХМӘТОВА: «Без авыр эштән курыкмадык. Булганына шөкер итеп яшәдек. Бүгенге рәхәт, мул тормыш шул чактагы авырлыкларга сабыр итә белгән өчен бүләктер кебек тоела миңа».

«Безнең ферма кызлары – авылның йолдызлары!» – дип җырлыйлар алар турында. Фотолары – газета һәм журнал битләрендә. Үзләре авыл, район советы депутатлары, слет, съезд делегатлары. Алар – социалистик ярыш алдынгылары, иң күп сөт савучылар.

«Азат хатын» журналының 1977 елгы сентябрь саны тышлыгыннан елмаючы Гөлфия Муллахмәтова да – ул чактагы Минзәлә районы «Ярыш» колхозының (хәзер Тукай районы) алдынгы сыер савучысы. Сигезенчене тәмамлаган көннән лаеклы ялга чыкканчы – 41 ел рәттән бер көн ялсыз фермада эшли ул. Аңа ул вакытта нибары 15 кенә яшь була әле.

«Дус кызларым белән барыбыз да сыер саварга кердек, – ди Гөлфия апа. – Миңа 15 буаз тана сайлап бирделәр. Шуларны бозаулатып, саварга өйрәтеп, үземә группа тупладым. Эш көндәлегенә кайсы сыер көнгә күпме сөт биргәнен, кайчан бозаулаганын язып бара идем. «Сирень» кушаматлы бер сыерымнан елына 4,5 мең литр сөт сауганмын. Чорына күрә ул бик күп булган инде».

1965 ел бу. Савым аппаратлары әле юк. Унбиш сыерны көненә өч тапкыр кул белән савасы. «Беләкләр сызлый, куллар иртәнгә шешенә... – дип искә ала ул. – Шулай да бездә тырышлык, үҗәтлек көчле булды. Төнге икедә, өчтә торып фермага барабыз. Йоклап ятсаң, сыерларыңа башак болгатырга кайнар су да, онлы апара да эләкми бит! Башкалар алдында бер дә сынатасы килми. Группа белән группа, бригада белән бригада, колхоз белән колхоз ярыша».

Алдынгы сыер савучының эше ферма белән генә чикләнми. Авылдашлары аны авыл һәм район советы депутаты итеп сайлый. Депутат ул – халыкның илчесе, аларның гозерен югарыдагыларга җиткерүче. Кемгә кемгә, күп балалы гаиләләрнең бар борчуы аңа яхшы таныш. Күрше Күзкәй егете – баянчы Өлфәт белән комсомол туе ясап өйләнешеп, үзләре дә өч ул, бер кыз үстерәләр. Ялгыз карт-карчыкларга ярдәм оештыру да аның күз уңында. «Ничек кенә өлгердек икән? – дип, бүген үзе дә аптырый. – Җәйләрен сыерларны Ыкның аръягына җәйләүгә алып чыгып, өчәр-дүртәр ай шунда эшли идек. Гектарлаган чөгендер бүлеп бирәләр. Өйдә дә хуҗалык зур...» Аннары үзе үк җавабын да бирә: «Яратып эшләгәнгә, яратып яшәгәнгәдер. Яшьлек матур үтте безнең. Җәйләүләргә барганда, кайтканда, машина кузовына төяләбез дә, и җырлыйбыз! «Әнә ферма кызлары кайтырга чыкты», – дип, күрше авыллар безне тыңлый икән. Бәйрәмнәр якынлашса, кич клубка йөгерәбез. Концерт әзерлибез, спектакль куябыз... Мин биергә, чигәргә... һәм китап укырга ярата идем. Өйдәгеләр йоклап беткәч, өстәл астына лампа белән кереп утырам да, дөньямны онытам.

Эшемне бигрәк яраттым. Без балалар үстергәндә декрет ялы ике генә ай иде. Анда да кызларның фермага барганын тәрәзәдән күреп елыйм. Сыер саву никадәр авыр хезмәт, ә фермадан китсәм, башка бер генә җирдә дә эшли алмам кебек тоела иде. Безнең фермабыз үзе генә дә нинди иде бит! Ашханәсе, мунчасы, хәтта бассейны да булган фермалар сирәктер. Бик сагынсам, әле дә шул тирәләрдән әйләнеп төшәм. Бүген анда тагын да матуррак. «Ярыш» хуҗалыгы җитәкчесе Рәсим Шәйхаттаров инициативасы белән тирә-юнenә агачлар утырткannaр, асфальт җәйгәннәр, бөтен эш техника белән башкарыла. Кайчагында шул шартларда эшләргә үзем дә кызыгам».

Лилия ГӘРӘЕВА



Коткарыгыз, бала карап арыдым! Әти-әниләрнең артык тырышып бала тәрбияләве тискәре нәтиҗәләргә китерә башлады. Әле менә үзизоляция көннәре дә әти-әни белән балаларны «якынайтты». Хәер, монысы икенче тарих, ә без алҗыган әниләр турында сөйләшик әле.



Раилә ХӘЯЛИЕВА

АЛҖЫГАН ӘНИ ХАЛӘТЕ

– Әни, бу малай миңа ком ташлады!

– Әни, таганга утырасым килә!

– Әни, куышып уйныйк әле!

– Әни!..

Урамдагы кояштан алҗып өйгә керәбез.

– Мин токмач ашы ашамыйм!

– Миңа буяулар кирәк, рәсем ясыйсым килә!

– Минем белән курчак уйна әле!

– Әни, теге токмач ашы кирәк...

– Әни, буяулар төшеп китте!

– Әни...

Иртәнге ашны кайчан ашаганымны хәтерләмим. Көзге яныннан йөгереп узганда гына чәчләремне тарыйм... Җәй бит, үземне дә формага кертергә кирәк! Бакчадан апасы кайтканчы юып-җыеп, үтүкләп, пешереп, әзерләп, кечкенәсенең меңтөрле кылын көйләп, әтисе кайтканчы түзеп...

Сездә дә шулаймы ул, әниләр? Минем еш кына Сальвадор Далиның чиксезлекне сурәтләүче сәгать формасына керәсем килә – менә шулай сузылып кына берәр өслеккә салынасы иде ул. Кем нинди фәлсәфә күрергә тели, шуны күрсен, ә мин... Ә мин әлегә үземне балалары артыннан бертуктаусыз йөгергән мультиктагы теге әни маймыл кебек хис итәм. Һәм... вакыт-вакыт бернәрсә эшлисем дә, беркемне кайгыртасым да килми башлый...

Миндә генә түгел, бала карап алҗыган әти-әниләр симптомы хәзер ике яшь гаиләнең берсендә очрый, диләр. Кемнеңдер булышу-

чысы юк, финанс хәле авыр. Икенчеләре – борчылырга яратучылар, идеаль әни булырга тырышучылар, өченчеләре – барысы да бала өчен дип үзенең бар тормышын «корбан» иткән әти-әниләр…

Айсылу (өч бала әнисе):

– Балаларымның яшь аермасы 2-3 яшь кенә булса да, һәрберсе җәмгыятьнең әни кешене төрлечә кабул иткән аерым чорында үсте. Беренче баламны тапканда, барлык «алга киткән» әниләр усал кайнана, балага бирелә торган махсус ризыклар һәм прививкалар турында бәхәсләшә-бәхәсләшә форумнарда аралаша иде. Бервакыт бер яшь әни: «Бала карап арыдым!» – дип язып куйганнан соң, форумда нинди тавыш чыкканны күрсәгез! «Декретта ялыктыңмы? Ничек бу турыда кычкырып әйтә аласың! Икенче бала алып кайтырга теләмисеңме? Эгоистка! Бала карап арыдыңмы? Алайса ник таптың?..» Чыннан да, бала тәрбияләп хәлдән тайган әни кеше, бу очракта күз яшьләренә буылып, гаеп хисе генә кичерә ала иде. Чәчең юылмаган, ничәнче атна йокы күрмәгәнсең, нерв кылларың өзеләм дип зыңлап тора икән… Тсс! Дәшмә! Синең бәхетле әни булырга гына хакың бар!

Ә икенче улыбызны алып кайтканда экраннарда пеленканың ике ягын да үтүкләмәсәң дә ярый, бала тәрбиясенә җиңелрәк карарга кирәк дип Комаровский күренә башлады. Әни кешегә күбрәк ял итәргә, үзен кайгыртырга кирәклеген искәрткән китаплар барлыкка килде. Җиңелрәк булып китте.

Бер ел элек без тагын бер нәни кызның әти-әнисе булдык. Яшь әни буларак мин яңа чынбарлыкка эләктем. Бала тапканнан соң барлыкка килгән артык килограммнар, җыелмаган балалар бүлмәсе, уңмаганбулмаган сыйфатларың турында туры эфирдан сөйләү – кәттәлек билгесенә әверелде. Әни блогерлар шулай кылана! Рәхәтләнеп зарлан!

Бала тәрбиясенә чумып, әниләрнең хәлдән таюы, эмоциональ яктан ару һәрвакыт булгандыр дип уйлыйм мин. Тәҗрибәм шуны исбатлый. Әмма аның турында хәзер генә

Әниләрнең аруын, ялыгуын җәмгыять таный торган вакыт җитте.

кычкырып сөйләргә ярый башлады, әлеге хәлне өйрәнүче психологлар барлыкка килде. Һәм без бу турыда торган саен күбрәк ишетә башладык…

Әтиләргә дә тукталыйк әле. Хатыны белән бала табарга баручы ирләргә инде экзотика итеп карамыйлар. Ияләшенде. Әтиләр хәзер бала карау процессында шактый актив катнаша. Памперсның нинди үлчәмдәгесен алырга кирәклеген дә, кояштан саклый торган кремның кайсы киштәдә ятканын да, кызларның нинди курчак яратканын да әйбәт белә замана әтиләре. Алай гынамы соң, бар көчен бала тәрбиясенә биреп, нәкъ әниләр кебек үк, эмоциональ яктан «янган» әтиләр дә бар икән!

Рөстәм (ике кыз әтисе):

– Мин кечкенә вакыттан бирле әти булырга әзерләндем. Бу, мөгаен, сәер яңгырыйдыр, ләкин мин, 13 яки 15 яшьлек малай, туачак улыма нинди сүзләр сөйлисен, нинди китаплар укыйсын һәм кинолар күрсәтәсен барлап йөри идем. Кешеләр үз балаларын тәрбияләгәндә нинди хаталар җибәргәнен күзәтә, хәтта өйрәтеп тә маташа идем.

Бүген миңа 30 яшь. Күз алдыма китергән үзем төсле тыйнак малай урынына терекөмеш кебек ике кызым бар. Мин җыйган методик материал аларга өч тиенгә дә кирәк түгел, һәм алар мине урталайга сындырып үзгәртәләр. Көлсәгез, көлегез – менә шулай!

Соңгы биш елда хатыным белән бөтен вакытыбызны бала тәрбиясенә бирәбез. Киендерәбез, уйнатабыз, буш вакытларын гел файдалы әйберләр белән генә тутырырга тырышабыз. Бүген икебез дә, психологлар теле белән әйткәндә, «эмоциональ яну» халәтендә. Башта балаларга ирек биреп барысын да эшләдек, аннары аларны «сындырырга» тырыштым… Имештер, безнең гаиләдә башкача була алмый. Бер мизгелдә борчуга төшкән хатыным, вазгыятьне читтән күреп, аңларга ярдәм итте, һәм мин куркып калдым. Балаларның характерын тәрбияләү һәм аны изү – бер үк әйбер түгел икән.

Кырыслык һәм ваемсызлык – әтиләр арасында ике иң еш очрый торган сыйфат. Безнең буын күбесенчә хезмәткә бирелгән, балалардан читләшкән әтиләр белән үсте. Минем моны үзгәртәсем килде, ләкин тиз арада уңайсыз хәлдә калдым.

«Кеше балалары шундый тыныч, ник безнең өйдә бетмәс «бака туе» соң?», «Тырышлыгымның бер кадере дә юк!», «Балалар белән кайнашып кына уңышка ирешә алмыйм!» дигән фикерләр күп әти кешегә таныштыр. Ул фикерләрне кычкырып әйтмисең инде, билгеле. Аларны хәтта уйлаганда да шыпырт кына уйлыйсың, берүк кыяфәтеңә чыкмасын! Ләкин алар табигый, авыруның симптомы сыман. Шундый уйларга барып җиттең икән – анализла: син ничек үзгәрергә тиеш? Синең хакыйкатең аларга килешмәячәк – бөтен дөнья әдәбияты шул турыда сөйли. Балалар белән бергә үзгәргәндә генә, дөньяны яңадан өйрәнгәндә генә син аларны чын шәхес итеп үстерә аласың. Тәҗрибә белән бүлешергә кирәк, ләкин булмаган зирәклегең белән масаерга ярамый.

КЫЗЫКЛЫ МӘГЪЛҮМАТ

Безнең илдәге кайбер дәү әти-дәү әниләр оныклары белән Европача аралаша башлаган. Алар оныкларының дусты булырга, берничә сәгать вакытларын шул балалар белән уздырырга әзер, әмма икенче әти-әнигә әйләнергә, бала тәрбияләүдә тулысынча катнашырга риза түгелләр икән. Яшь чакта, үз балаларын үстергәндә эмоциональ яктан талчыккан әти-әниләр, олыгайгач, шундый карар кабул итә дип фаразлыйлар.

Фото: Анна Арахамия

Әти-әнинең тырышлыгы балалар тарафыннан бәяләнмәү дә күңелне төшерә.

Ялгышсаң – гафу үтенергә кирәк, бала хөрмәтле кеше булырга тиешләр. Белмәгәнеңне таныырга һәм бергәләп эзләнергә кирәк. Таләпләр куйганда бала гаделлекне тоярга тиеш һәм башкалар...

Бу киңәшләрне алдан укыган булсам, алар миңа ярдәм иткән булыр идеме икән? Шикләнәм. Һәрберсен үзең «уйлап тапмыйча» булмыйдыр шул ул, дөнья шулай яратылган. Ләкин күптән ишеткән бер фикер миңа чынлап та ярдәм итте: һәрвакыт үзеңнең яхшы әти-әни икәнлегеңә, балаңның мөмкинлекләре һәм сәләтләре чиксезлегенә ышанырга кирәк. Без хәзер дилбегәне җибәрә төштек, самолеттагы сыман, башта үзеңә кислород битлеге кияргә кирәк, аннан балаңа кидерергә...

Идеаль бала тәрбияләргә тырышкан тагын бер әни фикеренә күз салыйк.

Галия (бер малай әнисе):

– Үземне инстаграм корбаны дип атыйм. Инста-әниләргә хас булганча бала көтүләр, фотосессияләр, сәламәт яшәү рәвеше, иң яхшы әни булырга тырышуларым... Ярты елдан шундый талчыктым! Әниләргә замана таләпләрен тирә-юнь йоктыра дип сөйләшсәк тә, үзебез өчен үрелеп булмаслык киртәләрне үзебез куябыз икән бит! Зирәк, акыллы, тыныч, ягымлы елмаюлы... ПП пәрәмәчләр, тортлар пешерү остасы, балаң картинкә кебек киенгән, өең Скандинавия стиленә туры китереп бизәлгән... Үзен кайгырткан, яраткан, массажын ясаткан, каш-керфекләре урынында булган, һөнәре буенча да югары дәрәҗәләргә ирешкән, гаилә учагын саклый белгән... Янып көлгә әйләнер өчен бу сыйфатлар артыгы белән җитә. Идеаль әнинең баласы – дерматит, томау төшүләрдән ерак тора, агрессиянең ни икәнен белми, тырыш һәм максатчан, уен бүлмәсендә генә уйнап утыра... Юк, юк! Мин хәзер мондый тормышның фотошоплы инстаграм битләрендә яки рекламада гына була алганлыгын яхшы беләм. Көндәлектә әле сүрелеп бетмәгән үз-үземне гаепләү хисе булса да, тау башына таш тәгәрәтмим инде. Бу стереотиплардан арынырга тырышкан мәлем. Барысын да җибәреп, ару-талулардан арынасым, баламны ничек бар шулай кабул итәсем, үзем теләгәнчә әни буласым килә...

Ике кыз үстерүче әни буларак, мин үзем дә бу хакта бик еш уйланам. Чөнки тормышымда кызыксынуларыма вакыт калмады диярлек. Барысын да бер бизмәнгә салып үлчәгәч, шундый нәтиҗәгә килдем: без үзебез тырыша-тырыша баланың вакытын үзебез белән тутырабыз бугай ул. Үзебез теләп аниматор роленә кергәнбез түгелме? Минем әти-әниләр баланың һәр минуты файдалы, кызыклы, мәгънәле булсын дип тырышмаган. Шулай да начар кешеләр булып үсмәдек бит әле. Тормышын кечкенәдән үк үзе кызыклы итәргә өйрәнгән балаларның киләчәге дә күңелле булыр сыман.

Олы яштәге күрше апа көлә-көлә бала үстергән чакларын сөйли. «Әй, авыр иде кечесе белән. Алтынчы катка күтәреп менсәм, ник алып менден, кире төшер, ди. Мунчага алып керсәм, чыккач, ник юындырдың, дип җиргә ятып елый иде», – ди. Ә мин уйланам. Балаларның көйсезлеге менә шулай көлеп сөйләрлек хатирә булып кына калсын иде ул, олыгайгач, алар өчен генә яшәдем, ә хәзер кадерем юк, дип үкенүләр булмасын иде.

...Миннән башка күңелсездер, кызларым янына киттем.

– Кызым, әйдә, маршрут уенын уйныйбыз!

– Кызым, китап укыйммы, рәсем ясыйкмы?

– Балалар өчен йога вакыты җитте!

– Кызым, әйдә, бергәләп аш пешереп алыйк әле!

– Кызым!..

БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ



Роза ШӘФИЕВА, психолог

Элегрәк вакытта яшьләр тормышка җаваплырак, җитдирәк караган. Хәзерге яшьләр исә бар эшне дә җиңел генә хәл итеп куярга ярата. Гаилә кору, бала тууны шатлык итеп кабул итсәләр дә, мәшәкатьләренә әзер булмыйлар. Чөнки күп очракта бүгенге әти-әниләр үзләре дә бала гына булып кала әле. Үзләренә күбрәк вакыт бирәселәре, күңел ачасылары килә.

Кеше үз гаиләсе, балалары белән аралашудан бәхетле булырга, рәхәтлек алырга тиеш. Әгәр шатлык хисләре юкка чыга икән, белгеч ярдәме кирәк.

Күңелсезлекләргә, ару-талу хисенә бирелмәс өчен, әниләргә берничә киңәш бирәсем килә:

- иртән уянгач, беренче эш итеп тормышыгызда шөкер итәрлек әйберләрне барлап чыгыгыз;
- табигатькә күбрәк чыгарга тырышыгыз;
- иҗат итү – иң әйбәт тынычлану чарасы, кызыксынуларыгызны искә төшерегез;
- ачуланып, үпкәләп йөрмәгез. Арып китсәгез, ирегездән, мөмкин булганда, дәү әни-дәү әтиләрдән ярдәм сорарга уңайсызланмагыз.

Бүгенге көндә социаль челтәрләрдә әти-әнинең алҗуы турындагы сөйләшуләрнең активлашуы дөньяда барган авыр ситуация белән дә бәйледер. 24 сәгать буена өйдә, һаман гел бер үк кешеләр янында булып арыдылар, аралашу даирәсен киңәйтергә кирәк.

ИРЕМ БАЛА ТЕЛӘМИ

Ике балабыз үсеп килә, инде өченчесенә узып куйганмын. Бигрәк көтмәгәндә булды, андый планнарыбыз юк иде. Бу хакта иремә әйткәч: «Шушы икесен яхшылап үстереп бетерергә кирәк. Өчесен дә үстерерлек, укытырлык, урнаштырырлык мөмкинлегебез юк, соңга калганчы, барып төшерт», – ди. Абортның кеше үтерүгә тиң гөнаһ булуын, һәр баланың үз ризыгы белән туганын әйтеп карыйм, ишетергә дә теләми. Хәзер әнә: «Табасың килсә, тап, ләкин миннән башка үстерерлек булсаң гына», – ди. Өч бала белән ялгызыма чынлап та авырга туры киләчәк. Иремне ничек күндерергә соң? Аныңча эшләмәсәм, ташлап чыгып китәр дип куркам.

Г. СӘЛИМОВА.
Буа районы.

Ландыш НИГЪМӘТҖАНОВА,
Татарстанның атказанган артисты, җырчы:

– Без үзебез дә күп балалы гаилә. Насыйп булса, тагын бер сабыебызны көтәбез. Безнең өчен балалар артык мәшәкать түгел, киресенчә, алар тормышка бәхет, ямь бирүчеләр. Без аларның һәрберсен шатланып көтеп алдык. Һәрбер бала үз ризыгы, үз бәхете белән туа, диләр. Хак сүзләр. Аллаһы Тәгалә ничә бала бирә, табарга кирәк. Кемдер баланы бик тилмереп, ялварып сорап ала бит. Аборт ул – коточкыч әйбер. Хатын-кызның яки баланың сәламәтлегенә куркыныч янамаса, ул адымга бармаска кирәк. Ә инде ир кеше баланың тууын теләми икән, җаваплылыктан курка икән, димәк, ул башка балаларны тәрбияләүдә дә бик катнашмагандыр. Сез табыгыз, соңыннан үкенерлек булмасын. Андый куркак ирләр беркая да китми алар. Ә китә икән, димәк, андый кеше сезгә кирәкми.

Фәрит ТАИШЕВ,
җырчы, хосусый эшмәкәр:

– Гаиләсе, балалары өчен ир кеше җаваплы. Ул ир кечкенә малай түгел бит, мөнәсәбәтләрнең нәтиҗәсен инде белергә тиеш. Ник әле аның гамәле өчен гөнаһсыз сабый гомере белән түләргә тиеш?! Гомерне бирүче дә, алучы да без түгел, шулай булгач, аңа кул сузарга хакыбыз юк. Үз-үзенә ышанмаган, көчсез, куркак кешеләр генә бар җаваплылыкны үзләреннән төшерергә, башкаларны гаепләп калдырырга тырыша. Әйе, балаларга тиешле тәрбия бирү, укыту, яхшы шартларда яшәтү өчен зур көч куярга кирәк. Бу дөньяда яшәвебезнең максаты да шул бит инде: үзебездән соң игелекле балалар калдыру.

Әлбәттә, кеше гаиләсенә кысылып булмый, һәр гаиләнең үз кануннары, үз тормышы. Әмма сау-сәламәт булган ир, хатынын абортка куарга тиеш түгел дип саныйм, мин аңа каршы. Бала ул – Ходай бүләге. Бүләктән баш тартмыйлар.

Белгеч фикере



Ләлә БӘҺРАМШИНА, психолог

– Бу хатынның ничектер күңелен күтәрә торган сүзләр әйтәсем, аңа көч бирәсем килә. Әлбәттә, туасы җанның гомерен өзәргә кирәкми. Авырлыклар вакытлыча гына. Конкрет бу очракта исә ир-атны җавапсыз дип әйтү дөрес булмас иде, ул гаиләсе өчен җаваплылыкны тойганга шушы сүзләрне әйтә. Ә җаваплылык тойган ир-ат белән сөйләшергә, уртак фикергә килергә мөмкин. Бәлки, мисаллар китереп, бәлки, дин әһеленә яисә психологка мөрәҗәгать итеп... Вакыт узган саен, ул әле үзенең фикерен үзгәртәчәк, тормышындагы бу яңалык белән килешәчәк. Яңалыкка ияләнер өчен дә вакыт кирәк бит. Шундый мәкаль бар: «Аллаһы Тәгалә баланы бирә икән, балага да бирә».

Бу ханым, ире гаиләсен ташлап китсә, берүзем өч баланы ничек үстерермен, дип борчыла. Ә чынлыкта, вариантлар бар. Стресс вакытында без аларны күрмибез генә, курку аңны томалый, күз алдында карачкы кебек тора. Бер генә вариант: китәм дип җыенган очракта сез аңа ике олы баланы үзе белән алып китәргә тәкъдим итегез. «Алар синең белән булсын, ә мин кечкенәсен үзем үстерәм», – диегез. Бу инде иң соң чиктә кулланырга мөмкин булган вариант. Минемчә, киләчәктә ир кеше барыбер үз баласын кабул итәчәк, яратачак ул аны.



Айгөл МИНҺАҖЕВА

ДИМЧЕ ДИҢГЕЗ КИЧЕРЕР

Һәр хатын-кыз – бриллиант. Әмма кайчак бриллиантка кемнеңдер күзе төшсен өчен дә аны азрак ялтыратып җибәрергә кирәк. Бу – димче эшенең бер үзенчәлеге. Тик үзе теләп алган вазыйфаларның соңгысы түгел.
Димләп кавыштыру бүген тормышыбызда нинди урын алып тора, яшь гаиләләр нинди авырлыклар белән очраша, аерылышуларның сәбәпләре нидә? Россия һәм Татарстан Мөслимәләр берлеге рәисе, тәҗрибәле яучы Наилә ҖИҺАНШИНА белән шулар хакында сөйләшәбез.

Яучылык белән ничек шөгыльләнә башладыгыз, Наилә ханым?

– Безнең нәселдән килә торгандыр: әбием дә, әбиемнең кызлары – апаларым да димләргә яраткан. Миңа да бу эш бик ошый. Башта үзем белгән, якын иткән кешеләргә ярдәм итәм дип кенә тотынган идем: иремнең иптәшләрен өйләндердем, дус кызларымны кияүгә бирдем. Шулай димче булып киткәнемне сизми дә калдым: берсеннән-берсе ишетеп, мине моңарчы белмәүчеләр дә мөрәҗәгать итә башлады. Бервакыт алар шактый күбәйде, һәрберсен хәтердә тоту авырлашты. Һәркемгә аерым анкета тутыру, аларны кайдадыр бер урында кабул итү ихтыяҗы килеп туды. 2010 елда «Ханым» гаилә үзәген шулай ачып җибәрдек. Россиядәге иң зур үзәкләрнең берсе санала ул бүген. Яратып, бар күңелебезне салып эшлибез! Инде шактый гына яучылар тәрбияләдек. Республикабыз районнарында үзәкнең филиалларын ачтык. Әгәр кемгәдер бер филиалда пар табылмый икән, аңа туры килгән кешене Казандагы үзәктән эзлибез, чөнки монда бөтен дөньяда яшәүче татарларның анкеталары тупланган. Сайлау мөмкинлеге күпкә зур.

Мөрәҗәгать итүчеләргә карата яшь буенча чикләүләр бармы?

– Юк дисәм дә була. Кызларны – 18, ир-егетләрне 20 яшьтән алабыз. Иң олы яшьтәгеләргә килгәндә, 85 яшьлек ир-атның һәм 88 яшьлек хатын-кызның мөрәҗәгать иткәне бар. 88 яшьлек ханымга, кызганыч, пар таба алмадык, чөнки ул яшьтәге хатын-кызларны сораучы юк. Кияүләр 80 яшьтән узса да, 70 яшьлекләрне эзли.

Егетләрнең кайберләрен әти-әниләре: «Өйләндерәсе иде», – дип, 19 яшьтә үк алып килә. Тик аларны кабул итмибез, бу яшьтә әле дөньяга үз карашлары формалашмаган, акыл утыртмаган. Өсләренә җаваплылык алырга да әзер түгелләр. Әти-әниләренә азрак сабыр итәргә кушабыз: башлы-күзле булырга өлгереп җитсеннәр, шулай дөресрәк булыр, дибез.

Ә кызларны хәтта 16 яшьтән үк алып килүчеләр дә бар. Мин, әлбәттә: «Иртәрәк бит әле, нишләп болай ашыгасыз?» – дип сорыйм. «Кияүгә бирергә иртә икәнен беләм. Ул хакта соңрак уйларбыз, вакыты җиткәч... Ә хәзергә акыллы, әдәпле берәр кеше белән танышып аралашуларын телим. Мин моны эшләмәсәм, ул барыбер кайдадыр кем беләндер танышачак», – диләр. Аннан кызларның өлгерү вакытлары барыбер төрле бит: кемдер 14-15 тә үк егетләргә күз ташлый башлый, икенчеләре бу вакыт әле курчак

кына уйный. 14-15 яшьтә кыз бала, әлбәттә, кемнең кем икәнен аера, кешегә бәя бирә алмый. Яратам дип алданулар шул чорда килеп чыга да. Әни кешенең баласын күп ялгышлардан саклап, аралап калырга теләвен бик аңлыйм. Кызга 18 тулганчы безнең аша танышкан егет белән аралашып, очрашып торалар да, аннан никах укыталар. Кемдер 18 яшьне дә бик иртә дияргә мөмкин: кыз бала әле белем алмаган, тормышта үз юлын тапмаган... Андыйлар өчен бер мисал китерәм. Бер дустым үзенең кызын 18 яше тулуга кияүгә бирде. Югары уку йортына кергән генә иде әле. Укый-укый биш ел эчендә ике бала тапты. Балаларын да үстерде, укыды да, хәтта эшләргә дә өлгерде. Укуын тәмамлауга, 23 яшендә үз фирмасын ачты: ул инде профессиональ белгеч булып җитешкән иде. Әниләреннән беркайчан ярдәм сорап йөрмәде, бик мөстәкыйль булды. Яшьли кияүгә чыгып нәрсәнедер югалтты дип уйламыйм, киресенчә, тормышта үзенә ни кирәген иртә аңлады – үз юлын тапты.

Күп әти-әниләр: «Башта укысын әле, карьера ясасын, фатир, машина алсын», – диләр. Ул арада кызга 30–35 яшь тула. Яхшы кияү турында уйлана башлыйлар. Ә яхшы кияүләр инде барысы да өйләнеп беткән... Җитмәсә, кызның таләпләре югары: егет чибәр дә, бай да, уңган да булсын, кызга баш та иеп торсын. Кыз үзе берәүгә дә баш иярга җыенмый, чөнки ул инде мөстәкыйль тормыш итәргә, эшләргә дә, яшәргә дә күнгән. Мондый туташларны кем беләндер кавыштыру инде бик авыр.

Бер-берсе белән таныштыргач та, яшьләрне әле күзәтеп торам. Кызганыч, бүген аларның күбесе бер-берсенең яхшы якларын күрергә тырышмый. Иң элек начар сыйфатларын эзли. Аннан: «Ә ул миңа нәрсә бирәчәк?» – дигән сорауга җавап эзләргә керешә. Ялгыш фикер дип саныйм моны. Гомерлек юлдаш сайлаганда, кеше: «Мин аның тормышына нинди яңалык алып киләм?», «Нәрсә бирә алам аңа?», «Мин аны бәхетле итә алырмынмы?» – дип уйларга тиештер. Үз-үзеңә шушы сорауларны бирәсең икән, мондый гаилә нык булачак.

Кызлар егетләрне еш кына нинди критерийлар буенча эзли?

– Бүген аларның күбесе эшчән егет эзли. Ялкаулардан бик куркалар, күп никахлар шуның аркасында таркала. Кызлар хәтта мәхәббәткә хирыс булган егетләрдән дә ул кадәр курыкмый. Тагын бер таләпләре – буе йөз илле сантиметрдан артмаса да, көчле зат булсын, диләр. Куркак, юаш булмасын дип тә телиләр. Гомумән, хатын-кызга көчле һәм мал таба торган ир-ат кирәк.

Ә егетләрнең булачак кәләшләренә таләпләре күпме?

– Егетләрнең берсе дә кызның малы турында сорамый. «Фатиры бармы?», «Күпме акча алып эшли?» дигән сорауларны беркайчан биргәннәре юк. «Булачак хатыным өйдә хатын-кыз эшен эшли белсен, тәмле пешерсен, өйне ямьләсен», – диләр. «Талашмасын. Бөтен нәрсәне утырып сөйләшә, аңлаша, уртак фикергә килә алырлык булсын», – диләр.

Мөселман егетләргә өйдә генә утыручы хатын кирәктер инде?

Егет-кызларга: «Идеал эзләп килгән булсагыз – ялгыштыгыз, андыйлар юк», – дибез.

– Соңгы елларда шундый тенденция күзәтәм: берәү дә булачак хатынына андый таләп куймый. Гомумән алганда, мөселман ир-атлары да хәзер хатын-кызның каядыр чыгып эшләвен, тырыш булуын, иренә гаилә йөген тартырга ярдәм итүен тели. Безгә шактый бай ир-атлар да килә. Алар, әлбәттә, гаиләдә хатын-кыз да эшләргә тиеш дими. Әмма кистереп: «Өйдә генә утырачак», – диючеләре дә юк. «Эшлим, дисә, каршы булмаячакмын. Андый теләге бар икән – ярдәм итәрмен», – диләр.

«Миңа өйдә генә утыра торган хатын кирәк», – дип, ортодоксаль мөселманнар гына эзли. Исламда шундый агымнар бар... Алар үзләре дә артык эшләми, ризыкны Аллаһ бирер диләр дә көтеп утыра. Аларга килгән хатын да булган малга һәм ризыкка риза булырга тиеш. Әмма мондыйлар, шөкер, бик аз.

Егетнең гаилә тормышына әзерме-юкмы икәнлеген ничек белергә?

– Әгәр дә ир-ат гаиләсен әле матди яктан тәэмин итә алмый икән – шәригать буенча аның өйләнергә хакы юк. Эше бар, ризык алырга, фатирга түләргә, үзе өчен генә түгел, хатыны өчен дә транспортта йөрергә акчасы җитә икән – шул вакытта өйләнсә дә була. Статистика буенча, 90 процент аерылышулар акча җитмәү аркасында килеп чыга. «Аерылышырга телим», – дип шалтыраткан хатын-кызлардан һәрвакыт моның сәбәбен сорыйм. Еш кына җаваплар гел бертөрле: «Ул беркайда да эшләми», «Балалар бакчасына түли алмыйбыз», «Бурычка баттык»... Алар бу очракта хаклы. Хатынны һәм балаларны кем ашатырга тиеш соң? Өйләнү – бер түшәккә ятып йоклау дигән сүз генә түгел әле ул. Өйләнү – Аллаһ каршында бурычлар алып, ул бурычларны үтәү дә. Гаилә коргач – балалар туа, аларны үстерергә, кеше итәргә кирәк. Шуның өчен дә алдан һәр адымыңны санарга, «Көчем җитәрме икән?» дип уйларга кирәк. «Нигә борчылырга, Аллаһ Сөбеханә вә Тәгалә һәрнәрсәне бирә», – ди кайберәүләр. Әлбәттә, Раббыбыз бирә, әмма ләкин урында ятып торган кешегә түгел – ул ялкауларны сөйми.

«Хатыным бернәрсәдән риза түгел», – дигән сүзләрне ишеткәлим. «Ә хатының риза булсын өчен син нәрсә эшлисең соң?» – дип сорыйм. «Мин шунда барып вәгазь тыңлыйм, монда барып җәмәгать белән очрашам», – диләр. Көнне шулай үткәрәләр. Гаиләле булса да, ял көне вакыт табып, вәгазь тыңларга бара ала ул, әлбәттә. Ләкин эш көннәрендә ир-ат эшләргә тиеш.

Бер хатын килде. 35 яшьлек улын өйләндерергә йөри. Иң беренче итеп: «Ә улыгыз кайда эшли?» – дигән сорауны бирдем. «Юк, ул эшләми, укып йөри», – ди. «Ә ул хатынын нинди акчага ашатырга җыена?» – дим. «Минем пенсиям бар», – ди. «Пенсия улыгызга түгел, сезгә бирелә. Ә ул бит сау-сәламәт», – дим. Егет кеше 15–20 яшьләрдә –

«Әйтмәгән түгел, әйткән сүзләр үкенечле, чөнки алар өчен җавап бирәсе бар».

укырга, ә 35 яшендә инде эшләргә тиеш. «Аңа бит дингә өйрәнергә кирәк», – ди әнисе. Дин гомер буе укып кына утырырга кушмый безгә – аның өчен буш вакыт бар, ул эшләргә куша.

Никахка кадәр яшьләр бер-берсен күпме вакыт белергә тиеш?

– Кайвакыт кызлар киләләр дә: «Бер егет белән биш ел очраштык, аннан ташлаштык», – дип сөйлиләр. Болай озак йөрү – вакытны әрәм итү ул. Кыз баланың еллары санаулы. Аллаһы Тәгалә бала тудыру өчен иң хәерле вакыт 20 дән 35 яшькә кадәр ди. Ул биш ел эчендә балалар тудырып, аларны инде күпме үстерергә мөмкинсең бит. Шуңа күрә берничә ай аралашу да җитә дип саныйм.

Яшь гаиләләрнең төп проблемасы дип тагын нәрсәне атый аласыз?

– Бик еш кына кыз бала кияүгә чыккач: «Минем әти-әни – ул, әйе, әти-әни, ә ирнекеләрнең безнең тормышта урыннары булмаска тиеш», – дип саный. Ягъни: «Безгә минекеләр генә кунакка килә ала, мин үземнекеләргә генә ярдәм итәм, минем әти-әни генә яхшы...», «Ничек инде аның әти-әнисе безнең тормышка кысыла ала?», «Нигә әле алар безгә килеп йөриләр?» – ди ул. Әгәр дә кияүгә чыкканда ук кыз баланың башында шундый уй-фикер була икән – аларның бергә яши алуы икеле. Егетнең әти-әнисе, әлбәттә: «Нишләп шундый хатын сайладың?» – диячәк, һәм ир барыбер ул сүзләргә колак салачак. Йөрәгендә мәхәббәт әкренләп суыначак. Йөрәген суыткансың икән – иртәгә үк аерылмаса да, берничә елдан шул сүзләрне әйтәчәк. Мәхәббәт бит ул йөрәк эше. Күп кызлар: «Мин аның йөрәге белән дә идарә итә алам», – диләр һәм ялгышалар. Моны эшләп булмый!

Аерылырга уйлаган бер ир-аттан: «Нигә бу адымга барырга булдың?» – дип сораганым бар. «Ул миңа шулай дип әйтте... Ул сүзне ишеткәч, бөтен әгъзаларым салкынаеп китте. Аңарга карата бернинди хисләрем юк хәзер», – дип җавап бирде. Хатын-кыз: «Әйтәм дә, ул үзгәрә, минемчә эшли», – дип уйлый. Иренең мәхәббәтен сүндерүен күз алдына да китерми.

Күптән түгел яныма сигез айлык авыры булган яшь хатын килде. «Ирем аерылышырга тели, нишләргә? – дип елый. – Күрәсез, бәби көтәм, миңа хәзер тынычлык кирәк, ә ул миңа талак әйтергә җыена». Без аның белән бик озак сөйләшеп утырдык. Гаеп аның үзендә булып чыкты. Ире еш кына үз әнисе янына хәл белергә бара һәм һәрвакыт берәр күчтәнәч алып бара икән. «Ә ник иregез әнисе янына үзе генә бара?» – дим. «Ул бит миңа беркем түгел, нигә мин аның янына барырга тиеш?» – дип сорауга сорау белән җавап бирде ул. Бер очракны искә төшерде. Ире аңа да, үз әнисенә дә концертка билет алган. Барырга чыккач, әнисен машинаның алгы утыргычына утырткан.

Моны күреп, хатын кара тавыш чыгарган: «Ул – минем урыным. Ник анда әниең утырырга тиеш?» Бу сүзләрдән соң ире аны ничек яратсын?! Мондый ситуацияләр сигез ай эчендә шактый җыелган: ирнең йөрәге тәмам каткан, хәтта туачак баласын да кирәксенми башлаган... Бу хатынга холкын үзгәртергә киңәш бирдем.

«Ул миңа өйләнде. Менеке! Беркая да китми», – дип уйлый хатын-кыз. Әмма ир – милек түгел. Кешене берничек тә үзеңә бәйләп куеп булмый, хәтта бала белән дә. Ир-ат тел ярасын кичерми. Сүз белән аны яралыйсың икән – ул аның йөрәгендә җыелып бара. Психологияләре шундый. Җыела-җыела да, бервакыт шартлый. Ә хатын-кыз: «Әйтәм! Әйтә алам!» – дип сөенә...

Никах – ул Аллаһтан бирелгән могҗиза: әллә кемнәрне берләштерә. Бер хәзрәт: «Мин никахта ук килен белән кияүнең әниләрен дуслаштырырга тырышам. Бервакытта да проблема әтиләр ягынан чыкмый. Гаиләне таркатуга «ярдәм итүчеләр» – әниләр. Әгәр ике әни дуслашып уртак тел тапса, балаларына аерылышырга рөхсәт итмәячәк», – дигән иде. Әйе, шулай! Ике араны татулаштырырлык киңәшне алар, һичшиксез, бирәчәк.

Яучының роле егет белән кызны таныштыруда гынамы?

– Алай гына димәс идем. Безнең яучылар 90 процент гаиләне аерылышудан да саклап кала. 10 проценты – ашыгып өйләнүчеләр. Мәсәлән, бер кыз белән бер егет тышкы кыяфәтләрен ошаттылар да кавышып та куйдылар. Кыз бик телчән, ә егет аз сүзле. Берничә айдан аерылыштылар: егетнең сабырлыгы беткән. Әмма вакытында килеп киңәшләшсәләр, ярдәм итә алыр идек аларга.

Кичә генә яныма 48 яшьлек бер хатын-кыз килде. «Нинди генә яучыларда булмадым, кияүгә бирә алмыйлар», – ди. Сөйләшә торгач, аның кияүгә чыга алмау сәбәбен аңладым. Ул үзе дә ризалашты аның белән, үзгәрергә вәгъдә бирде. Әгәр кеше киңәшләрне ишетмәсә, тыңламаса – аны кияүгә бирә алмыйбыз. Мондый вакытта үзеңә читтән күз салырга кирәк: бәлки, таләпләрең артык зурдыр, ирдән бик күпне көтәсеңдер? Юк, яучының эше «алдың да бирдең» генә түгел. Яучы янына килгәч, күңелен, җанын ачучылар байтак: аларга кем туры килгәнен шунда ук аңлыйсың. Күңелен ачмаганнар да бар: боларына әле юл табарга кирәк башта...

«Ханым» «Ханума»

татарлар өчен гаилә төзү һәм аны саклау халыкара үзәге

Түбәндәге юнәлешләр буенча эшли:
- гаилә төзергә ярдәм итә;
- сезгә туры килгән парны сайлаша;
- курслар, тренинглар уздыра;
- ике арадагы конфликтлы хәлләрне чишәргә, бер-береңне яхшырак аңларга, гаиләдә гармония табарга булыша.

18+

Реклама

Телефон: 8-952-042-18-15 Электрон адрес: hanuma2021@mail.ru

КҮЗ ТИЮ



«Шамил» мәчете
имам-хатыйбы
Мәхмүт хәзрәт
ШӘРӘФЕТДИН
җавап бирә

Күз тиюне ничек аңлатасыз?

– Мин үзем авыруларны өчкә бүләм. Тән белән бәйле авырулар, курку, артык борчылу сәбәпле барлыкка килгән җан авырулары һәм рухи авырулар. Күз тию һәм сихербозымны рухи авыруларга кертәм. Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) күз тию хакында әйткән бер сүзе бар: «Күз тию – хактыр ул, йөгереп йөри торган бияне дә казанга кертер», – дигән. Чыннан да, арада күзе каты кешеләр очрый. Аларның күзләреннән билгеле бер дулкыннар (вибрация) пәйда була. Ул дулкыннар кемгәдер, бигрәк тә балага барып ирешә икән – аның тормышында чирләр, авырлыклар барлыкка килергә мөмкин.

Үзеңә күз тигәнне ничек белергә?

– Кайвакыт кешеләр авырып китә. Төрле табибларга да мөрәҗәгать итәләр. Әмма медицина аларга ярдәм итә алмый: кеше өметсезлеккә, төрле шикләргә бирелә. Яки эшләре гөрләп барган җирдән көннәрдән бер көнне уңышсызлыклар гына сагалый башлый: тырышлык куйганда да җайланмый. Гаилә тормышында да чатаклыклар килеп чыга. Мондый вакытта дога уку яки белгән кешедән укыту файдага булырга мөмкин.

Күз тиюдән ничек арынырга?

– Күз тиюдән арындыра, чистарта, саклый торган бик күп догаларны киңәш итә динебез. Шулай ук дин күрсәткән чистарыну ысуллары бар – Коръән аятьләрен, догаларны суга укып, шул суны эчү һәм шуның белән юыну. Догалы су белән коену – тәҗрибә белән расланган бер дини нәсыйхәт.

Күз тиюдән сакланып калып буламы?

– Тән чирләре белән авырмас өчен кешенең иммунитеты көчле булырга тиеш, диләр. Аның өчен табиблар дөрес тукланырга, стресстан сакланырга киңәш итә. Сулаган һавабыз, эчкән суыбыз да чиста булырга тиеш. Боларга әле физик эшне дә өстәргә була. Шуның кебек үк, кешенең рухи иммунитеты да югары булырга тиеш. Рухи чирләрдән саклану өчен һәрвакыт уңай фикердә булу зарур. Көнләшү, хөсетлек, тәкәбберлек, башкаларны кимсетү уйлары безнең күңелебезне какшата, рухи чирләр килеп чыгуга сәбәп була. Кеше үзенең күңелен чиста тота, ашаган ризыгы – хәләл, «бисмилла»лы, өенә кергәндә-чыкканда догалар укып йөри икән – андый кешегә күз авырлык белән тия. Дөресрәге, тими дияргә дә була.

Әмма бу заманда кешеләрнең һәрвакыт ачык йөз, якты күңел белән йөрүе дә бер хикмәт бит әле. Эчке һәм тышкы дөньясы елмаю, шатлык һәм сөенеч белән тулган бер кешедән: «Сез ничек һәрвакыт күтәренке күңел белән яши аласыз? Ни гаҗәп, сезнең йөзегездә елмаю бервакытта да сүрелми. Безгә дә шушы хәлгә ирешү юлын өйрәтегез әле. Үзегезнең бәхетле булу серен безгә дә ачсагыз иде», – дип сорыйлар. Бу кеше: «Мин дә нәкъ сезнең кебек бик озак еллар буе күңелсезләнеп, булган һәм булмаган хәлләргә борчылып яшәдем. Әмма бик күп эзләнүләрдән соң шуны аңладым: Аллаһы Тәгалә бу гомерне һәм шуның белән бергә ихтыяр көчен миңа бүләк иткән. Шулай булгач, бәхетле булу-булмау минем үз кулымда. Һәр көнне иртә белән уянгач, мин үз-үземә: бүгенге көнне сөенечтә яки кайгыда уздыру минем үземнән тора. Шуңа күрә бу көннең һәр мизгелен сөенечтә, шатлыкта уздырачакмын дип боерык бирәм», – дигән. Күп нәрсәнең бары тик үзебездән торганын беркайчан да онытырга ярамый.

Балаларны (кайвакыт үзебезне дә) төрле бөтиләр, күз формасындагы сувенирлар ярдәмендә сакларга тырышабыз. Боларның файдасы бармы?

– Алда әйтелгәнчә, ата-ана баласын күз тиюдән саклап калырга теләсә, хәләл азык белән ризыкландырырга тиеш. Имезгән вакытта догалар уку, зекер әйтеп ашату баланың рухи иммунитетын арттыра. Ә инде бала авырып китеп, табиблар ул авыруга дәва таба алмаса, әлбәттә, аңа дога укырга, белгән кешедән өшкертергә ашыгырга кирәк. Гадәттә, суга, тозга, бала ашый торган ризыкка догалар укыйлар. Догалы су белән коендыралар. Чыннан да күз тигән булса, бала тиз арада тынычланыр, аңа шифа килер. Миләш ботагын кесәдә йөртү, күз формасындагы төймәләр тагу да очрый. Алар барысы да ниндидер тормыш тәҗрибәсе аркылы килеп чыккан ышанулар. Әмма дин бу әйберләргә уңай карамый. Боларны куллану урынына дога белән шифалану һәм саклану киңәш ителә. Дога язып, шул кәгазьне бала янына кую да бар. Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) якын шәкертләреннән берсе – ибне Гомәр бик еш кына балаларны күзгә күренмәгән дулкыннардан (күз тиюдән), шайтаннардан саклар өчен Коръәннән аятьләр язып, шуны балалар янына куйдыра торган булган, диләр. Догалы язу балаларны да, олы кешеләрне дә саклый, доганың һәркемгә бәрәкәте бар, тәэсире көчле.

ЧИРМЕШӘННЕҢ БАЛТА ОСТАСЫ



Лилия
ГӘРӘЕВА

Бричка, кашовка, тарантас, арба алды, арба карамалары, арба кендеге, арба күкрәге... Йә, кайсыгыз «арба карамалары»ның ни икәнен беләә? Ә «арба күкрәге» дигәне нәрсә? Бричка, тарантас?..



«Ат алсаң, арба кирәк»
(татар халык мәкале).

– Әле кайчан гына хуҗалыктагы иң кирәкле әйбер иде бит ул ат арбасы. Утын-печән ташысаң да, хуҗалыктан тирес чыгарсаң да гел арба кирәк булды. Утыз-кырык елдан ат арбаларын да музейга куярга туры килер дип кем уйлаган... – язмам герое көрсенеп ала.

Музей экспонаты дигәннән, Чирмешәннең туган як тарихы музеенда бер композиция бар. Тырыш авыл агаеның җыйнак кына ихатасы ул. Ишегалдындагы каралты-куралары белән такта түбәле, алты почмаклы авыл йорты кергән дә утырган. Коесы да шунда гына. Яңарак кына урманнан утын алып кайткан, күрәсең, атын туарса да, арбасын бушатырга өлгермәгән әле. Бүкәнгә чапкан балтасы эш көтеп тын калган. Печәнгә төшәсе чалгылар да сандалга салып таптаганны көтә булыр... Музейга ничек сыйган ул йорт дияргә ашыкмагыз әле. Чып-чын өйнең, чын арба, эш коралларының кечерәйтелгән нөсхәләре алар. Шушы арбага җигәрдәй ат булса, хәзер үк җик тә кит!

Район мәдәният йортында рәссам-бизәүче булып эшләгән Сәлимҗан Гамиров хезмәте болар. Ат арбаларының, элеккеге эш коралларының бары музейларда гына калып баруына көрсенүче дә ул.

– Бүгенге балалардан, нәрсә ул шөшле, нәрсә ул өтергә, дип сора, җавап бирә алмый. Сандал нәрсә дисәң, белмиләр. Хәтта чалгы белән кул пычкыларына кадәр музей экспонатына әверелеп бара. Менә без уйлаштык та, үзебез күреп үскән авыл тормышын шулай итеп булса да гәүдәләндерик, дидек. Күпләр өчен үзенә күрә бер ностальгия.

Сәлимҗан Гамиров үзе Чирмешән районының Түбән Кәминкә егете. Алтын куллы, диләр аның турында, белмәгән, эшләмәгән эше юк, диләр. Укытучы да булырга туры килгән аңа, балта остасы да, рәссам да, хәтта ферма мөдире дә булган. Ә инде атлар турында сөйли башласамы?! Соң, авыл малае булсын да, ничек инде атлар яратмасын?

– Әти гомере буе колхозда атлар карады, – дип аңлата ул үзе моны. – Авыл малайлары ат тирәсендә үсә. Ныклап тәпи йөрергә өйрәнденме, аяклар үзеннән-үзе шунда тарта. Ат абзарында һәр малайның «үз» тае була. Әнә шул тайны сыйлар өчен өйдән ипи чәлдерәсең, өстәлдәге шикәр шакмагын кесәңә шудырасың... Шулай сыйлый-сыйлый, аны башта үзеңә ияләндерәсең. Елгага алып төшеп, әнидән качырып кына алган сабын кисәге белән кыргычлыйкыргычлый юасың, аннары атланырга тырышып карыйсың. Ә аның тәне кытыклана, үрле-кырлы сикерә, койрык чәнчеп чаба... Ялына тотынып калсаң, каласың, тотынып кала алмасаң, тояк астына тәгәрисең. Һи-и, безнең ул тәгәрәүләр...

Ат «җене» әтисе Газимҗан агадан булса, рәсем «җене», мөгаен, әнисе Саимәападандыр. Иллә дә оста чигүче булган ул. «Безнең өйдә бар нәрсә чигүле иде. Әни үз куллары белән чиккән мендәрләрдә йоклап, ул чиккән сөлге-тастымалларга кул-битне сөртеп үстек», – дип, күңеленнән бала чакларына да сугылып ала Сәлимҗан абый.

Мәктәпне тәмамлагач, Лениногорскидагы педагогика училищесына укырга керә. Нияте – рәсем һәм сызым укытучысы булу. Мәктәптә укыткан елларын хәзер инде сагынып сөйләргә генә калган. Армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң, сукмакларны язмыш бөтенләй башка якка бора: ферма мөдире итеп чакыралар аны. Балта эшенә осталык менә кайда кирәк була!

– Ул вакытта колхозда атлар күп иде. Аты булгач, арбасы кирәк, чанасы кирәк, камыты, ыңгырчагы, дугасы, дилбегәсе... күп инде санасаң... Югыйсә техника да көчле вакытлар, әмма атларга да игътибар зур булды. Көн дә җигә торгач, арбалар ватылып та куя. Үз гомеремдә бик күп рәтләргә туры килде аларны, рәтли-рәтли, башым ката торган иде. Авылда бик оста арбачы Рәшит абый Лотфуллин иде безнең. Яңасын да ясый, искесен дә төзәтә... Аннан да күп нәрсәне өйрәнгәнбездер, әтинең дә агач эшенә кулы ятар иде. Ул ясаган өстәл-урындыклар белән яшәдек. Бала чакта агач мылтык ясыйбыз дип, аның яхшыяхшы такталарын шактый турадым, – дип көлә оста.

Иң беренче арбасын да әтисенә бүләккә ясый ул.

– Пенсиягә чыккач, әти «Вишня» кушаматлы ат алды. Шул атны җигәр өчен, тәвәккәлләп, бер арба ясап карарга булдым. Дөресен әйтим, чын борынгыча, бөтен җире агачтан булган арбалар инде без үскәндә дә юк иде алар. Әйтик, арбаның ике күчәрен, безнең якта аны ось дип кенә йөртәләр, элек каен агачыннан ясыйлар иде. Моның өчен юан, шәп каен кирәк. Усактан ясасаң, ике-өч елга гына чыдый. Шул каенны циркульле пычкыдан чыгарасың. Андый пычкың булмаса, балта белән юнасың, ышкы белән ышкылыйсың. Алай мәшәкатьлерәк. Тора-бара агач күчәр урынына тимерне куя башладылар. Арба ясау эше бермә-бер җиңеләйде.

Фото аша шул чор атмосферасын күрсәтәсебез килеп, агач көпчәкләр дә булса, дип сүз башлаган идек, Сәлимҗан абый көлде үзебездән.

– Арбага күптән инде агач көпчәк куймыйлар. Алар да хәзер тимердән. Тимер көпчәк күпкә чыдам, күпкә ышанычлы, – ди ул. – Хәзер арбаның күп өлеше заманча. Әйтик, элеккеге арбаларны кабык белән тегәләр иде. Аның өчен урманнан юкә каерысын салдырып, тигезләп җәеп киптерәләр иде...

– Юкә кабыгы арба төбен җәяргә яраклымы? – дип гаҗәпләнәм.

– Бик калын, бик чыдам була ул, – ди оста, шикләремне таратып. – Әмма бүген юкә кабыгы кулланмыйлар инде. Кем калай белән тегә, кем рези-

Фотолар: Гөлсирә Шарифуллина һәм Кадрия Гамирова

Арбаны музейларда гына күрер көн тиз килмәсен әле.

на җәя... Дөресен әйткәндә, ат арбаларының хәзер бик кирәге дә юк. Шуңа күрә аны ясый белүчеләре дә сирәк. Хәзер бит ат асраучы хуҗалыклар да аз. Атларны мотоблоклар, тракторлар алыштырды. Атны ел буе ашатып, тәрбияләп торырга кирәк. Ә мотоблокка бензин гына саласы...

Безнең күбебезнең фәкать гади ат арбасын гына күргәне бар. Югыйсә элек аның әллә ничә төрен ясаганнар.

– «Шайтан арбасы» дигәне була. Анысы печәнсалам ташыр өчен бик кулай. Башка якларда аны башкача атыйлардыр, Чирмешәндә менә шулай дип йөртәләр. Аннары урманнан бүрәнә ташый торганы бар. Русча атамасы – «колымага». Ул – каркастан гына гыйбарәт озын арба, хәтта утырып йөри торган урыны да юк. Авылда булса, берәү яки ике генә була. Аннары икмәк ташый торганын да онытмыйк, бричка дип йөртәләр аны. Бортлары биек итеп, ярыклар калдырылмый ясала. Ә көнкүрештә иң күп кулланылганы шушы гади ат арбасы. Ул универсаль – нәрсә төясәң дә була аңа.

Сәлимҗан абыйларның үзләренең дә авылдан Чирмешәнгә күченгәннәренә шактый инде. 1995 елда килеп төпләнәләр монда. Алабуганың мәдәният һәм сәнгать училищесын тәмамлап, рәссам-бизәүче белгечлеге алган ир-егетне район мәдәният йортына эшкә чакыралар.

«Ул бик матур сәгатьләр дә ясый», дип ишеткән идек без аның хакында.

– Вакыт булса, әллә нәрсәләр дә ясар идем, вакыт ягы гына кысан, – ди Сәлимҗан абый. Ә сәгатьләр ясавы хак. Кибеттән алган әзер сәгатьләрне бизәүдән башланган булган бу шөгыле. Хәзер бары механизмын гына сатып ала, калган барлык өлешләрен үз куллары белән ясый. Агачка чокып бизәк төшерелгән (милли бизәкләр кулланырга тырыша) ул сәгатьләр бик тә үзенчәлекле.

Кем генә булып эшләргә туры килсә дә, укытучылык барыбер канында, ахрысы, аның. Балаларны җыеп, музейның үзендә оста куллар түгәрәге оештыру – моңа дәлил.

– Теләүчеләр күп, урын ягы гына кечерәк. Узган ел оештырылган түгәрәккә сигез малай, бер кыз йөрде. Иң гади әйберләрдән башладык. Хәзерге балаларны башта чүкеч тотарга өйрәтергә кирәк әле, – ди ул.

Бу түгәрәкнең эшләп китүендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутат Илгиз Салиховның да ярдәме зур булуын әйтеп узды. Агач кыру станогы, циркульле пычкы аның ярдәме белән алынган.

– Балаларга бик кызык үзе. Өйрәнәселәре, үз куллары белән нәрсәдер ясыйсылары килә, – ди Сәлимҗан абыйлары.

Аның үзенең дә әле өйрәнергә теләгән нәрсәләре күп.

– Бер тарантас ясап карыйсым килә, – ди ул. – Андый тарантаслар элек бар иде, хәзер күргәнем юк. Музей өчен генә булса да берне ясап куярга телим. Бездән соңгылар аның нәрсә икәнен дә белмәячәк. Һичьюгында музейдан булса да күреп белерләр.

Һәр яңалык – бик яхшылап онытылган борынгы әйбер, диләр. Әйе, бүген техника заманы, атларга да, арба-тарантасларга да ихтыяҗ юк. Бүген юк, ә иртәгә булмас, дип кем әйтә ала?!

P. S. Арбаның төбен тоташтырып тора торган агачларны «арба карамалары» дип атыйлар. «Арба алды» – арбаның төп арбага кендек белән тоташтырыла торган алгы өлеше. «Арба күкрәге» – арбаның алгы күчәренә кендек белән тоташа торган өлеше. «Арба кендеге» – арба алдын төп арбага тоташтыра торган озынча юан тимер.





16+

Һәрбер өйгә таныш көйләр... Милли моңнар һәм Китап

КИТАП МИЛЛИ РАДИО

Смартфоннарда тыңлагыз:

Google Play



App Store



Реклама



ЯГЫМЛЫ ЧИРМЕШӘН.

Татарстанның иң көньяк ноктасы ул Чирмешән. Тау тезмәләре, яшел тугайлары, эреле-ваклы чишмәләре, уңдырышлы кара җирләре кемне дә әсир итәр. Ә урманнары ни тора! Районда бер кешегә ике гектар урман туры килә дип тә сөйлиләр әнә. Минераль тозларга бай чишмәләренең шифасын да телгә алмый калмыйлар. Бәркәтә, Туймәт, Кармыш, Лашман, Әмир, Кәминкә, Яңа Кади дип, исемнәре үк ягымлы авылларын санап китәләр. Тарихи истәлекле урыннары, гүзәл табигате, күркәм кешеләре белән күңелләрне яулый торган үзенә бер сихри як бу. XVIII гасыр урталарында ук төзелгән Чирмешән һәм Шешминка ныгытмаларын Пугачев валы тоташтыра. Россия империясе чикләрен Оренбург далалары ягыннан килүче күчмә халыклардан саклый торган форпост булган ул.
Шул биеклектән түбәнгә карасаң, күзне иркәләп, яшел түбәле Чирмешән җәйрәп ята! Яңа төзелгән йортлар, парк-скверлар фонында мәчет манаралары үзенә бер бизәк булып балкый. Бер яктан, авыл хуҗалыгы районы, чып-чын аграр төбәк бу; икенче яктан, нефть, битум ятмаларына бай җирләр. Шәһәрчә яшәүче авыл дисәң дә була, авыллыгын саклаган шәһәр итеп тә кабул итәсең бу Чирмешәнне. Һәм сокланасың! Халыкның тормыш шартларын яхшырту, аларны социаль яклау, аналар һәм балалар мәнфәгатен кайгырту, инвалидларга һәм ветераннарга ярдәм итү, аз керемле гаиләләргә булышу… Районның социаль-икътисадый үсеш программасы күп өлкәләрне колачлый шулай. Уңышлар турында сөйләгәндә инде сүз үзеннән-үзе район башлыгы Фердинат Мидхәт улы Дәүләтшинга барып тоташа. Тәҗрибәле, алдан күрә белү сәләтенә ия, яңалыклардан курыкмый торган, теләсә нинди очракта да зирәк һәм акыллы чишелеш таба белгән җитәкче диләр аның турында. Авыл хуҗалыгын күтәрүгә керткән өлеше, шәхси эшмәкәрләргә булышуы, минифермаларга юл ачуы турында иркенләп сөйлиләр. Менә ни өчен Чирмешән дип әйтүгә – Дәүләтшин, Дәүләтшин исемен телгә алуга ук Чирмешән күз алдына килеп баса. Ә аңа барысы да сыйган: ирешелгән уңышлар, матур эшләр, халыкны сөендерерлек изге гамәлләр, кешеләрнең ышанычы һәм рәхмәтләре… Халык каршында менә шундый имтихан тотып һәм чирмешәнлеләр яратуы белән билгеләнгән иң югары бәяне алып, Фердинат Мидхәт улы үзенең түгәрәк юбилеен каршылый. Бу көннәрдә олпат җитәкчегә ихлас котлау сүзләре, матур теләкләр җиткерүчеләр бихисаптыр.
Кем ул, нинди ул? Кай яклары белән тирә-юньдәгеләрнең ихтирамын казана алган? Уңышларының сере нәрсәдә?
Район башлыгы белән иңгә-иң торып эшләгән хезмәттәшләре Фердинат Дәүләтшинны һәркайсы үзенчә ача. Туган көндә әйтелгән ул җылы сүзләр бәйрәм котлавы булып барып ирешсен.



Рәмзия ДОЛГОПОЛОВА, район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары

– Фердинат Мидхәтович безнең районга үз эшен тирәнтен белгән тәҗрибәле җитәкче буларак килеп керде. Эшен объектлар карап йөрүдән түгел, аз керемле күп балалы гаиләләр белән танышудан башлады ул. Берничә көн эчендә без аларның барысын да йөреп чыктык… Ул вакытта Украинадан качаклар агылган иде. Шуларны барлау, аларны урнаштырып, борчуүтенечләрен хәл итү – миңа башлык тарафыннан куелган беренче бурыч шул булды. Инде менә бергә эшли башлавыбызга да биш ел вакыт үтеп бара. Бер мизгел кебек кенә ул еллар! Уйлап куям да… Байтак яхшы эшләр эшләнгән икән бит. Бигрәк тә кече авыллар тарихында ташка баскан эз кебек калырдайлары хәтергә нык уелган. Фердинат Мидхәтовичның әйткән сүзе бар: «Бәләкәй авылларда көн күрүчеләр дә башкалар шикелле яхшы шартларда яшәргә тиеш. Уты, газы, суы, юлы, мәктәбе булсын аларның. Бәхеткә, Президент программалары бу мәнфәгатьләрне хәл итәргә зур этәргеч бирә, вакытында берәмтекләп эшли белергә генә кирәк», – дигән иде ул. Сосновка һәм Казанка авылларында Федераль программа нигезендә спорт заллары, мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен бакчасы булган заманча мәктәп салынгач, кешеләрнең күзләрендә яшь күрдек. Сөенеч яшьләре иде ул. Ә аз керемле гаиләләрне барлап чыгу эшнең башы гына булган әле. Аларны төрле программаларга кертеп, торак хәлләрен яхшырту, минифермалар төзергә ярдәм итү халык күңеленә өмет өстәде. Шундый гаиләләрнең берсендә узган ел әни кеше, килеп: «Безгә яңа уку елына уку кирәк-яраклары булмыйдыр инде, аз керемлеләр рәтеннән чыктык», – дигәч, җитәкче кешенең менә шулай алдан күреп, һәрнәрсәне энә күзеннән үткәреп эшли белүенә тагын бер сокландым.

ЗИРӘК ҖИТӘКЧЕЛӘР...



Шәүкәт ГАТИН, районның Финанс-бюджет палатасы рәисе

– Әлки районы Базарлы Матак авылында туып-үскән олы шәхес ул. Казан финанс-икътисад институтын тәмамлаган. Аны ВЛКСМның Әлки районы беренче секретаре булып эшләгән чакларыннан ук шәп оештыручы дип беләбез. Әлки районында совхоз директоры, Нурлатта авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы, Әлкидә район хакимияте башлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты... Әнә нинди мәктәпләр узып килде ул Чирмешәнгә! Кирәк икән – сабыр һәм түзем, вакыты белән кайнар һәм катгый була белгән атаклы Дәүләтшин ул! Соңгы елларда Чирмешән матур үзгәрешләр кичерә, авылларыбыз төзекләнә, яңара. Район җитәкчесенең халкыбызга хас тырышлыгы һәм тыйнаклыгы, яңалыкка омтылуы, максатчанлыгы иртәгәсе көнебезгә өмет уята.



Рузилә МИНХӘЕРОВА, «Мәдәният» бүлеге башлыгы

– Мин җай чыкканда ашыкмый гына Чирмешәнебез урамнары буйлап йөрергә яратам. Мәдәният йорты, үзәкләштерелгән китапханә, Мемориаль үзәк, Балалар-үсмерләр спорт мәктәбе, Сәнгать мәктәбе, Боз Сарае, ябык трибуналы стадион... Күзне иркәләп, ялт итеп торалар. Урам фонарьлары, күперләр, таш түшәлгән юллар, чәчәкләргә күмелгән ишегаллары, мәйданнар... Болары Чирмешәнгә үзенә бер шигърилек өсти. Ихтыярсыз, кеше кадерен белә торган җитәкчеләр эшли бездә дип куанасың. Һәм, әлбәттә, район башлыгы Фердинат Мидхәт улына рәхмәт сүзләрен җиткерәсе килә. Көндәлек шигырь юллары тезелә:

Ил улына әйләнә дә шәхес,
Ил хөрмәтен күрә хезмәттә.



Ольга МАРКОВА, «Мәгариф» бүлеге башлыгы

– «Чиста авыл синнән башлана». Менә шушы муниципаль акция бөтен авылларны, бар мәктәпләрне кузгатыр дип уйламаган да идек. Балалар ярыша-ярыша макулатура, пластика җыеп тапшыра, үзләре яшәгән урамнарны, тирәяктагы чишмәләрне чистарта башлады. Ә бу акцияне... хакимият башлыгы Фердинат Дәүләтшин уйлап тапты! Балаларда экологик культура тәрбияләүгә, аларга хезмәт тәрбиясе бирүгә бездә аерым игътибар бирелә. Укучылар заманча җиһазландырылган мәктәпләрдә белем ала. Мәктәпләрнең тирә-ягы гөлбакчаны хәтерләтә. Чирмешән аграр техникумы Worldskills стандартларына туры килерлек итеп танымаслык булып үзгәрде. Район башлыгының мәгариф өлкәсендәге актуаль проблемаларны тирәнтен белүе, идарәчелек буенча зур тәҗрибәсе мәктәп, укытучылар өчен зур табыш ул.



Илназ МӨХЕТДИНОВ, «Яшьләр эшләре һәм спорт» бүлеге башлыгы

– Яшьләрнең ял үзәге беркемнекенә охшамаган проект буенча салынган бездә. Район хакимияте башлыгы Фердинат Дәүләтшин үзе тәкъдим итте бу проектны. Чаңгы базасы, күпфункцияле спорт залыбыз бар. Барысы да заманча, креатив. Спорт мәктәбебез дә шундый. Ә күпме спорт мәйданчыклары, яңа спорт биналары төзелде, яшьләргә эш урыннары булдырылды. ГТО нормаларын тапшыру буенча республика күләмендәге ярышлар бездә узу үзе үк дәрәҗә бит! Хоккей турнирлары, мини-футбол, гер күтәрү, волейбол ярышлары... Әнә шулай кайнап яши Чирмешән яшьләре! Чөнки шәп энергетикалы, спортка гашыйк, тынгысыз, янып эшләүче һәм безне дә зур эшләргә әйдәүче Фердинат Мидхәтович бар безнең!



Рушания ӘХМӘДУЛЛИНА, «Халыкны социаль яклау» бүлеге башлыгы

– Ул Чирмешәнгә эшкә килүенең беренче көннәреннән үк районда яшәүче сугыш ветераннары өйләренә ашыкты. Хәлләрен сорашты, гозерләрен тыңлады һәм тиз арада проблемаларын да чиште. Аннары безгә күп балалы гаиләләрнең өйләренә барырга туры килде. Мине иң шаккаттырганы шул булды: Фердинат Мидхәтович кибеткә кереп шоколадлар, тәм-томнар алды да урамда уйнап йөргән малайларга-кызларга таратты. Үзебез барган гаиләләрдәге балаларга да кучтәнәчләр өләште, сәдака итеп акча да бирде. Балаларның ничек шатланганын күрсәгез иде! Аңа ярдәм сорап килүчеләр бик күп. Беркайчан да кире бормый, ничек булса да ярдәм итәргә тырыша. Менә шундый кече күңелле, игелекле, гади һәм ихлас булсын икән ул җитәкче кеше!





Бу язмамның төп герое кадерле әнием Әсхәт Фәридәсе булса да, аны үз чордашларыннан аерып карыйсым килми, чөнки авыл ул – зур бер гаилә кебек. Моның шулай икәнен Фәридәләр урамы озак еллар матур мөнәсәбәтләре белән исбатлап килде.

ӘСХӘТ ФӘРИДӘСЕ

Барлык татар авыллары кебек, безнең Кече Кайбыч та чокырлы бер җиргә урнашкан. Авылның уртасыннан агучы Бәрле елгасының як-ягына төрле төстәге өйләре һәм бакчалары белән тезелеп киткән ике озын урамнан кала, берничә кыска урамы да бар. Шунысы гаҗәп, авылдагы барлык Фәридә исемле хатын-кызлар бу урамнарның бары тик берсендә – тау башына салынган озын урамга махсус җыелган кебек. Бер чор кешеләре булганга һәм күбесе бергә колхоз эшендә йөргәнгә, аларны берберенннән аеру өчен авыл халкы, гадәттә, ирләренең исемен дә кушып сөйли: Якут Фәридәсе, Әсхәт Фәридәсе, Йолдыз Фәридәсе, Фәез Фәридәсе, Әүхәт Фәридәсе, Низами Фәридәсе... Әтисенең яисә әнисенең исеме «ияргән» яшьрәк буын да бар әле: Фәрит Фәридәсе, Исмәгыйль Фәридәсе, Маһирә Фәридәсе...

Әнинең язмышы – аның чордашы булган башка Фәридәләрнеке кебек үк ил күләмендәге авыр елларны үз җилкәсендә татыган буыннар язмышы ул. Җиденче классны тәмамлау белән фермага бозаулар карарга урнашу, айлар буе бушка эшләү, кичләрен ай яктысында чигү чигеп, бирнә әзерләү кебек мәшәкатьләр аның да иң зур хыялын – шәһәргә китеп белем алу теләген кире әйләнеп кайтмаслык итеп еракларга озата. Сугыш алдыннан дөньяга аваз салган һәм рәхимсез сугыш аркасында әтисез үскән балаларның язмышы – гомерләре буенча гел үзләре төзергә, нәрсәдер булдырырга дучар ителгән язмыш иде. Чәчкаб, Кошман кебек күрше авыллардан Кече Кайбычка килен булып килгән Фәридәләр җилкәсенә кайнанага ярау, өйдәге мал-туарны карау, бер-бер артлы дөньяга килгән балаларны үстерү, колхоз эшенә җитешү, көндәлек эшләрне башкару өстенә яңа йорт салып чыгу мәшәкате дә өстәлә. Җәйге челләдә берничә гектар чөгендер утау, салкын көздә бозланган чөгендер алу... Боларның барысын да алар авырсынмыйча, шулай булырга тиеш дип башкара: чөгендер басуында эшләмәсәң, яңа уку елы җиткәндә балаларга мәктәп киеме ничек сатып аласың?! Кышын бозланган базны лом белән казып, силосын капчыкка тутыру, таш кебек капчыкларны җилкәгә салып ташу, трактор арбасына төяүләр дисеңме – болар берсе дә куркытмады Фәридәләр буынын. Берсендә чокырлы юл буйлап кайтканда, трактор арбасы авып, чөгендер тавы астында калгач, бер-берсен үлем тырнагыннан коткаралар. Бу аларны тормышка тагын да ныграк тотынырга мәҗбүр итә. Әлеге юлларны язганда, кадерле әнием янында аның ахирәтләре, самими күршеләре Лотфуллина Зөлфәт, мәрхүмә Абдуллина Әминә апалар да күз алдымда җанлана. Гөлсинә, Гөлсирә, Вәсилә, Фәүзия апалар... Алар да Әсхәт һәм Йолдыз Фәридәләре белән бергә тормыш арбасын сөйрәде.

Нужа белән гомер иткән бу буынның күпчелеге ак яулыклы әбиләр булып, авылыбызга нур таратып, бүген дә матур гына яшәп яталар. Кадерле әниебезгә – тумышы белән Иске Чәчкаб авылыннан булган Яруллина Фәридә Габделхак кызына да 80 яшь тулды. Ил күләмендә булып узган барлык үзгәрешләрне үзенә сыйдырган сигез дистә... Бу гомер эчендә әтиебез Әсхәдулла белән өч бала үстереп, олы тормыш юлына бастырдылар,

төп нигездә калган уллары Рамил һәм киленнәре Зөбәрҗәтнең балаларын – оныкларын тәрбияләштеләр. Аның яшендәге әбиләр кебек, бүген вакытында намазын укып, шигырьдәгечә, «тәмле ашлар пешереп, матур гөлләр үстереп» көн итә әниебез.

Белгәнебезчә, соңгы елларда тормыш шартлары яхшыру һәм медицинаның алга китүе сәбәпле, дөнья күләмендә уртача гомер яше артты. Шулай да кайчак билгеле бер яшькә җиткән кешеләрнең сау-сәламәт булып гомер итүләре турында уйланасың, сокланасың, үзенә гыйбрәт алырлык үрнәкләр эзлисең. Мин дә, урта буын вәкиле буларак, әниемнең тормыш фәлсәфәсен ачыкларга тырышам.

Сау-сәламәт гомер итүнең сере нәрсәдә соң? Тамырларында – әти-әнисе, әби-бабасындадыр. Әниебездәге кешелеклелек, эшчәнлек һәм белемгә омтылыш кебек матур сыйфатлар аның гаиләсеннән күчкән. Октябрь инкыйлабына кадәр Чәчкаб авылында яшәгән һәр ике яктан да бабалары эш сөючән, мул тормышлы һәм укымышлы (сүз уңаеннан: берсенең улы Бөек Ватан сугышы елларында һәм аннан соң да корабльдә капитан булып хезмәт итә) гаиләләрдән саналган. Күп балалы гаилә башлыгы Низаметдин бабай, мәсәлән, җир эшкәртеп, иген чәчеп, урак урып көн итә. Илдә ыгы-зыгылар башланганчы ук көнче кешеләр тегермәннәрен яндыра – бу аларны кулак дип Себергә сөрелүдән саклап кала. Совет хөкүмәте урнаштырылган елларда исә ындырларындагы барлык игенне төяп алып чыгалар. Ә өй тулы – ач балачага... Тырыш булалар – кабат аякка басалар.

Белгәнебезчә, совет чоры кешесе алдына башка кыйммәтләр куелды. Әниемнең укымышлы һәм тапкыр холыклы Закир бабасы авылда хат ташучы булып эшли, бераздан аны оныгы Фәридә дәвам итә. Укуга һәвәслек, бәлки, Закир бабасы янында үсүдән, үзенең дә почтальон булып эшләвеннән күчкәндер. Бүген исә ак яулыклы әниебез күбрәк дини эчтәлекле китаплар укып, алардан үз күңеленә тынычлык таба.

Озак яшәүнең сере хозурлы гаилә учагындадыр. Һәркем өчен гаилә – аны җылытып, көч биреп торучы учак ул. Төрки мифология буенча, ут-очкын чыгарыла торган чакма таш күкнең иң югары катыннан – Күк Тәңре яшәгән җирдән индерелгән һәм шунлыктан ут изге дип саналган. Учак тирәсендә гаилә җыела, ризык пешә. Гаиләнең җылылыгын исә хатын-кыз саклый, һәм ул бу учакны сүндермәскә – балалар тудырып, киләчәк буынга тапшырырга тиеш. Әниебез изге ут белән өебезне дә, йөрәк җылысы белән күңелебезне дә җылытты.
Безне алиһә Һомай кош кебек саклап, үз канаты астында сөеп-назлап һәм тәмледән-тәмле ризыклар белән сыйлап үстерде. Һәр җәй төрле яклардан төп нигезгә кунакка кайтучыларны якты йөз белән каршылады, әтиебезнең туганнарын үзенекеннән дә якынрак күрде, безне дә шуңа өйрәтте.

Сау-сәламәт яшәүнең сере җирне яратуында, бабалары кебек гомерен җир эшкәртеп уздыруындадыр. Борынгы хикәятләрнең барысында да тудыручы, үстерүче һәм ризыкландыручы җир образы юкка гына

Әти-әнинең үрнәк гаилә булуын башкалардан еш ишетеп, алар белән гел горурланып яшәдек.

хатын-кыз – әниләр белән тиңләштерелмәгән бит. Дөнья яратылуда изге туфрак ничек мөһим роль уйнаган булса, кешенең дөньяга килүен һәм нәселләрнең дәвам итүен дә мөкатдәс әниләрдән башка һич күз алдына китерә алмыйбыз. Күңелне борчу биләп алганда, рухи чистарыну эзләп, адәм баласы башын әнисенең тезләренә сала, ерак җирләрдә яшәүчеләрне исә ана күңеле белән бергә туган туфрак та үзенә тарта. (Минем үземә дә бу хис шундый таныш!) Чыңгыз Айтматов, бу ике изге җанны бербөтен итеп карап, бер әсәрен юкка гына «Туфрак Ана» дип атамаган. Әниебез үзенең кендеге белән бәйләнгән җирне гомер буе яратып, үз итеп яшәде. Колхоз кырларында яисә өй артындагы бакчада эшләгәндә күпме кайгы-шатлыгын туфрак белән уртаклашкандыр, күңелен бушаткандыр, яшәргә көч туплагандыр.

Озак яшәүнең сере рухи байлыкта һәм имандадыр. Дин ирегe килгәч, әниебез дә, бик күп чордашлары кебек, үз күңелен иман нуры белән баетты, ислам хакыйкате белән тирәннән танышу аңа яшәүнең башка кыйммәтләрен ачты. Бу, үз чиратында, аңа яңа көч һәм ышаныч өстәде. Тәкъдиргә ышану, кешеләргә шәфкатьле һәм ярдәмчел булу, сабырлык һәм тыйнаклык кебек төшенчәләр аның тормыш фәлсәфәсендә төп маяклар булды. Ислам дине кануннары белән гомер итүче әниебез, язучы Әмирхан Еникинең Акъәбисе кебек, үзендә татар халкының гореф-гадәтләрен дә саклый, аларны балаларына һәм оныкларына өйрәтергә тырыша. Гомумән, дини мәҗлесләрдә мул табыннар янына җыелган олы яшьтәге ак яулыклы апаларны мин Акъәбигә охшатам. Тормыш тәҗрибәсе, рухи байлык, күңелләрендәге аклык-пакьлек йөзләренә якты нур булып күчкән. Уйлап карасаң, аларның катлаулы эчке дөньясында авылыбызның бай тарихы, мәңгелеккә күчкән шәхесләре хакында никадәр кызыклы мәгълүмат сакланадыр. Үткән тарихын белмәгәннәрнең киләчәге юк, диләр бит. Муенсага тезелгән энҗе бөртекләре өзелеп, таралып киткәнче, Рәшидә, Зөлфәт, Фәридә... апаларның күңел дәфтәрләрен кәгазьгә төшереп калдыра алсак иде... Әйе, Яралучының барлыгына һәм берлегенә инану белән бергә, матурлыкка һәм изгелеккә ышаныч та кешене көчле һәм озын гомерле итәдер.

Без бүген файдалы ризыклар белән тукланып, авыр эшләр башкармый гына көн итеп озын-озак яшәргә хыялланабыз. Сау-сәламәт һәм озак яшәүнең формуласы исә, тормыш авырлыклары алдында бөгелмичә, яшәү мәгънәсен башкаларны бәхетле итүдә күргән, һәрвакыт хәрәкәттә булган һәм рухи камиллеккә омтылган әти-әниләребезнең яшәү рәвешендә бит!

Рамилә ЯРУЛЛИНА-ЙЫЛДЫРЫМ.
Төркия.

СИНЛЕ ТӨННӘР, СИНСЕЗ КӨННӘР

Алсу ШАНОВА

* * *

Төтен исе сеңгән кич хәтердә,
Учак яккан идең ул чакта.
Кулларыңнан ялкын үпте синең,
Мин көнләштем шунда учактан...

Кипкән чыбыкларга гына түгел,
Сулган җанга ялкын үрләттең.
Ай карады сиңа якты көлеп,
Төн нурында калды сурәтең...

Учак исе сеңде күңелләргә,
Вәгъдә бирдек бергә янарга...
Пыскып янган учак исе калды...
Юк!
Сөю төсе калды далада.

* * *

Рәмиз улыма

Артыш исе бәрә далалардан,
Куенымда улым ул, нурым.
Ныклап коча яшь кулларым аны,
Аллаһ биргән бәхетнең зурын...

Далаларның
сукмак хәтерен таптап,
Тауларга дип киттек, тауларга.
Күзләремдә бәхетемне күреп,
Җиңел сулый бугай таулар да...

Улым йөгерә зур тауларга таба,
Үзе йөгерә, үзе әйди дә.
Ышанмассың! Бер мизгелдә кинәт
Син хатын да булдың, әни дә!

Һәрбер сүзе ихлас сабыемның,
Һәр көлүе күчә уенга.
Нинди бәхет икән әни булу,
Нинди бәхет балаң булуда!

Шомырт күзле бәхет тулы улым,
Җылылыгы күчте куеныма.
Онытып кинәт хәтта уенын да,
Йокыга талды таулар куенында...

* * *

Гашыйк булып йөрде күпләр,
Ләкин син ярым...
Керфек кагуыңа хәтле
Сөям, Русланым...

Вәсвәсәгә төшсә күңел,
Беләм син барын...
Хилаф уйларымнан йолган
Син бит, Русланым.

Син булганда җылы тоям,
Яңгырын-карын.
Бәхетемә тугансың бит,
Минем Русланым!

Син янәшә чакта тойдым
Мәхәббәт барын.
Күзең нуры миңа булсын,
Җаным – Русланым!

Ялгыз чакта тоясыңмы
Күңел ярсуын?
Яратам сине... Бик яратам –
...Синең Алсуың!

Барыбер

Раббым бүләк иткән өлешме син,
Алтыныммы, әллә көмешме?
Иңбашымнан кочкан ул кулларың
Җисемемә бигрәк килешле...

Син очраткан көннән булды микән
Сагыш төсләренә буялуым?!
Алыштырмас мизгелләрем ул –
Син,
Синең кочагыңда уянуым...

Теткәләнсәм күңел белән бергә,
Калмаса да башка чарам-чамам,
Төн тәрәзгә ут-чаткылар сипкәч,
Синең күкрәгеңә башым салам...
Һәм барыбер
Иң бәхетле калам.

Альбина ГАЙНУЛЛИНА

Карлыган

Сагынырсың инде, диештеләр.
Юксынырмын, диеп килештем.
Авыл башына кадәр озатты
Яулыкның зәңгәрен ябып төн.
Тезмә мәрҗән – йолдыз атыламы,
Чык төшәме керфек очына...
Төшләремдә урам әйләнәм дә,
Кабат чыгам түбән очыма.
Сагынадыр, диеп авыр сулый
Түр бакчада үскән карлыган.
Төшләремдә адашуны
Күреп алган, ахры – таныган.

* * *

Синле төннәр белән
Синсез көннәр бәхәсенә
Катнашмаска өйрәнсәм дә күптән,
Мәңге теленгән бәгырь җөйләре
Торган саен гел сездерә икән.
Синле еллар белән
Синсез минутларның әрҗәсенә
Үксез хыялларны төяп түгәм.
Хисләремне ваклап алданудан,
Синсез калудан өзлегәм.
Синле уйлар белән
Синсез максатларга киртә куеп
Ике бәхеткә юл ярган җирдән,
Туктап-каушап,
уйга калам кайчак...
Шулай яратуым инде
кирәк микән?!

Рөхсәтме...

Рөхсәтме, бервакыт әгәр
Шалтыратсам?!
Язсам сәлам хаты...
Хәлең белеп, тәрәз каксам –
Борчымаммы сине артык?!
Рөхсәтме, бер көн әгәр
Кояш булып
Күзләреңнән үпсәм?!
Ләйсән булып таңнарыңда
Сагнуым пышылдап үтсәм...
Рөхсәтме, вакыт давылын

Алдап, калсам
Яшьлегемдә качып?!
Юлларыңа чыгарга да каршы,
Үзеңне алырга кочып...
Рөхсәтме, җаным, бервакыт
Шалтыратсам...
Язсам сәлам хаты...
Хәтереңә төшеп, иркәм,
Борчымаммы сине артык?!

Физәлия ДӘҮЛӘТГӘРӘЕВА

Шәһәр–Авыл

Шәһәр фатирының читлегенә
Сыймый ирек сөйгән күңелем...
Яшел болыннарга җаным оча...
Тели чиксез авыл киңлеген...

Биек йортның түбәсенә барып,
Шәһәрләрдә офык терәлә.
Тик авылда, офыклардан артта,
Ни барлыгын күңел күрәлә...

Алтынчы кат... Унберенче катлар...
Биекләрдә булды яшәгән.
Җан теләми хәзер башка тормыш,
Җиргә сыенгандай яшәүдән...

Икенче шул авыл... Миләшеңне
Сайламаган юкка сандугач...
Шушы авыл гына сала ала
Саф чыкларын җанга, таң тугач...

Шул тынлыгы гына авылыңның
Әллә ниләр сала җаныңа...
Рәхмәт сиңа, шәһәр, синдә рәхәт.
Тик китәм мин кайтып авылыма...

* * *

Бу чирәм астында минем эзләр,
Ерак балачагым эзләре.
Зәңгәр күктән карый
минем күзләр –
Кер кунмаган сабый күзләре.

Бу тирәкләр әле мине таный,
Үзгәрсәм дә һич танымаслык.
Җилләр исәнләшә назлап кына,
Тиеп кагылыр-кагылмаслык.

Бу болында шул ук кыңгыраулар.
Җир җиләге шул ук хуш исле.
Шул җиләкне нарасый кызыкай
Аунап ятып җыядыр төсле.

Бу чишмәнең җыры шул ук моңлы,
Ничек соң шуны сагынмаслык?!
Барысы да шул ук, тик мин генә
Үземне никтер танымаслык...

* * *

Балакаем, кайтып йөрмә инде,
Туңарсың бит, тышта буран, ди.
Көтә үзе әнкәй, әйткән була,
Әйбәт кенә әле торам, ди.

Балакаем, кайтып йөрмә инде,
Интегерсең, юллар өзек, ди.
Көтә үзе әнкәй, әйткән була,
Ятам әле, балам, түзеп, ди.

Әнкәй җаным, киртәме соң безгә
Узып булмас буран-пычраклар?
Балакаең аңлый, бәхет бит ул,
Сиңа кайта алган бу чаклар.

Рәмзия САДЫЙКОВА

Юрыйм яхшыга

Кояш чыкса, ул көләдер диеп,
Күзләремне салам офыкка.
Җилләр иссә, сәлам китерә дип,
Битем куям җилгә озакка.
Ай яктыртса, ул елмая диеп,
Күзем кысам аңа карап мин.
Йолдыз җиргә атылып төшә икән,
Аңа таба ашкынып барам мин.
Яңгыр яуса гына мин елыймын:
Тамчылары йөрәгемә агалар.
Керфек очларымнан
шул бөртекләр
Кайнар яшьләр булып тамалар.
Давыл купса, юрыйм яхшылыкка!
Миңа язган шушы язмышымны
Уңай якка киредән әйләндерер,
Очраса да, бәлки, каршылыкка!

Әгәр... булсам

Кышлар булсам, күңелеңә
Кар булып явар идем.
Язлар булсам, ташкыннардай
Су булып агар идем.
Җәйләр булсам, йөрәгеңне
Чәчкәгә төрер идем.
Хыял булсам, янәшәмдә
Җитәкләп йөрер идем.
Тормыш юлларын икәүләп
Гел бергә гизәр идек.
Яратуымны барыбер
Күңелемнән сизәр идең.
Гомернең ахырынача
Сөенеп яшәр идек.
Мин дә сине, син дә мине
Бәхетле итәр идек...

Рушания ӘХМӘДУЛЛИНА

Бер сүз

Беркөн мендәремә башым куеп,
Әллә черем итеп алдыммы...
Күзем ачсам, улым янәшәмдә,
Чәчтән сыйпый:
«Әнием, ардыңмы?»

Әллә шушы сүздән күңел тулды,
Белмим, җылысыннан кулының...
Минем өчен борчылганын күреп,
Җилкәсеннән сөйдем улымның.

Бары бер сүз, игътибары белән
Юып алды бөтен арыганны.
Сикереп торып янә эшкә чаптым –
Очам! Сизмим атлап барганны!

Хәтерләмим... әни, без яшь чакта
Хәл җыярга ятып алдыңмы?
Ник әйтмәдем икән шул чагында:
«Әллә, әни, бик нык ардыңмы?»

Әни өчен күп кирәкми икән –
Бер җылы сүз, бары шул җитә!
Әйтеп калу кирәк вакытында,
Гомер бераү, ул да тиз үтә!

Балачак

Миләш җимешләрен җепкә тезеп,
Муенсалар итеп таккан чак.
Син һаман да үзәкләрне өзеп
Искә төшәсең бит, балачак!

Синдә генә чәйләр хуш исле дә,
Ашлар тәмле иде нигәдер...
Мич коймагы, күпереп пешкән ипи
Әле дә булса төшкә керәдер.

Кем сагынмый икән балачагын,
Күрсәтегез берәрсен!
Минем һаман сабый булып өйгә,
«Кайттым!» диеп килә керәсем!

Эшкә генә киткән әтиемне
Урам якта килә көтәсем!
Сары чәчәк, миләш муенсалар
Әниемә бүләк итәсем!

Күңел түрендәге хатирәләр
Онытылмыйча истә торачак.
Бер гамьсез дә, бәхетле дә инде,
И татлы да инде син, балачак!



Аны укучылары да, тамашачылары да бик ярата! Камил Кәримов исемен әйтүгә үк сәхнәдәге кызык тамашалар искә төшә. Көлдерә-көлдерә, үзенең юмористик хикәяләрен укуы, артистлар тормышыннан мәзәк хәлләр сөйләве кемне дә җәлеп итә. Ул булган җирдә – һәрчак шаян сүз, гади генә тоелган хәл-вакыйгалар да кызык бер төсмер ала. Роман-повестьларыннан да нечкә юмор, үзенә бер җылылык, геройларын яратуы бөркелә. «Ком сәгате», «Игезәкләр йолдызлыгы», «Сакау күке»ләр... «Үзеңне бел», «Бәхетле кеше», «Өй артында шомыртым», «Вәгъдә»ләр... Ул әсәрләрдә язучының бөтен тормышы чагыла сыман: су скважиналары бораулаучысы булып эшләү, мәдәният институты, «Яшь ленинчы», «Чаян», «Казан утлары» редакцияләре, Язучылар берлеге, ТВ, эстрада... Боларга өстәп, аның атаклы Шәле егете икәнен дә әйтеп үтсәк... Тукай премиясе лауреаты портретына менә шундыйрак штрихлар.
Ә бүген язучының матур юбилее! Котлыйбыз! Иҗат уңышлары телибез!



Камил КӘРИМОВ

КУЕН ҖЫЛЫСЫ

Хикәя

Бу дөньяда эч сереңне сөйләргә тилмереп йөргән чаклар да еш була икән. Бер уйлаганда, күрше-тирәңдә дә, эшеңдә дә дуслар гына инде, сөйлә сереңне, рәхәтләнеп тыңласыннар... Сернең серлелегенә карап кына сөйлибез дә бугай: дусларыбызны, таныш-белешләребезне очратсак, эндәшмичә үтеп китмибез, сер сөйлибез, сер алабыз; үз серебезне сакласак, кеше серен чишеп булса да әңгәмәдәшебезне куандырырга, шаккаттырырга тырышабыз. Еш һәм бик еш кына, адресы ялгыш язылган хат шикелле, үз серебез үзебезгә кире әйләнеп тә кайта...

Ә син менә вокзалга бар. Берәр буш урын тапсаң, кил дә утыр, сабыр гына көтеп тор. Эндәшмичә калмаслар. Курыкмыйча ачыл син боларга, вокзалдагы күршең барысын да күтәрә. Дөрес, сүз башладың исә мондагы һәр кеше тизрәк үз зарын сөйли башлый. Сөйләр өчен сиңа да чират тияр. Ул арада инде соңга калган поездлар да килеп җитә, һәм, берегез – әшрыйк, икенчегез мәшрыйк якка дигәндәй, китеп тә барасыз. Сөйләгән сүзләрегез хат булып та, таш булып та әйләнеп кайтмас.

Эш урыны юлда Фәйзелнең. Заводны кирәкле җиһазлар, чимал белән тәэмин итү өчен тырыша ул; күрше шәһәрләрдәге заводларга заказлар илтә; тегесен эзли, монысын таба, алыштырасыны алыштыра. Эшенә күрә танышлары да җитәрлек Фәйзелнең – юлга чыккан саен яңалары арта. Әлбәттә, һәр танышка да дус булып калырга диелгән әмер юк, күбесе әнә шул бер күреп сөйләшкән таныш килеш кенә бераз истә торган була да, әкренләп, хәтер өеме арасында бөтенләй күмелеп кала. Еллар үткәч кабат очрашсаң да, алар белән инде яңадан танышырга туры килә. Иренми Фәйзел, кирәксә ярты көн вакытын да кызганмас – тик юлга чыккач серле танышлар тел шартлатып тыңларлык мажаралар гына сөйләсен аңа. Юлда күңелсезләнмәс өчен ул – күргәненең туганы, күрмәгәненең – дусты, бабайларның – яшьтәше, ханымнарның мәхәббәте булырга да әзер.

...Фәйзел ике ягындагы күршесен дә җентекләп күзәтеп чыкты: берсе әбиләр яшендәге хатын-кыз – сентябрь башы гына дип тормаган, сырма киеп, шакмаклап сугылган калын шәл ябынган, ярты капчыклы биштәренә таянып, рәхәтләнеп йокымсырый. Юк, дип уйлап куйды Фәйзел, бу түмгәктән ни он, ни йон, ни запчасть – танышу ул һәрвакыт җимеш бирергә тиеш. Менә икенче яктагы күршесе болай күрер күзгә эшлекле генә кеше, ахрысы. Ыспай гына киенгән, күзлекле, галстуклы дигәндәй. Ике йозаклы портфелен алдыннан төшермичә, «өф!» итеп кенә тора. Иптәшләре дә, хатыны-мазар да янында юк. Ир кеше ялгыз гына юлга чыкса, бел дә тор: ул командировкада, ә командировкага теләсә кемне җибәрмиләр.

– Бу вокзал тирәсендә кеше бер дә бетеп тормый, – дип башлады сүзен Фәйзел, күршесен сөйләндерергә теләп. – Карасана, нихәтле эшсез әрле-бирле чемодан ташый. Ярый, хет ашыгучылары да бардыр инде. Ә менә болары, – диде ул, хатынының алдына башын куеп, эскәмиягә



Рәсем: Наталья Васильева

сузылып яткан бер агайга таба ымлап, – мөгаен, тәүлекләр буе шушында аунап ятадыр... Әгәр мондагы халыкны поезд көткән арада гына эшкә кушып торсаң, ә?! Вокзал белән янәшәгә берәр комбинат салып куясы да эшләтәсе үзләрен. Билет бәясен дә каплар, вакыт та тиз узар иде.

Гадәттә, Фәйзелнең бу фикере һәр яңа танышны елмайта торган иде. Әлеге кешенең генә кырыс йөзе һаман үзгәрмәде.

– Минем эшләп торырга вакытым юк, тиздән поездым килеп җитә, – дип кенә җавап бирде ул.

– Кайсы якларга юл тотасыз? – Фәйзел, кәприз ханымнар белән сөйләшкәндәй, тавышын йомшартты.

– Саратовка.

– Эш беләнме?

– Юк. Язмыш кызык итте бит мине: бер хатыным Казанда, икенчесе – Саратовта. Икесендә дә берәр балам бар. Тәки йөрим менә шулай ике шәһәр арасында.

– Ә син билетыңны югалт та Казанда кал йә, киресенчә, Саратовтан чыкма.

– Әйтергә генә җиңел. Уйлап карасаң... – дип, абзыйның ачылып китәргә исәбе бар иде дә, тик Фәйзел күңеленнән генә кул селтәде: ир белән хатын турындагы хикәяләрнең һәммәсенең дә эчтәлеге бертөрле.

Ул арада ике ханым үтеп бара иде, Фәйзел күршесеннән гафу үтенде дә аларга иярде. Ханымнарның берсе бик нык ашыга кебек, озата килүе дә итагатьлек өчен генә бугай, дустын поезд туктыйсы платформага алып килгәч, үзе тиз генә олагырга ниятләде:

– Менә, – диде ул китәр алдыннан, – алтынчы вагон шушы тирәдәрәк туктар, үпкәләмә инде, вакытым юк, поездың килгәнче көтеп тора алмыйм.

Ханымнарның исемнәрен дә ишетеп калды Фәйзел: озата килүчесе – Сания, ә китүчесе, актан киенгәне – Роза икән. Тагын Фәйзелне кызыксындырганы – алтынчы вагон дигән сүз булды. Аныкы да алтынчыда лабаса. Шушы кызыксыну, Роза белән саубуллашып киткән Санияне эзәрлекләп барырга һәм аулаграк дигән урында аның юлына аркылы төшәргә, иптәш кызы турында сорашырга мәҗбүр итте...

Ярты сәгатьләп вакыт үтте.

Фәйзел әйләнеп килгәндә почта поезды килеп туктаган иде инде.

Алтынчы вагонга кергәч, Фәйзел үз урынына утырырга ашыкмады, башкаларга сиздермичә генә ак күлмәкле ханымны эзләп тапты. Вагон эчендә һәркем урнашып, җайлашып беткән иде инде. Бер әби генә «ак ханым» тирәсендә зарланып тора:

– Вәт тамаша, билетны өске катка биргәннәр, ни хәл итеп менепләр ятармын икән?!

Ә Фәйзелгә нәкъ шул гына кирәк тә.

– Әбекәй, пожалысты, менә минем урынга килегез, – дип, әбигә икеләнерлек вакыт та калдырмыйча, билетларны алыштырып куйды, һәм шулай итеп Фәйзел, шакмаклы юл сумкасын тотып ак ханым янына килеп басты.

– Роза! – Фәйзел бу исемне шундый итеп әйтте, хәтта ак ханым, янындагы ирне танымаса да, аның, һичшиксез, иске таныш булуына ышана иде.

– Әйе, мин Роза, – диде ак ханым оялып кына, – тик сезне хәтерли алмыйм.

Бу оялу ир кешенең шушылай тилмереп, йотлыгып һәм бер үк вакытта сөенеп каравыннан кыенсынып калу гына түгел, ә Фәйзелне исенә төшерә алмаудан уңайсызлану да иде. Ак күлмәгенең ачык изүеннән сафлык бөр-



кеп, кызыктырып торган тәненә алсу төс йөгерде. Әйтерсең аңа әле Фәйзелгә кадәр бер генә ир-атның да күзе төшмәгән булган.

Фәйзел җавап бирергә ашыкмады. Хатын-кыз дигәнең җавапсыз калган сорауларны бик өнәп бетерми, җавап тапмый торып тынычланыр дип уйлама да. Кем-кем, ә Фәйзел инде моны яхшы белә.

Роза поездның кузгалганын сизмәде дә. Башка вакытларда ул телевизор экранына ябырылган нарасый төсле хирысланып тәрәзәдән карап барыр, кул болгап калган озатучыларның аерылу сагышларын күңеленнән генә кичереп карар, тәгәрмәчләр тыкылдаган саен ерагая барган Казан каласына үзе дә: «Сау булып тор!» – дип пышылдап куяр иде. Юк, бүген болар барысы да онытылды, ник дисәң, каршысында күзгә-күз карашып, серле билгесезлек утыра.

– Танымавың да гаҗәп түгел, унбиш ел вакыт үткән...

– Унбиш ел элек мин авылда яши идем әле.

– Салкын Чишмәдә. Карале, ул чишмәгез һаман шулай шаулап агып торамы?

– Әйе... Кызык, сез мине чынлап та беләсез. Мин генә хәтерләмим. Хәер, иртәдән кичкә кадәр күз алдыбыздан күпме кеше чагылып үтә, барысын да ничек искәреп каласың?.. Йөдәтмәгез инде, әйтегез, кем сез?

– Син авылга бер чибәр кыз идең. Сиңа күз тутырып караган өчен генә дә кайбер егетләр бер гаепсезгә тукмала торган иде.

– Анысы дөрес. Клубка гел абыема ияреп кенә килә идем.

– Сез, салкын чишмәләр, Аппакай авылына йөрдегез, анда клуб та зуррак, егетләре дә шәһәрчәрәк. Ә мин читтән генә күзәтеп торам да, шуның белән юанам.

– Якын килергә курыктыгызмы?

– Мин курка белмим. Хәзер дә менә үземне сездермәскә кирәк булгандыр. Унбиш ел буе ничек түзгәнмендер, белмим, тик хәзер сөйләшәсем килә, сине бүтән очрата алмам төсле.

– Исемегезне дә белмим, ичмасам.

– Фәйзел мин.

– Фәйзел, Фәйзел... Фәйзел... Юк, исемә төшерә алмыйм.

– Аппакайда кошчылык комбинаты төзегән идек. Тирә-яктагы колхозлардан бик күп җыйдылар безне. Ул вакытта йомыркадан чыккан әтәчләр дә бүген унбиш яшь тутыргандыр инде... Эштән кайткач, арыганнарны да онытып, Аппакай юлына чыгып басам – хыялланып-хыялланып сине күзәтәм.

– Килеп дәшәсегез калган. Егетләрем арасында алай артык өзгәләнеп сөя белүчеләр юк иде.

– Исәнме, Роза, мин сине яратам, дисәм, мөгаен, «мине бик күпләр ярата», дип кенә җавап бирер идең әле... Гомерем буе сиңа охшаган кешене эзләдем.

Ярату сүзләрен кем генә яратмый икән! Роза да йотлыгып тыңлады. Фәйзелгә караган саен күңеле сөенде. Роза ир алдында үзен бурычлы итеп санады... «Элеккеге игътибар юк инде хәзер миңа, олыгаям, ахрысы, трамвайларда яшьләр урын да бирә башлады», дип, өлкәннәр гаме белән яшәүгә күчкән ханым мәхәббәткә авазсаш сүзләр ишетә бүген. Ялгызлыкта үткән һәр көн үзен нык сиздерә, һәм менә бүген аның янында Фәйзел исемле өмет. Хәер, ниткән өмет булсын ди инде, юлаучы гына ич. Розаны да кем беләндер бутавы гынадыр. Бәлки, кайда ачык күңел күрсә, шунда бәреп керә торган берәр әрсез генәдер. Тәүбә, тәүбә, анысы кирәкми...

– Чәч толымым элек нинди иде, әйтә аласызмы? – Роза, үз соравыннан үзе оялып, читкә борылды һәм җавап көтте. Артык кыен түгелме бу сорау, дөрес җавап бирә белерме? Ялгышмаса гына ярар иде. Күпертеп таралган куе кара чәчләремә сыный карасаң, кисеп ташланган толымымның озынлыгын чамалап та әйтә алырсың...

– Җиргә тиеп тормаса да, тел шартлатып үтәрлек иде...

– Дөрес. Клубка киеп чыга торган чәчәкле ак күлмәгемне хәтерлисезме?

Поезд әкренләп төнгә килеп керде. Тәрәзәгә якынайган урманнарда карурман төсе...

Пассажирлар урын-җир иплиләр. Тәгәрмәчләрнең тигез тыкылдавы һәркемне йоклатыр сыман. Пышылдашып кына сөйләшер чак якыная. Ә Розаның бүген көчле сүзләр ишетәсе килә.

Тамбурда көзге төн җиләслеге.

Розаның иңендә Фәйзел пинҗәге.

Ике башка йөз төрле уй.

– Ак күлмәгең сиңа бик килешә иде.

– Ул миңа бик килешә иде.

– «Иде дә иде», дибез. Кайда эшлисең, Роза? Нәрсәләр майтарасың?

– Сөйли калсам, тыңлап арырсыз. Болай да инде күзләрегездә йокы бар.

– Минем күзләр гел шундый ла ул, игътибар итмә.

– Ирдән уңмадым. Бер кыз үстердем, техникумга укырга керде. Баласын очырган кош төсле, җиңел сулап ялгызым гына ял итеп кайтырга исәп.

Сүз уңаеннан гына «һәр кешенең бәхетле булуын телим», дип купшыланырга яратса да, Розаның ирсез яшәве Фәйзелнең өметен азындырды, хәтта куандырды да бугай.

– Роза, син бер дә үзгәрмәгәнсең. Мин әле дә сокланам сиңа, ә соклану ул – ярату билгесе...

– Мондый сүзләрне ишетүе рәхәт. Сөйлә, Фәйзел, сөйлә.

– Хат язасым килә.

– Хат... Хат очрашу бит ул – берең сөйли, берең тыңлый.

– Кая языйм соң, адресыңны әйтәсеңме?

Фәйзел, Роза иңендәге пинҗәкнең кесәсенә тыгылып, куен дәфтәрен алды. Ул моны шундый тиз эшләде, кесәгә үрелгәндә Розаның куен җылысын да тоймый калды. Әйтә-әйтелешкә үк урам исемен, йорт номерын да язып алды. Тиз язды, әйтерсең бер мизгелгә генә тоткарланса да, Розаның кире уйлавы мөмкин иде.

Хатларга гына языла торган аерым сүзләр бар, телдән әйтеп бирүе кыен аларны. Розаның әнә шул зарыгып көткән очрашуларга тиң хатлар алганы юкка яшьлекнең

үзе кадәр гомер үткән инде, һәм менә яшьлек тагын әйләнеп кайтты. Аккан сулар кире кайтмый, дип җырлыйлар тагын...

Киноларда күреп, китаплардан укыса да, очраклы күренешләргә юлыккан кешеләргә шикләнебрәк, ышанмыйчарак карый иде Роза. Фәйзел белән очрашу да очраклы хәл түгелме соң?! Бәлки, болар һәммәсе дә алдавыч төш кенәдер. Була бит шулай: әллә кайдан гына кошлар сайравы ишетелеп китә – урманда да, болында да кебек. Куышып йөрисең, ул сине тотып ала, иреннәреңә орынып үткәндәй тоела. Уянсаң, куеныңда исерек ир бөгәрләнеп ята... Һай, татлы төшләрнең бигрәк тансык чагы!..

– Фәйзел, ачуланмасагыз, сорыйм әле, ник соң моңарчы ялгыз яшәдегез? Ирләргә гаилә яңартуы җиңел ич...

– Кичә өйләнсәм, бүген нишләр идем, сиңа читтән генә кызыгып карап утырыр идемме? Ир кеше өчен иң зур бәхет ирек бит ул. Минем менә теләсә кайсы чибәркәйнең аяк астына егылырлык ирегем бар.

– Ничә тапкыр егылдыгыз инде? – дип ялт кына сорап куйды Роза, шаяртудан бигрәк, Фәйзелнең «тел төбен» аңларга теләде.

– Блокнотымда ничә адрес булса, шулхәтле, – диде Фәйзел комарланып һәм шул арада болай мактануның тиешсезлеген аңлап, сүзне кирегә борырга теләде, – Ә блокнотым чип-чиста!

– Әйтегез әле, дөресен генә әйтегез, сез бит мине белмисез, әйеме, бу әкиятне уйлап кына чыгардыгыз?!

– Хатын-кыз белән танышу үзе бер сәнгать бит ул, – диде Фәйзел, Розаның күзенә туры карарга куркып.

– Ялган сәнгатьне җенем сөйми!

Шушы берничә сәгать эчендә күз алдында әкияттәгедәй сихри шәһәр калкып, ул шәһәрдә Фәйзел белән Роза өчен дә бер йорт корылган иде; тәрәзәләре якты, ишеге киң – атлап керәсе дә гөрләшеп яши генә башлыйсы. Бактың исә, шәһәре дә, йорты да балалар мәйданчыгындагы төсле комнан гына өелгән булган икән. Җимерелде дә төште, җир белән тигезләнде.

Роза, үзенә-үзе сораулар яудырып, аларга җаваплар да табарга тырышты. Адресым нигә кирәк булды икән? Хат язар өченме? Юк, Фәйзел хат язарга ярата торган кешегә охшамаган. Эш юктан, кызык өчен генә хатлар язышырга унҗиде яшьлек чагыбызмы? Яшьлек дигәннән, Фәйзелнең кайчандыр безнең якларда булуы, миңа кызыгып йөрүе кебек үк, чеп-чи ялгандыр әле. Ирләр, тол хатын икәнеңне белсәләр, сөйләндереп карар өчен әллә ничә төрле ысулын табалар. Салкын Чишмәдән икәнлегемне дә берәр ничек ишетеп кенә калгандыр... Сания озата килгән иде, аннан сораштыргандыр әле, җаен да тапкандыр, шундый әрсез иргә охшаган бу. Ә Сания ике дә уйламас. Мине күптәннән сөяркәле итәсе килә иде инде аның. Чәчең озын иде, дип әйтүе дә, шикәргә карап, баллы ул, дигән кебек кенә – чәч үсәр өчен бирелгән, кыска чәчне кем киссен?! Ирдәге хатын булсаң да, ялгыз чагыңны туры китереп, тәрәзәңә чиртеп үтәргә иренмәс. Абау, нинди чиркангыч кеше. Адресымны ник алганын да беләм хәзер: тамагы туйган эт тапкан ризыгын күмеп куя, карыны ачкач эзләп ала. Фәйз... бу хәсис тә шундыйдыр, исемен дә искәрәсем килми хәтта. Их, блокнотын ачып карарга, хатын-кызлар адресы белән тулган микән?!

Розаның җаны өшеде, гүя әкренләп куен җылысы суынып бара иде. Гомердә булмаганны, йөрәге авырткандай тоелды.

Роза, кинәт кенә яшерен бер карарга килеп, сагаеп калды: ничектер җаен табып, блокноттагы адресны юк итәргә...

Роза, күзен йомса да, Фәйзелнең өске ятактан аңа каерылып карап барганын тойды. Карасын әле, карасын... Фәйзелне сынарга теләп, одеялны читкә этәрде, җәймә генә ябынды, болай юка аклык аша нәфис сынның бөтен барлыгы беленеп тора.

Фәйзел песи җитезлеге белән ятактан төште дә, аяк очларына гына басып, Розага якынайды, аның ачык муенын үбәргә теләдеме, әллә тән җылысын тоеп карарга ниятләдеме – белмәссең. Тик Роза, ир кеше сулышыннан оеп, чирканып куйды һәм, йокы аралаш кына борылгандай, мендәргә йөзтүбән капланды. Аяк тавышларын ишеткәч кенә Фәйзелнең тамбур ягына таба киткәнен аңлады.

«Адресым язылган блокнот якында гына!» – шушы тынгысыз уй Розаның бөтен холкы-акылы белән идарә итә башлады... Ул – кесәдә. Алырга. Бер мизгел җитә. Әмма бит кеше кесәсенә керәсе!.. Ләкин ул ир синең өметеңне алгысытты. Намуссызга җәза бирү – намус эше. Озак уйлап икеләнеп ятсаң, Фәйзел килеп җитмәгәе... Ул кесәдә. Алырга. Бер мизгел...

Роза, урыныннан торып, күршеләрен күзәтеп чыкты: йоклауларына тәмам ышангач кына, өске ятакка үрелеп, элгечтәге пинжәкнең куен кесәсен эзләп тапты. Куен дәфтәренә кул тигәч, әллә куркудан, әллә артык сагаюдан маңгаеннан чеметтереп-чеметтереп салкын тир бәрде. Хәтта күңеле болгангандай булды. Тиз генә актарып, йөзәрләгән хатын-кыз арасыннан үз адресын ертып алды. «Абау, усаллык эшләве дә кыен икән, бөтенләй хәлдән тайдым», – дип уйлап куйды ул һәм башка берни дә уйламаска тырышты. Йокларга яткач та башыннан ук бөркәнде: Фәйзелне күрсә, гафу үтенмичә түзә алмас кебек иде...

Вакытның тизрәк үтүен теләгәндәй, поезд тизлеген арттырды.

***

Фәйзелнең ятактан сикереп төшүе сискәндерде Розаны: «Әллә сизде микән?» Станциягә килеп җителгән иде. Фәйзел ашык-пошык киенде дә аерылышу газаплары кичермичә генә саубуллашып чыгып китте.

Роза, сиздермәскә тырышып, Фәйзелне күзәтте. Тәрәзә экранында ватык телевизордагы кебек тавышсыз-тынсыз аксыл сурәтләр – куе томан таңны бастырып куйган. Әнә «теге», ялтыравык ботинкасына карап, перрон буйлап йөренде дә пычрак юлга төшеп, томан эченә кереп югалды. Шуны гына көтеп торгандай, поезд кузгалып китте. Роза, тәгәрмәчләр теркелдәвенә сөенеп, мендәргә ауды да кулын күкрәгенә куйды.

Сул күкрәк астында ярсынып-куанып Йөрәк тибә иде.

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Гомер бертуктамый алга чаба. Менә быел да яңгырлы яздан соң, җәйгә аяк бастык. Җир өстендә баш калкыткан яшел үләннәр, койма буендагы кычытканнар кай арада буй җиткергән диген?! Кычыткан диюгә, бер вакыйга искә төшә минем.

...Ул көнне мәктәптән вакытында өйгә кайтмаган кызыбызны эзли-эзли, уттан суларга төшкәнебезне бүгенгедәй хәтерлим. Шалтыратып сорамаган танышбелеш, укытучы, классташлары калмады... Юк бала! Телефоны да «не доступен». Эзләп-эзләп тә таба алмагач, полициягә хәбәр итәрбез дип торганда бергә эшләүче хезмәттәшем кесә телефонына шалтыратты. «Кызың безнең ишегалдында таганда утыра!» – ди. Белмим, аяк җиргә тиде микән ул чакта. Йөгергән уңайга аяк астында үсеп утырган кычытканны йолкып алганым гына истә. Күрәсең, кычыткан ул чакта балама яхшы «сабак» биргәндер, аның шактый вакыт: «Әни, кар яуса, кычыткан бетәр иде, әйме?!» – дигәнен бүген дә елмаеп искә алабыз.

Кычыткан үзебезгә дә балачакта шактый эләккәләгәндер инде ул. Балалык белән алары истә калмаган. Авыл баласы өчен ул гадәти үсемлек санала, чөнки бакчада да, койма кырларында да шактый үсә иде. Әле шул кычытканны чиләкчиләк урып алып кайтып, бәбкәләргә, тавык-чебешләргә махсус улакларда тапап куя идек. Аннан әни аны он, пешкән бәрәңге белән кушып, кош-кортларга җим ясап бирә. Ә ул кычыткан ашының тәмлелекләре! Авыл җирендә туып-үсеп, бер генә тапкыр булса да кычыткан ашын ашап карамаган кеше сирәктер. Язның иң беренче витамины ич ул!

Бакчада баш төртергә дә өлгермәде, быел да җыеп алып, ашын пешереп ашадык әле. Ашның рецепты да гади – кем ничек тели шулай пешерә. Мин үзем ит кайнаган шулпага салып пешкәнен яратам. Шунда бәрәңгесен, суганын турап, кишерен кыргычтан кырам, аңа бераз озынча токмачны ваклап салам һәм пешеп чыгар алдыннан гына бер йомырка туглап, шулпага кушам. Яшел суганнар турап ашасаң, телләрне йотарлык була. Ә инде ашны ачык һавада – утын өстенә казан асып та пешерсәң, тәме икеләтә арта!

Кычыткан сугыш чоры балаларын да ачлыктан коткарган. «Ул елларда үлемнән шул кычыткан, балтырган, кукы, юалар саклап алып калды», – дип искә ала әнием.

Әле тагын шунысы хәтердә сакланып калган, без мәктәптә укыганда авыл фермасындагы яшь бозауларга кычыткан җыю бар иде. Без балалар да бу эштә бик теләп катнаша идек. Кычыткан тапшырган өчен күпмедер акча да түләгәннәре хәтердә. Күбрәк акча алыр өчен арыш капчыгын кычыткан белән шыплап тутырып, аны велосипедның артына беркетеп, җыю пунктын көнгә берничә урый идек. Вакытны да файдалы үткәрәсең, кесәгә дә бераз «тама» иде!

Бакчада үсеп утыручы менә шундый гади генә кычыткан балачак хатирәләренә алып кайтты әле, үзенең файдалы да, тәрбияви дә якларын искә төшерде. Гади генә булса да, бик тә үзенчәлекле икән ул кычыткан!

Гөлчәчәк САДРЕТДИНОВА.
Азнакай шәһәре.

Гомерем буе Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле булып яшим мин. Җиде айдан туып, ДЦПлы булсам да, 5 яшькә кадәр тәпи йөреп китә алмасам да, Аллаһка мең шөкер: үзем кебек кеше белән гаилә корып, шәфкатьле, миһербанлы балалар тудырып, аларны исән-сау тәрбияләп үстердек.

Һәр көн иртән торып баскач, үземнең, ирем Ринатның, балаларымның исән-сау булганына шөкрана кылам. Яныбызда мәрхәмәтле, яхшы кешеләр бик күп. Ярдәм итәләр, аларга рәхмәтләр яусын.

Фото: www.pixabay.com

Менә бу карантин игълан ителгәннәре башлангач, «Ярдәм» мәчетенең инвалидларга көн саен кайнар ашлар өләшүен ишеттек. Шалтыратып заявка биргән идек, икенче көнне үк килеп тә җиттеләр.

Шул аш китерүчеләрне көн саен кунак көткән кебек көтәм. Алар килгәч, кызым Алсуның ничек шатланганын күрсәгез сез! Карантин булгач, балам ике ай өйдә утырды. Бер җиргә бара да, иптәшләре белән уйный да алмады.

Менә минем 8 мең сум пенсиям бар. Кызыма да анысын, монысын алырга кирәк. Ризык алмасам, ул акчаны даруга тотам. Алар да кыйммәт хәзер.

Ә волонтерлар шулкадәр мәрхәмәтле! Алар да кемнәрнеңдер акыллы, газиз балалары бит инде. Шуларга карап сөенәм. Елый-елый рәхмәтләр әйтеп: «Исән-сау эшләгез», – дип озатып калам. Япь-яшь кенә булсалар да, бик итагатьле, матур итеп сөйләшәләр, хәлләребезне белешәләр. Безнең өчен бу бик мөһим. «Ярдәм» мәчетеннән ярдәм килә башлагач, ризыкның – Аллаһы Тәгаләдән икәнлегенә, Аның ризыгыбызны күбәйтүенә тагын бер кат инандык. Ашарга китергән саен утырып елый идем. Шатлыгымнан... Безгә Аллаһы Тәгалә көтмәгән җирдән бирде. Рәхмәттән башка сүзем юк. Бу катлаулы чир йөргән вакытта кешеләр уңай яктан ачылды, игелек кылырга тырышучыларның күп икәнлеге күренде.



Тилмереп яшәүчеләр бик күп бит. Без, аз булса да, бәрәкәтле булганына сөенеп яшибез. Минем бөтен нәрсәм бар. Башкаларга да ярдәм итүче кешеләр күбрәк булсын иде!

Әле июнь башында безнең терәгебез – 22 нче заводта токарь булып эшләүче улыбыз Радикны Саратов якларына армиягә озаттык. Исән-сау хезмәт итеп кайт, улым, күз нурым!

Илүсә ШӘЙХЕТДИНОВА.
Казан.

Кадерле редакция!

Минем бабамның бабасы – Кутуев Зибу (руслаштырып, Зиновий дип атаганнар) Вәлитович 1896 елда Пенза губернасының Краснослободск өязендәге Аксель волостена караган Тархан авылында (хәзерге Мордовия) дөньяга килә. 1895 елда туган абыйсының исеме – Хәлим, энекәше дә бар дип беләбез, әмма аның исеме төгәл билгеле түгел (Фәхретдин булырга мөмкин), якынча 1905 елгы дип чамалыйбыз. Әтиләре – Вәлит Рафекович Кутуев 1857 елгы булырга тиеш. Олы абыйларын язмыш Себер якларына илтеп ташлаган, мөгаен, сөргенгә җибәрелгәннәрдер.

Зибу бабабыз, Казанга күченеп, сәүдә белән шөгыльләнгән, үз йорты һәм кибете булган. Ул шул сәбәпле сөрелгән дигән фараз бар. Сөргендә Кемерово өлкәсендәге Мария районының Суслово авылына барып урнашканнар. Анда да сәүдә эшен башлап җибәргәннәр, баеп киткәннәр, кибетләр, сәүдә мануфактуралары тотканнар. Ләкин аларны кабат кулга алганнар. Зибу бабабыз ун елга Бамлаг төрмәсенә утыртыла. Ә Хәлим кулга алынмыйча кала, НКВДдан качып яши.

Кемероводагы туганнарымны эзләп тапкач, шуны белдем:



Хәлим бабай, кече энеләре турында – Америкада мөһаҗирлектә дип, ә үзләрен морзалар токымыннан, дип сөйли торган булган.

Кызганыч, нәселемнең тарихын бик начар беләм. Шуңа күрә журнал укучыларына да мөрәҗәгать итәсем килә. Безнең нәселгә караган теләсә нинди мәгълүмат өчен дә бик рәхмәтле булыр идем. Бигрәк тә Кутуев Вәлит Рафек улы, аның гаиләсе турында беләсем килә.

Телефон номерым:
89923418400 (WhatsApp, Viber, Telegram)
RMUS@MAIL.RU

Адрес: 620103, Свердловск өлкәсе, Екатеринбург шәһәре, Умельцев урамы, 11 нче йорт, 264-265 нче фатир.
Ренальд Кутуевка.

Фотода: Эшләпәле ир – 1895 елгы Кутуев Хәлим Вәлитович.

Ренальд КУТУЕВ.
Свердловск өлкәсе,
Екатеринбург шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

Ятим елар – җир-күк елар... Халык шулай ди. Бу язманы укыганда күзгә яшь тулган, тамакка төер тыгылган урыннар очраса да, күңелдә аларны кызгану, җәлләү хисе генә калыр дип уйламыйм. Юк, аларның берсе дә мескен түгел. Алар мескен булып яшәми! Инде ничә еллар күрше редакцияләрдә, янәшә эшлибез. «Татарстан» журналының чыгарылыш мөхәррире Фәридә ӘХМӘТҖАНОВАны шактый якыннан беләбез. Сеңлесе Айсылу белән булган мөнәсәбәтләре дә күз алдыбызда. Гаиләсен, улы белән кызын өзелеп яратуын күреп, сизеп торабыз, абыйларын ничек кайгыртып торуыннан да хәбәрдарбыз. Караган саен – сокланабыз! Кечкенә генә кыз зур гаиләне таратмыйча ничек саклап калган? Бу язма шул хакта. Ачыктан-ачык сөйләшәбез.



СЫГЫЛГАННАР ГЕЛ СЫНМЫЙ



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Их дигән вакытлар, минә кайчан әни кирәк икән дигән чаклар, зиратка менеп елаулар – барысы да булды инде...

– Балалар, әниегез үлгән...

Әти кабинага менеп утырды да башын рульгә салды... Бу күренеш әле дә күз алдымда. 1976 елның 30 мае иде ул. Без ул көнне бакчада бәрәңге утырта идек. Әти йөгереп кайтып керде дә: «Җыенызгыз, Карилегә барабыз!» – диде. Кунакка чиста киемнәрдән баралар бит – яңа халатымны кияргә кермәкче булам. «Фәридә, вакыт юк!» – ди әти. Чаллы авылы тирәсендә каршыбызга машина чыгып, юлны бүлде. Әти бик тузынып төшеп киткән иде дә, безгә шушы хәбәрне китерүчеләр булган икән... Әнине күрергә өлгермәдек...

Мин белгәндә әни авырый иде инде безнең. Йөрәк... Аз гына нидер эшләсә дә, сулышы каба, тыны кысыла. Аңа җиңелрәк булсын дип, әти авылда иң беренче булып өйгә су кертте. Мин икенче класска барыр алдыннан, 27 август көнне әнине больницага алып киттеләр... Абый белән икәү аның мәктәп формасын юдык. Һаман саен кара чыга. Күрше Бибисара нәнәй кереп: «Балалар, туктагыз, пычрак түгел бу, аның шулай төсе чыга», – димәсә, тагын ничә кат юган булыр идек әле?! Әни тугыз ай эчендә өйгә өч-дүрт тапкыр гына кайтып торгандыр: больницадан чыкмады да. Операция ясарга тәкъдим иткән булганнар, ул баш тарткан. 19 апрель көнне дәү әнигә аны «үлде» дип хәбәр иткәннәр. Барса, әни исән! Әмма хәле авырайган булгандыр инде, шуннан соң ул аны үзенә – Олы Карилегә алып кайтты. Ә 19 апрель безнең өчен барыбер хәсрәт алып килде. Тагын нәкъ бер елдан...

Ул көнне, юлдан кире борылып кайттык – әтинең безгә әнинең мәетен күрсәтәсе килмәгәндер инде. Сеңлем Айсылу бу вакыт дәү әниләрдә иде. «Әни нигә тормый?» – дип аптыраткач, аны да күршеләргә алып чыгып киткәннәр. Яңа бантик, гольфилар биргәннәр...

Икенче көнне әнине җирләделәр. Утыз җидесе дә тулмаган иде әле аның. Дүрт бала калдык: бер абый алтынчыны, икенчесенең – дүртенчене, мин икенче классны тәмамлаган ел. Кечкенә сеңлебезгә исә дүрт яшь тә тулмаган. Иң беренче соравым да аның хакында булды: «Хәзер Айсылу нишли?» Үги әни турында бик күп китаплар укыдым – аның нинди булачагын беләм. Өйгә башка әни килүдән бик каты куркам. Аннары без бит инде болай да бер ел диярлек әнисез яшәдек. 2 нче класста укыганда әти мине инде кер машинасында керләр юарга өйрәтте. Аш куя беләм. Дөрес, керосинкага гына: кайткач ашны газга күчереп, әти үзе пешереп бетерә. Идәнне себерәм, юам. Әнинең: «Бүгенге эшне иртәгә калдырма, кызым», – дигәне гел хәтердә. Әтигә башкалар ниләр әйткәнне дә гел тыңлап йөрим. Карилегә баргач, дәү әнинең: «Кияү, балалар бик вак. Сиңа өйләнергә кирәк», – дигәнен дә ишетеп калдым. «Розаның елы үтмичә, бернәрсә дә эшләмим», – дип җавап бирде әти.

Мине бик ярата иде ул, үзенең әнисенә охшата иде. Яныма килеп утыра да: «Сиңа авыр, кызым, сине жәллим. Абыең урынында син булсаң да, миңа беркем кирәкмәс иде», – дия иде. Терлек-туарны абыйлар карый, ә йорт минем өстә иде бит. «Әти, өйләнмә генә, бөтенесен дә үзем эшлим», – дим. «Өйләнмә!» дигән сүзне адым саен кабатладым мин аңа.

Берсендә әти белән район үзәгеннән кайтабыз. Машинага бер апа да утырды. Аны бер авыл янында төшереп калдыргач: «Кызым, бу апа сиңа ошадымы?» – дип сорады. Нигә болай сораганын беләм бит! «Юк!» – дидем өздереп... Әтигә дүрт бала белән җиңел булмагандыр, уйланып та йөргәндер. 37 яшь кенә иде бит әле аңа.

Бер ел шулай узды.

...Безне дәресләрдән соң гел озынайтылган көн группасына калдыралар иде. 19 апрель көнне тәрбиячебез Гөлҗиһан апа керде дә: «Фәридә, бар син кайт инде. Өеңдә эшең күптер», – диде. Үзенең күзләре кызарган, елаган. Моңа никтер игътибар итмәдем – сөенеп өйгә йөгердем. Ул елны яз иртә килде, инде сукмаклар төшкән. Бездән бер йорт аркылы торучы Бибисара нәнәйләргә җиткәч, каршыма олы абый Ринат чыкты. «Фәридә, безнең әти больницага эләккән бит әле», – ди. Йөрәгем жуу итте: әтинең бит беркайчан да авырганы юк! Каршы як күршебез капка буяп ята. Ул да сүзгә кушылды: «Борчылмагыз, әтиегезгә берни дә булмаган!» Шул вакыт капкада Бибисара нәнәй күренде һәм: «Кирәкми, балаларны өметләндермә», – диде. Мин шунда барысын да аңладым... Аңымны җуйганмын... Күземне ачканда Бибисара нәнәйләр өендә ята идем, медпункттан шәфкать туташы килгән, уколлар кадаган.

Гап-гади иртә иде ул. Өйдә бер грамм су калмаган. Әти абыйларны торуга шуның өчен ачуланды. Без мәктәпкә киттек, ул – эшкә. Көндәгечә, башта Айсылуны балалар бакчасына керткән. Бензовозда эшли, районнан колхозга бензин ташый иде әти. Әхәт абый хәзергәчә сөйли: «Мин өйләнергә йөри идем. Район үзәгенә чалбар тектерергә бардым, – ди. – Шәүкәт абый мине алып барды да, кайтканда никтер көтмәде, ашыкты. Фәлән кешегә утырып кайтырсың диде дә, китеп барды». Район үзәгеннән чыгып аз гына баруга, машинасы белән капланган әти. Бензовозның бензин белән тулы багына берни булмаган, ә кабинадан берни калмаган. Инфаркт булгандыр дип уйлыйбыз... Икенче көнне бер йорт аркылы күршеләрнең утын әрдәнәсе артына качып әтине алып кайтканнарын карап тордым. Бөтенесе: «Фәридә кайда икән?» – диләр... Әтине озатырга кеше бик күп килде. Кеп-кечкенә дүрт баланың дөм ятим калуы бөтен район өчен зур фаҗига булды ул чакта.

16 июнь көнне инде безне Зәй районының Бигеш авылында урнашкан балалар йортына алып киттеләр. Өчебезне... Айсылуны дәү әни алып калды. Миннән хәзер дә бик еш кына: «Туганнарыгыз юк идемени, нигә алар сезне балалар йортына җибәрде?» – дип сораучылар бар. Безне алырга теләүчеләр бар иде. Беребезне – әнинең абыйсы, икебезне әтинең ике апасы алып китәргә уйлады. Чимкент шәһәренә. Дус кызымның авыл Советында

Фото: Анна Арахамия



Әти кинәт китте, әнигә бик авыр булгандыр, ул барысын да алдан сизгәндер...

эшләүче әнисе дә: «Фәридә, теләсәң, сине алып калам. Рифа белән бергә үсәрсез», – дигән иде. Бибисара нәнәй миңа: «Кызым, ризалашмагыз. Шатлыкта да, кайгыда да бергә булыгыз», – диде. Абыйлар да бер-беребездән аерылуга каршы булды.

Бик тырыш, булдыклы кеше иде безнең әти. 1965 елда әни белән алар яңа кирпеч йорт салып чыкканнар. Бөтен каралты-кураларыбыз да өр-яңа иде. Мунча да яңа өлгергән генә иде әле. Шул тормышның барысын да калдырып китте дә барды әти белән әни...

Йорттагы терлекләрнең бер өлешен Карилегә – дәү әниләргә илттеләр. Анда бабай үги, әмма бик әйбәт кеше иде. Әти «Иж-Юпитер» мотоциклы алган гына иде, бер тапкыр йөрергә дә өлгермәде – аны колхозга сатып алдылар. Өйдәге сатылырлык әйберләрне сатып, акчасын авыл Советы дүртебезгә бүлеп кассага салды. Бер өлешен дәү әнигә дә бирделәр – каникулларга аларга кайтып йөрисе бит. Ә йортка тимәскә булдылар: «Бәлки, үскәч, берәрегез кайтыр», – диделәр.

Башта безне, ияләшергә җайлырак булыр дип, Бигешкә бер айга гына илттеләр. Юлга кузгалгач, туктый алмый елавым истә. «Борчаклы күлмәгемне аласым килгән иде, шул калган», – дип еладым. Кире борылып кайтып күлмәкне алдык. Мин килен булып төшкәч, безне ул чакта Бигешкә илткән Хәбир абый: «Бик каты елаган идең, Фәридә, миңа рәнҗеп калмадыңмы?» – дип сорады...

Ишекне ачып керүгә, безне балалар уратып алды. Һәрберсе миңа үз язмышын сөйли... Балалар йортына әти-әнисе үлгәннәр генә эләгә дип белә идем, ә монда кем генә юк! Югалып калдым: кайсына карарга, кемне тыңларга белмим. «Бишле»гә генә укый торган кыз килә», – дигән сүз булган, алар инде үзара «аның белән мин дуслашам» дип, бүлешеп тә куйганнар.

Абыйларга, бәлки, малайлардан эләккәндер, тик Бигеш балалар йортында кыерсыттылар дип әйтә алмыйм. Миңа анда кыен булмады. Сагынуны санамаганда! Авылны, Айсылуны өзелеп сагынам! Аны әйтеп аңлатып булмый... Төннәрен берәүгә дә күрсәтмичә елыйм... Сеңлемә атап шигырьләр язам. Нинди генә конкурста җиңеп бүләк алсам да, аңа алып кайтырга дип җыеп барам. Безгә бөтен авыл хат яза иде. Егермешәр хат килгән көннәр булды. Директор: «Нәрсә язалар сезгә бу кадәр?» – дип, берсендә кычкырып укыткан иде хәтта.

Класс җитәкчем бик әйбәт характеристика язып җибәргән иде, сеңлесен үзе карады дигән юллар да бар иде. Шуңадыр, миңа хәтта Бигештә керләремне үземә юарга рөхсәт иттеләр. Безне анда чисталыкка да, ашарга пешерергә дә, кул эшенә дә өйрәттеләр. Авыл мунчасы кебек мунчабыз бар иде – суын үзебез ташыйбыз. «Бишле»гә генә укыгач, башкалардан аерылып торганмындыр – чәчемне дә кисмәделәр. Кечкенәләр арасында бердәнбер озын чәчле кыз идем! Бөтен балалар йортының горурлыгы булганмындыр дип уйлыйм хәзер. Бетләмәсеннәр дип, чәчләребезне гел тикшереп торалар. Табиблар килгәнне ишетсәләр, 9–10 нчы классларда укучы малайлар, бет, серкә юкмы дип, башта үзләре тикшерәләр, аннан, миңа ияреп, медпунктка баралар. Чәчемне кистерергә дисәләр, яклап калалар, янәсе.

Бигеш безнең авылдан аерыла иде, әлбәттә. Юллар – асфальт, пыяла кибет. Аэропорт салганда халык нык хәлләнеп калган. Мәктәп тә зур. Ул безнең балалар йорты каршында гына иде. Озын тәнәфестә чабып кына үзебезгә чыгабыз: ипи белән йә сөт, йә кесәл бирәләр. Берсендә ашап бетермәгән ипи кисәген алъяпкыч кесәсенә салганмын, дәрестә исә, онытылып китеп, шул ипи валчыгын капканмын. Үзем сизмәдем. Тарих укытучысы дәрестән куып чыгарды. Башта нәрсә өчен икәнен дә аңламадым. Яңа уку елы башланган гына иде әле... Озак та үтмәде: «Балалар йортына яңа завуч килде, улы белән бездә торачак», – диделәр. Тәрбиячебез яңа завучтан дәфтәр алырга мине җибәрде. Завуч бүлмәсе ишеген шул тарих укытучысы Земфира апа ачты. Мине күрде дә кочаклап елый башлады: «Син детдом баласымыни? Зинһар, гафу ит. Чәчең озын, бантигың булгач, белмәдем», – ди.

Каникулга дәү әнигә кайтуга, дүртәүләп үзебезнең авылга йөгерәбез. Сигез чакрым! Ачкыч белән ачып өйгә керәбез, бакчада әти утырткан алмагачлар, карлыганнар, кура җиләге. Колхоз көтүенә сыерыбызны карарга барабыз... Мәймүнә Тата апаларда кунабыз: рәхмәт, һәрвакыт якты чырай белән каршы алып, озатып калдылар.

1979 елда Бигеш балалар йортын яптылар, безне Казандагы 10 нчы интернат-мәктәпкә алып киттеләр. Бер яктан сөенеч – авылга якынайдык, икенче яктан... Бигештә барыбыз да бертөрле иде, ә монда, ял җиттеме, әти-әниле балалар өйләренә тарала, син каласың. Тәэмин итү дә башка. Бер елга нибары бер күлмәк бирәләр: кайберләребезнең алмашка да башкасы юк. Пальтоны да дүрт ел киясе. Кечерәя, билгеле, тик яңасы тиеш түгел. Аяк киеме дә кечерәя, тишелә... Безгә дә шул кием-салым, әти-әниләләргә дә. Дөрес, мин үзем җәйге каникулларда «Точмаш» заводында эшләдем, цех начальнигы балалар йортында үскән кеше иде, хезмәт хакына өстәп премия дә түләде – шул акчага киендем. Бигештә безне тәм-томнан өзмәделәр, ә монда ял көне генә бирәләр. Бер малаебыз склад баскан: конфет урлап, Бигештән килүчеләрнең мендәр астына куеп чыккан... Балалар йорты белән интернат-мәктәпнең аермасы күп иде шул. Беренчесе барыбер күбрәк ятимнәр өчен аның. Ләкин үземнең 10 нчы интернат-мәктәптә укуым белән горурланам: безгә ныклы белем, дөрес тәрбия бирделәр. Укытучыларыбыз искиткеч көчле иде!

Абыйлар армиягә икесе бер елны китте. Шул көзне безнең дәү әни вафат булды. Яман шеш... Соңгы көннәрендә аны үги кызы карады. Яңа елга ул Айсылуны Казанга алып килде. Мин дә аларга бардым. «Фәридә, без җизнәңнәргә кайтып китәбез. Айсылуны кая куясың?» – ди. Кая куя алам инде мин аны? Кулына мәктәптән

бер документ та бирмичә чыгарып җибәргәннәр. Бу вакытта 9 нчы класста укыйм. Дәү әни турындагы авыр хәбәрне алгач, тәрбиячеләр белән Айсылуга дип урын әзерләдек. Тик директор: «Сеңлеңне кабул итә алмыйбыз, аны Азнакайга җибәрәчәкләр. Бездә хәзер сәләтле балаларны гына җыялар», – диде... Ул да сәләтле, дип тә карадым... Каникуллар иде бит – интернатта кеше аз. Айсылуны алып кайттым. Аны бүлмәдән чыгармыйбыз. Дус кызым Хәнифә белән икәү бер порция ашыйбыз, икенчесен аңа алып менәбез... Беркөнне Камәрия Зиннуровна килеп керде, аның әле укытучы гына булып эшләгән чагы. «Фәридә, мин бит исемлеккә Айсылуны да керткән идем. Белмәдем...» – ди. Директорга чакырттылар. «Алып килдеңмени сеңлеңне? – ди. – Министрлыкка үзең барып карасаң гына. Мине ишетергә дә теләмиләр».

Министр урынбасары үзе кабул итте. Еладым инде... «Азнакайга китсә, мин бит аны башка күрә алмыйм», – дим. Балалар йортлары белән эшләү бүлеге инспекторына җибәрде, ул исә «документларсыз гына кабул итәргә» дигән язу язып бирде. Язгы каникулда Олы Кариле мәктәбе завучы Айсылуның документларын китереп китте. Сеңлем интернатка бик авыр ияләште. Елый иде: «Ул сукты, бу сукты, алай әйттеләр, болай...» Башта япладым, аннан: «Үзең дә җавап бир», – дип өйрәттем.

Ятимлегем турында беренче тапкыр университетка укырга кергәч кенә исемә төшерделәр. Алтын медаль белән, бер имтихан гына биреп, рус теле бүлегенә кердем. Декан әңгәмәгә чакырды. «Син безгә очраклы рәвештә генә эләккән. Татар мәктәбен тәмамлап килгәнсең, өстәвенә, ятим дә икәнсең. Укый алмаячаксың, кеше урынын алып торма – читтән торып уку бүлегенә күч», – диде ул миңа. Еласам да, үз сүземнән кире чигенмәдем. «Киребеткән кыз, ярдәм сорап кермә», – дип чыгарып җибәрде. Класс җитәкчемә моны кайтып сөйләгәч, ул: «Фәридә, хезмәт хакым зур түгел, әмма үзем булышырмын», – диде... Беренче сессияне группадан бары тик мин генә «бишле»гә тапшырдым, әмма декан: «Хәтерлим, ул безгә очраклы эләкте», – дип, югары стипендия түләтмәде. Алга таба да гел «яхшы» билгеләренә укыгач кына, бәйләнүдән туктады. Йогышлы авырулар сырхауханәсенә эшкә урнаштым, 70 сум хезмәт хакы алам. Аннан абыйлар армиядән кайтты. Эштән кичке сәгать тугызда гына чыгуымны белгәч, «башка эшләмисең», диделәр. Ай саен икесе дә миңа 30–40 шар сум акча биреп тордылар. Югары стипендия алып укыдым. IV курстан соң безнең кебек ятимнәргә, хөкүмәт карары нигезендә, кием-салым өчен дип, елга бер тапкыр 500 сум, ашарга көн саен 1 әр сум түли башладылар. «Сиңа рәхәт», – дигән иде шунда бер группадашым...

Айсылу белән без гел бергә булдык. Төшемдә күрсәм дә, ул яраткан конфетларны алып, янына йөгерәм. Әпадан бигрәк, әни урынына идем бугай мин аңа. Безнең мөнәсәбәтләр дә гел шундый булды: биш яшькә генә өлкәнрәк булсам да, аның өчен үземне һәрвакыт җаваплы хис иттем. Хәер, абыйлар өчен дә. Җәүдәте өйләнгәч, берара бик килми, очрашмый башлады. Хатыны белән икесен утыртып сөйләштем: «Сез дә гаилә, без дә, – дидем. – Барыбызны туплап торырга әти-әни юк, аралашмыйбыз икән – гаилә булудан туктыйбыз». Шөкер, тату яшибез. Мин диплом алган елны Айсылу университетка укырга керде. Абыйларның берсе институт тәмамлады, икенчесе: «Сез укыгыз», – дип эшкә урнашты, югыйсә аның да аттестатында билгеләре бик әйбәт иде. Айсылу кияүгә чыкканда аны абыйлардан килеп сорадылар, никахны да аларда укыттык. Ә мин кияүгә туган авылыма чыктым, элеккеге классташыма. «Сезне Бигешкә алып киткәндә үк, әнигә, Фәридәне алып калыйк әле, дип әйткән идем», – ди Илшат.

Ятим үсүем гаиләдә берәр ничек чагылдымы? Булгандыр, үзем сизмәгәнмендер... Аннан ирем әйбәт булды минем! Дөрес, гаиләдәге мөнәсәбәтләрнең нинди булырга тиешлеген бөтенләй белми идем дия алмыйм: каникулларда туганнарга кайтып йөрдек бит. Үпкә, кемдер безгә нәрсәдер тиеш дигән нәрсә миндә беркайчан булмады. Бу – безнең язмыш... Әмма тормышта югалып калмаячагыбызны һәрвакыт белә идем. Башкалардан бернәрсә таләп итмәү, өмет итмәү дә – ятим үсү нәтиҗәседер. Монысын кайнанам аңлап бетермәде. Ул бик юмарт карчык иде, ирем белән безгә анысын да, монысын да бирергә тырышты. Ә мин алмаска җан талашам: «Барысын да үзебез эшләп табарбыз», – дим. Алу дигәннән. Ятим балалар буларак, бары Айсылуга гына зур авырлыклар белән Чаллыда бер бүлмәле фатир ала алдык. Моның өчен 23 яшькә кадәр каядыр чиратка басарга тиеш булганбыз. Белмәдек...

Кемдер минем өчен нәрсәдер хәл иткәнне көтә алмыйм – үзем эшләргә тиеш дип саныйм. Бу гадәтем хәзер дә бар. Белмим, холкым шундыймы икән, әллә кечкенәдән мөстәкыйль булып үсү нәтиҗәсеме? Буш хыяллар да юк миндә.

Кияүгә чыккач, алты ел балам булмады. Илшат: «Бәлки балалар йортыннан алырбыз?» – дигән сүзләр әйткәләде. «Ә син аны ярата алмасаң кире илтерсеңме? Мәче баласын ташлау да гөнаһ, ул бит кеше», – дия идем. Тәрбиягә бала алып, аны бөтен кимчелекләре белән ярата алучылар – минем өчен геройлар. Балалар йортында үсүчеләрне артык яхшы беләм бугай... Аннан, үз балаңа катырак итеп тә әйтеп була, ә ятим баланы беркайчан ачулана алмас идем...

Авылга инде беребез дә кайтып төпләнмәячәген белгәч, йортыбызны күрше Әминә апаларга саттык. Кереп йөрибез – бик сөенеп каршы алалар. Туган якка – Кама Тамагы районы Келәнче авылына, ирем туыпүскән нигезгә гел кайтабыз, Яз саен авылдашлар зират өсләрен чистарта – бу көнне абыйлар да көтеп кенә тора. «Әти белән әни исән булса, безнең тормыш башкача булыр иде», – дип сөйләшәбез. Төшкә, нигәдер, әти ешрак керә... Икесе бергә төшкән фотосурәт каршысына басып гел бер җыр көйли һәм елый иде әти:

Күпме күзләр күреп онытылган, / Күпме йөзләр чыккан исемнән; / Күпме сүзләр киткән хәтеремнән?! – / Ә син һаман, һаман исемдә...

Кайдадыр шушы җыр яңгыраганын ишетсәм, алар кабат икесе дә хәтеремдә җанлана...

КҮЗЛӘРЕМНЕҢ ТӨСЕ ҮЗГӘРМӘДЕ...

Икәү бергә йөргән сукмакларда
Яфрак күмде безнең эзләрне,
Яфракларның төсе үзгәрмәде,
Яфракларның төсе үзгәрмәде,
Синнән башка көзләр үзгәрде.

Нияз Акмал сүзләренә Фәрит Хатыйпов көй язган бу җыр Нәфкать Нигъмәтуллин башкаруында Башкортстан радиосыннан еш яңгырый. Һәм ул мине ерак яшьлегемә – Казанда укып йөргән елларыма чакыра... Мин җырга буйсынып, яшьлегемә кайтам...



Фәния
СӘЕТГӘРӘЕВА

...Университетка укырга керүчеләрне студентлыкка кабул итү кичәсе үткәрү матур гадәткә әйләнгән иде. Бу кичәгә татар бүлегендә укучылар да, татар журналистикасы студентлары да, гомумән, әдәбиятны, шигъриятне яратучылар килә. Укырга яңа керүчеләр ниндирәк икән, сәләтле яшьләр бармы? Яңа студентлар белән танышудан бигрәк, үзенә күрә бер сынау шикелле кичә иде ул. Мин шунда бер шигырь сөйләгән идем:

Чәчәк җыя бер кыз тугайда,
Моң-зарларын сөйли тургайга.
Тыңлый тургай аны таң калып, –
Әллә хисләр уртак булганга...

Җыелучыларның гөрләтеп кул чапканы, залда нindидер шаулы дулкын үткәне хәтердә калган. Таралышканда бергә басып торган берничә егетнең миңа: «Сереңне безнең белән дә уртаклаш әле», – дип сүз кушканын да хәтерлим. Тик аларның йөзләрен дә, үзләрен дә дулкынланган күңелем отып калмады.

Тулай торакта ул вакытта журналистика бүлегендә укучы, хәзер танылган шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова белән күрше бүлмәдә яшәдем. Мине сеңлесе кебек үз күреп, киңәшләре белән ярдәм итеп торды. Бүгенге көнгәчә аңа рәхмәтлемен. Һәм нәкъ менә аның аша минем белән сер бүлешергә теләгән теге егетләр белән таныштым. Фәйрүзә кебек үк алар да журналистика бүлегендә укыйлар икән: Альберт Һадиев, Рашат Мифтахов һәм Нияз

Акмалов. Өч дус. Инде өчесе дә бакыйлыкка күчте... Урыннары оҗмахта булсын.

Ул елларда әдәбиятка, шигърияткә тартылу бик көчле иде. Бауман урамындагы Тукай клубында үткәрелгән һәр әдәби кичәгә ашкынып бардык. Шул кичәләрнең берсеннән Нияз белән без бергә кайттык... Ул миңа юл буе шигырь укыды. Үзенекен генә түгел, Мөдәррис Әгъләм, Кадыйр Сибгатуллин, Зөлфәт һәм башкаларныкын. Яттан! Хәтеренең яхшылыгына шаккатып, йотлыгып тыңладым.

Ул көнне йомшак кына кар ява иде. Нияз көйли-көйли бер шигырен укыды:

Казан каласында кар ява,
бөтерелеп-бөтерелеп.
Шәһри Казан моңлы нурга чумган
Мамык шәлләренә төренеп...

Мин бу шигырьне аның җыентыкларында очратмадым. Соңыннан энесе Нәсим аркылы белдем: ул чыннан да җырга әйләнгән. Аңа Рөстәм Яхин көй язып, Айдар Фәйзрахманов башкаруында ул Татарстан радиосы фондында саклана икән. Бик мәслихәт!

Гомумән, Нияз белән очрашкан саен бер-беребезгә шигырь укый идек. Аның уенда, җанында шигырьдән башка нәрсәгә урын юк иде бугай. Кайчак башында өзек-өзек фикерләр туса, язып куюымны сорый иде. Чөнки мин – студент, кулымда һәрчак дәфтәр-каләмле букчам... Аңа ияреп мин дә шигырь укыган булам. Башкортстаннан булгач, туганнарымны, әнкәй-әткәйне нык сагына идем. Шунда әнкәй турындагы бер шигыремне укыгач, Нияз: «Сат әле шул шигыреңдәге бер фикереңне», – дип шаккаттырган иде. Ул: «Шатлыклардан елар өчен / Бармы яшең, әнкәй?!» дигән җөмлә иде...

Ниязның һәр сүзе, һәр фикере шигъри иде, һәм һәрберсе – яңалык, ачыш! Ул башкалардагы шундый ачышларга да ихлас сөенер иде. Күңелен кырганнарга исә шигъри юллар белән җаваплар:

Әйбәт булды инде, әйбәт булды,
Кайберләргә бер биш көнлек
гайбәт булды.

Бу – аның яраткан гыйбарәсе. Аннары: «Иң беренче эш итеп, сана мине кеше итеп...» – дигән җөмләне еш куллана иде. Ул аны соңыннан бик матур шигырьгә әйләндергән:

Карыйсың төбәп,
уйларымны белергә теләп.
Карыйсың сынап,
кемлегемне сорап.
Карыйсың җанны өшетеп
кемнәрдәндер гайбәт ишетеп.
Аңла:
иң беренче эш итеп
сана мине кеше итеп...

Нияз җәяү йөрергә ярата иде. Нәкъ менә җәяү йөргәндә яза иде ул күп шигырьләрен. Каләм белән дәфтәргә түгел, ә хәтеренә.

Җәяү йөрим. Урам буйлап түгел,
Дөньяларны уйлап мин йөрим...

1976 елда университетны тәмамлагач, эшкә Балык Бистәсе районына, радионың җирле тапшырулар мөхәррире булып китте Нияз. Ул киткәч, урамнар бушап калгандай булды... Хатлар алыштык. Тик ул, нишләптер, бик сирәк яза иде. Бервакыт андагы газетада бастыру өчен миннән шигырьләр сорады. Кыенсынып кына берничә шигыремне җибәрдем. Һәм аның берсен, ул вакыттагы минем халәтемне аңлатканын, бастырып та чыгарды. Менә ул шигырь:

Сагынсын дип дәшмәвеңме,
Күрмисең шул яшьләремне, –
Сагындым бит инде.
Сынсын, дипме, горурлыкны, –
Ә ул миңа торырлыкмы, –
Дип сыныйсың мине.
Сабыр булсын, дипме әллә,
Син дәшмисең миңа әл дә,
Ә мин янам, көям...
Горурмын да, сабырмын да,
Ләкин шундый сагындым ла,
Үзем генә беләм...

Берничә көннән шул шигырь өчен почта аша миңа бер сум гонорар да килеп төште. Бу 1977 ел иде...

1976 елның көзендә Татарстан Язучылар берлеге яшь иҗатчылар семинары оештырды. Һәм Ниязның шигырьләре, хикәяләре шул семинарда уңай бәя алды. Иҗат мөмкинлекләрен киңәйтү максатыннан, өлкән әдипләр аңа Казанга күчеп килергә киңәш иттеләр. 1977 елның көзендә Нияз Казанга күчеп килде. Без аерылмас дусларга әйләндек. Кая гына барсак та – бергә! Нияз миңа үзенең мөнәсәбәтен белдереп шушы шигырьне укыды:

Җанда иде мең газабым,
Мең уйларым;
Арган иде тәнем, җаным,
Буыннарым...
Җеназасын эзләп йөри иде бәхетем.
Һәм син дәштең:
«Оныт барын,
Уйларыңнан арын...»
Мин җиңәрмен,
мин җиңәрмен
бу дөньяның җилен, карын.
Давылларын.
Әгәр тойсам үз янымда
Шушы сүзне әйтә алган
Кеше барын... (1977 ел).

Фәния белән Нияз исемнәрен бергә кушып, дуслар хәтта безгә яңа исем уйлап чыгарды: Фәнияз.

Безнең төркем университетта иң көчлеләрдән булды дисәм, башкалар үпкәләмәс. Флера Низамова, Фәез Зөлкарнәев, Нәҗип Исмәгыйлев, Галимҗан Гыйльманов, Нурия Сафиуллина, Нурания Мингалимова, Фәнүзә Зыязиева, Филүс Галләмовларның исемнәре Татарстанда гына түгел, читтә дә киң билгеле. Нияз безнең төркемне нык яратты. Флера, Фәезләр белән шигърият турында бәхәсләшеп хәлләре бетәр иде. Розалия Мухъянова, Фәезнең хәләле Иркә Әхмәтшина белән еш кына сүз көрәштерерләр иде. Шулай итеп, Нияз безнең төркемнең аерылмас бер кешесенә әверелде. Нинди генә бәйрәм, нинди генә чара булмасын – ул киңәше, гармунда уйнавы белән кичәләребезне бизи иде. Һәм, әлбәттә, аның шигырьләре барыбызга да тансык иде. Аеруча мәхәббәт турындагылары.

Кыз күңеле

Вакыт үтә,
гомер итә,
көн итә.

Ул үзе кебек туры сүзле, гадел кешеләрне яратты, алар белән аралашуны хуп күрде.



■ Фәнияз: Фәния белән Нияз.

Кемне көтә,
нәрсә көтә,
ни көтә? –
Борчу йөрер бу күңелдә
кич-иртә.
Җан сөйгәннәр
читтә йөреп
тилмертә.
Җанга ятлар
янда йөреп
тилертә...
Сыкрау түгел,
елау түгел,
зар түгел:
үзе белеп борчыладыр
бу күңел...

Танымаганга салыш

Ник кирәк мондый карашлар
Ник кирәк мондый сагыш? –
Үтеп кит син. Күрмичә үт,
Танымаганга салыш.

Син – бер ярның карлыгачы,
Мин – күптән бүтән ярда.
Башлап син бит ташлап киттең
Уртак кыябыз барда.

Син табындың бүтән ярга,
Бүтән кыяны үптең.
Ник бүген, җанны тетрәтеп,
Үтәли карап үттең?

Югалган табыш кебек үк
Бу сагыш миңа таныш.
Үтеп кит син, күрмичә үт –
Танымаганга салыш...

Өченче курстан соң безнең төркемнең күп кенә кызлары «Девчата» дип исемләнгән төзелеш отряды белән җәй көне Татарстан районнарына эшкә барды. Хәтеремдә, ул көнне Нияз энесе Нәсим белән безне озатып калдылар. (Гомумән, Нияз энесен бик ярата иде, еш кына үз янында йөртә иде.) Шул озатудан соң Нияздан хат килеп төште. Шигъри хат.

Ургыла язмыш дәрьясы –
Дулкын өстендә – дулкын!
Нинди җилләр белән килде
безне аерган ул көн?
Төбәлеп калган карашлар
югалды агымсуда.
Безнең сөю – ялгыз җилкән...
Моңсу да, ямансу да.
Әллә миңа тоела бары,
әллә гел – кыйблалары:
Җилкәнне көтеп тора бит
Бәрелер кыялары!
Нинди җилләр белән килде? –
Дулкын өстендә – дулкын!
Сагышлы түгел, каргышлы
Безне аерган ул көн... (2.07.1977)

Нияз мине үзенең туганнары – Эльмира һәм Энҗе апалары белән таныштырды. Бер җәйдә туган ягына – Сарман районы Каташ-Каран авылына алып кайтты. Әти-әнисе, Нәҗип абыйсының гаиләсе белән таныштырды. Әтисе Рәшит абый математика укытучысы булса да, шигъри җанлы, шаян, җор сүзле иде. Җае туры килгәндә Ниязның әнисенә: «И Хәлимә, Хәлимә, ник кермисең хәлемә?» – дип шаяртыр иде. Оста умартачы иде. Кортлары күп. Төрле яктан бал ташыйлар. Әнисе Хәлимә апаның бакчасында нинди генә җимешләр юк. Ярдәм итү йөзеннән карлыган җыярга чыктым. Шунда мине корт чакты. Аллергия булгандыр инде, битем, кулларым су тулган шеш белән капланды. Температурам күтәрелде. Әй күрсәгез аларның кайгырганын! «Кеше баласын харап итәбез бит, никләргә генә ул бакчага чыгардык икән!» – дип, табиб чакырдылар хәтта. Хәлем тиз яхшырды, тик мине бакчага башка чыгармадылар. Җыйган карлыганнарымнан, үзем белгәнчә, кайнатма ясадым, бик шатландылар. Ул җәйдә печән нык уңды. Сарман буйкайлары тугай, тугай... Нияз белән Нәсим печән чаба, мин җыйган булам. Печән чаба белми идем: безнең якларда тугай юк, кыр да кыр. Печәнне бик авырлык белән әллә кайларга барып әзерлиләр бездә. Акмаловларның берсе шигырь сөйли, икенчесе җырлый... Нәсим дә, абыйсы кебек баянда уйный, хәтта көйләр яза иде. Мин аларны Хәлимә апа төйнәп җибәргән ризык белән сыйлыйм. Кайткач: «Ашарыгызга җиттеме, сусамадыгызмы?» – дип сорагач, егетләр: «Фәния куян күчтәнәче итеп алып та кайтты әле», – диләр. Әти-әниләре сынап йөргәннәрдер инде, Ниязга соңыннан, уңган кыз, югалтма, дигәннәр.

...Әйе, югалтасы килмәде Ниязның мине. Университетны тәмамлагач, мине Казанда калдыру максатыннан эшкә Сарман районына җибәрүләрен сорап, юллама алды. Һәм дуслары аша ул юлламаны юкка чыгарды. Ул заманда юллама белән эшкә бару мәҗбүри иде бит. Шулай итеп, мин Казанда калдым. 10 нчы интернат-мәктәпкә эшкә кердем. Нияз башта Татарстан китап сөючеләр җәмгыятендә инструктор-методист булып эшләде. Иң яңа китаплар аның кулында иде. Үзе укыганнан соң миңа да тәкъдим итәр иде. 1979 елда «Яшь ленинчы» газетасына эшкә күчте. «Торгынлык еллары» дип аталган бу еллар – татар мәктәпләренә, татар теленә зур киртәләр куелган, зур басым ясалган чор. Менә шундый авыр бер чорда «Яшь ленинчы» газетасы, башка татар матбугаты органнары белән берлектә, туган тел өчен, татар мәктәпләре, рухи ныклык-хөрлек өчен чын-чынлап көрәш җәелдерде, Нияз да бу изге эшкә җаны-тәне белән кушылды.

Тик аның җаны тыныч түгел иде. Мәктәп елларында ук район газетасында «Ярлар һәм яралар», «Такташка җавап» исемле поэмалар белән беррәттән, «Сугыш тавы» дигән күләмле шигъри әсәр бастырып чыгарган шагыйрьнең шигырьләре, хикәя, хәтта повестьлары вакытлы матбугатта аз басылды, китап итеп чыгара

алмады. Аның җанын шул телгәләде. Һәм, әлбәттә, бу гаделсезлеккә түзә алмады... Сынды. Бу сынуны мин дә күтәрә алмадым. Шул вакыттагы көчсезлегемә әле дә үкенеп бетә алмыйм. Нияз авылына ялга киткәч, ашык-пошык җыенып, качып дип әйтерлек, 1980 елның көзендә Башкортстанга кайтып киттем. Ниязга бөтенләйгә Казаннан китү турындагы хәбәремне вокзалга озатырга төшкәч кенә әйттем. Алданрак әйтсәм, җибәрмәс, дип, үзем дә кире уйлармын дип курыкканмындыр инде... Ниязның гасабиланып, бу хәлнең чынлыгына ышана алмый перронда басып калганы әле дә булса күз алдымда...

Хатлар алыштык. Һәр хаты саен – бәгырьләрне телә торган шигырьләр...

Син барында карлар ап-ак иде,
Әй каралды карлар син киткәч.
Вокзал хәтле вокзал өнсез калды,
Китәсеңне синең ишеткәч.

Китте поезд...
Төнне ярып китте,
Мең тарафка безне таратып.
Мин дусларга уйнап кына әйттем,
Ә бит калдым чынлап яратып.

Шәлләреңне иңеңә салып җибәр,
Юл җилләре әгәр өшетсә.
Синең поезд кире борылыр иде,
Йөрәгемне минем ишетсә...
* * *
Каргыш итеп юрап әйттеңме син
Без хушлашып йөргән бер көндә:
«Мин яраткан кебек сине бүтән
Яраталмас, – диеп, – беркем дә».

Сине җуйган ул көннәрдән бирле
Күп исемнәр кергән хәтергә.
Мин базмамын ләкин беркемгә дә
Яратмадың диеп әйтергә.

Хәер... Барыбер... Нигә яшерергә?
Ни әйтсәм дә – минем иркемдә:
Син яраткан кебек яратмады
Бу дөньяда мине беркем дә...

Мин «Кызыл таң» газетасында эшләгәндә Нияз бер шәлкем шигырьләр җибәрде. Башкортлар да минем иҗат белән танышсын әле, дип. Ул шигырьләр арасында миңа багышланган, хәзер популяр җырга әйләнгән «Күзләремнең төсе үзгәрмәде» шигыре дә бар иде.

...Берчак тулай торакның комендантны мине үз бүлмәсенә чакырды. Казаннан шалтыраталар, ди. Нияз... «Өйләнсәң, фатир бирәбез», дигәннәр икән. И-и-и, беркатлы шагыйрь! Кыз баладан шулай дип кияүгә чыгуын сорыйлармыни инде?! Мин, әлбәттә, риза булмадым. Фатир алыр өчен генә чакыра дип үртәлдем... Нияз өйләнде. Һәм безнең арада хатлар да озак кына туктап торды. Шулай да, Казанга сабакташлар белән очрашуга барганда группадашлар Ниязны да чакырганнар иде. Әйттем бит: ул безнең группа кешесенә әйләнгән иде дип. Нияз шунда бер рәссам ясаган карикатурасы белән менә бу шигырьне алып килгән иде.

Тулган айга карап
күңелем тулды.
Уйлап барган уем онытылды,
искә төште кинәт кемнәрдер.
Аларга да бәлки бу тулган ай
Мөлдерәмә булып күренәдер...

Ай тотылган төндә онытылган, әй, –
Бу тулган ай кайчан тотылган ай
исәбендә айлар, елларның?
Иң якын яр...
Ул соң кайсы чатта?
Тулган айга карап барган чакта
күңелендә ниләр ул ярның?

Өзелеп-өзелеп, өзелеп кала бәгырь,
мин үзем дә бәлки кемнәргәдер
бик тә моңсу булып күренәмдер, –
тулган айга карап күңелем тулды,
уйлап барган уем онытылды.
искә төште кинәт кемнәрдер...

Тик ул җыентыгына бераз үзгәртеп кертелгән.

Соңыннан бу шигырьгә ике композитор – Рәис Сафиуллин һәм Рамил Миндияр көй язды.

1986 елда Нияз Акмалның лирик һәм публицистик шигырьләре тупланган «Учак» исемле беренче җыентыгы басылып чыкты. Ул җыентыкны Казанда китап кибетләреннән бик тиз алып бетергәннәр дип ишеттем. Үзеннән сорагач, соңгысын да бер танышым үтенеп алып китте дип көрсенде.

Гомумән, Ниязның бер генә җыентыгы да кибет киштәләрендә юк.

...Югалтуга килгәндә... Нияз «Мәдәни җомга» газетасында эшләгәндә миннән Башкортстан татарлары (артистлар, язучылар) турында мәкаләләр язуымны сорый иде. Озак еллар «Мәдәни җомга»ның актив авторы булдым. Беренче язмаларымнан соң оперативка вакытында газета мөхәррире: «Уфада бер шәп хәбәрчебез барлыкка килде, югалтмаска иде аны», – дигән. Шунда Нияз: «Их, аны күп еллар элек югалттым шул...» – дип көрсенгән дип әйттеләр.

Еллар үткәч, эшем буенча Казанга еш барырга туры килде. Тик Нияз белән сирәк очраша идек. Сабакташыбыз Фәиз Зөлкарнәй фаҗигале вафат булгач, аның хәтер кичәсендә очраштык. Ул тетрәндергеч шигырен укыды:

Алар әйтте:
«Мондый кан кирәк», – дип,
Болар әйтте: «Андый кан кирәк!»
Дөрес, дуслар, мондый Кешеләр дә,
Мондый кан да Җирдә бик сирәк.
Кемдер әйтте: «Исән калыр иде,
Йөгереп барып әгәр кан бирсәк».
Ул чыннан да исән калыр иде,
Өр-яңадан әгәр җан өрсәк.
«Чабылмаган печәннәре калды...» –
Әтисе бит әйтте шулай дип.
Ул Иделне, Илне иркәләде,
Чынлап та бит, дуслар, шулай бит?!

Ниязны ташлап китүемә бик үкендем, дидем. Аеруча теге шигыре хәтеремне телгәли иде:

Мин җиңәрмен,
мин җиңәрмен
бу дөньяның җилен, карын.
Давылларын.
Әгәр тойсам үз янымда
Шушы сүзне әйтә алган
Кеше барын...

Аны мин генә үзгәртә алмас идем. Аның үзенең шигыре дә бар бит:

Үз халәтем, үз хәлем.
Үз гадәтем, үз гамем.
Барысы да үз җанымда,
Тагын ничек үзгәрим?
Үз фикерем, үз башым.
Үз хәсрәтем, күз яшем.
Ялгышларымны каргама –
Мин беренче кат яшим...

Ә хәзер Нияз Акмал безнең күңелләрдә, шигърият сөючеләр йөрәгендә, әдәбият дөньясында мәңге яшәячәк!

Ак чәчәкләр

Айгөл Әхмәтгалиева сүзләре,
Вил Усманов көе.

Ак чәчәкләр – ап-ак язлар микән,
Ак өметләр микән күзләрдә...
Аклык эзләп, аклык күзләп үткән
Гомер үзе нинди төсләрдә?

Кушымта:
Ак гөлләрдән җан җылысы алып
Күңелләргә саласы иде.
Ак чәчәкләр кебек ап-ак булып
Саф күңелле каласы иде...

Яшәү дигән татлы сүзгә сыйган
Сер ачкычы кайда, кем белә?
Таң күзеннән гүя безнең гомер
Чык тамчысы булып түгелә.

Гомер таҗын өзә ачы җилләр,
Җаннар елый, шулчак нишләргә?
...Ак чәчәкләр йолдыз булып яна
Өмет нуры сүнгән кичләрдә.









АК ЧӘЧӘКЛӘР ЙОЛДЫЗ БУЛЫП ЯНА...



Айгөл
ӘХМӘТГАЛИЕВА

Татар әдәбиятына, мәдәниятенә гашыйк тамашачы «Ак чәчәкләр» романы буенча фильм төшерелүеннән хәбәрдар инде, әлбәттә. Габдрахман Әпсәләмовның бу мәшһүр әсәре заманында кемнәрне генә үзенә әсир итмәгән дә, кемнәрне генә табиб һөнәре сайларга этәрмәгән! Романны чын мәгънәсендә табибларга сүздән коелган һәйкәл дип атарга мөмкин. Фильмның сценарий авторы буларак, миңа бу әсәрне кайта-кайта, әллә ничә тапкыр кабат укырга туры килде. Бүген язарга теләгәнем – әлеге әсәр прототиплары турында түгел, ә бәлки фильм өчен махсус язылган «Ак чәчәкләр» җырының герое турында. Күпләр сәерсенеп куяр, янәсе, җырның нинди герое булсын инде... Була икән шул!

Сценарийны язып бетергәч, телемнән тартар тарткандай, «Ак чәчәкләр»нең продюсеры Миләүшә Айтугановага: «Фильм алдыннан, бәлки, берәр җыр да куяргадыр, кирәк дисәгез, шигырен язып карыйм», – дип әйтеп куйдым. «Табиблар турындагы фильмга табиблар турында җыр язам», дип әйтүе генә җиңел икән. Шигырь сүзләре урынына күңелгә кирәге-кирәкмәгәне – әллә ниләр килеп тулырга гына тора... Чәбәләнеп беткән уйларымны читкә куып, кинәт кенә күзалдыма ак халатлы берәү килеп басты. Ул «берәү» – иң авыр вакытларымда, якыннарымның тормышы өчен ут йотып йөргән көннәремдә миңа ярдәм кулы сузган, сүнәргә торган өмет учагын тергезеп җибәргән кеше – Азнакай районы Мәндәй авылы егете Азат Әдһәд улы Фәтхетдинов иде. «Миңа» дидем дә үзем үк елмаеп куйдым: миндәйләрнең саны йөзләгән, меңләгән ләбаса!

Казан медицина институтын тәмамлап, Чаллыга эшкә килгәч, аның хезмәт юлында 1 нче балалар хастаханәсендә табиб-педиатр, сырхауханәдә бүлек мөдире, баш табиб, шәһәр сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе, 2 нче шәһәр больницасы баш табибы дигән баскычлар тезелеп китә. Кайда гына нинди генә вазыйфа башкармасын, халык телендә Азат Әдһәдовичның иң беренче чиратта кешелеклелек сыйфатлары урын ала. Табиб һөнәре сайлаган, бигрәк тә балачакта хирург булам дип хыялланган кешене йомшак күңелле итеп күзаллавы кыенрак, андыйлар күпкә кырыс булырга тиеш кебек. Хәер, Азат Әдһәдовичта бу сыйфатлар барысы бербөтенгә әверелә кебек: кирәк чагында таләпчән дә, кырыс та, шул ук вакытта кайгыртучан һәм ярдәмчел дә, гади һәм ихлас та була алу табибларга гына түгел, чын ир-егетләргә хас.

Кызым кечкенә чакта безгә берара больница юлын таптарга туры килде. Алдан язылып, айлар буе чират көтәргә мәҗбүр еллар иде ул. Үзләре әни булганнар бала авырганда ана кешенең нинди утта янганын бик яхшы аңлар. Баланың беләгенә кадалган шырпы да ананың йөрәгенә кадала... Әле бер, әле икенче ишеккә барып бәреләбез; тегеннән-моннан дару эзләп йөгерәбез. Соңгы чара итеп Азат Әдһәдович янына юл тоттым. Сүземне сабыр гына тыңлады да:

– Мин берничә көннән җәйге ялга китәм, аңынчы хәл итәрбез, – диде ул.

– Ярар, – дип чыгып китсәм дә, күңелемдә өметсезлектән гайре нәрсә юк иде. Ялга китәсе кеше минем проблемаларымны кайгыртып йөрер дисеңме?.. Бер атна үттеме-юкмы, өйгә балалар поликлиникасыннан шалтыраталар. Колакларыма ышанырга белмим: «Азат Әдһәдович барысын да әйтеп калдырды», – диләр. Ул минутта күңелгә тулган рәхмәт хисләре керфек очларыннан түгелде... Кызым белән бер айга якын дәваландык. Көн туса, аңа саулык теләп Ходайга ялвара идем. Изгелеге-игелеге өчен Азат абыйның үзенә дә Ходайдан сәламәтлек сорый идем.

Дөньяда могҗизалы хәлләр дә була. Дәваланганнан соң табибларның «барысы да әйбәт!» дигән сүзләрен ишетү иңнәргә канат куйды, күңелне күкләргә күтәрде. Бүген дә гаиләбез белән Азат Әдһәдовичка рәхмәтле булып яшибез. Чын ир кеше булып, үз сүзендә тора алганы, кызыбызны савыктыруда ярдәм кулы сузганы өчен мең рәхмәтле без аңа.

Үткен телле халкыбызның «Татар түрә булса, чабатасын түргә элә» дигән мәкале бар. Азат Фәтхетдиновка бу кагылмый! Таләпчән, шул ук вакытта гади. Кешелекле. Олы җанлы. Шулай булмыйча, һөнәре буенча балалар табибы лабаса! Азат Әдһәдовичны һәрчак эшлекле кыяфәттә күреп өйрәнгәнгәме, аның: «Мин балачакта бик шук идем», – диюенә ышанасы да килми.

– Чынлап, тиктормас малай идем. Бәкегә чумулар да, язгы ташуда боз белән агып китүләр дә калмады. Әби бәйләп куя торган иде үземне. Әнинең туганнары врач булганга микән, мин дә хирург булам дип үстем. Әби чемодан бирде, шуны тотып берүзем Казанга чыгып киттем, – дип искә төшерә ул үткән елларны.

Адәм баласы өчен байлык алтын-көмеш, доллар, евро белән үлчәнми, иң кыйммәтлесе – аның саулыгы һәм бердәнбер гомере. Әнә шул кыйммәтләрне югалту куркынычы ачы чынбарлыгы белән алдыңа килеп басканда, бар ярдәмне Аллаһы Тәгаләдән өмет итәсең, аның кодрәте белән шифалы кулга ия булган табиблар янына ашыгасың. Хәзерге заман кешеләрне аяусыз сыный, күпләрне – авыру белән... Коронавирус дигән афәт килеп кагылгач, бу һөнәр ияләренең кадере күзгә күренеп артты. Чөнки нәкъ менә алар көрәшнең иң алгы сызыгына басты, тәүлектәге сәгатьләр, үз саулыклары, хәтта гомерләре белән исәпләшмичә, кешеләргә ярдәмгә ашыкты. Чаллыда Азат Әдһәдович җитәкләгән 2 нче больница әлеге авыру килеп кагылганнарны дәвалаучы үзәккә әверелде. Андагы табибларның фидакарьлеге, «барысы да яхшы булачак» дип инандыруы «өмет нуры сүнгән кичләрдә йолдыз булып яна».

Азат Әдһәдович кебек табиблар, аның кебек якты кешеләр – авылның гына түгел, районның, шәһәрнең, алай гына да түгел, тулы бер милләтнең горурлыгы бит ул. Ул яктылыкка табиблар символы булган ак чәчәкләрнең аклыгы да кушылгач, бөтен тирә-якка җан җылысы тарала кебек.

...Җырның сүзләрен язганда күз алдымда ак халатлы, ак күңелле шушы табиб иде. Мин хәтта җырның көен дә ишеткәндәй булдым, колагымда салмак кына агылды да агылды ул... Озак та үтмәде, Миләүшә ханым җырның беренче вариантын яздырып та җибәрде, Вил Усманов көй язарга да өлгергән икән. Тыңлап карагач: «Язның 17 нче мизгеле» фильмындагы шикелле, салмаграк кына, бастырып кына бара торган итеп, бераз әкренәйтеп булмас микән», – дип, мин дә үз фикеремне җиткердем.

...«Казан егетләре» ансамбле һәм Зәринә Хәсәншина башкаруында «Ак чәчәкләр» җыры яңгыраганда, азнакайлылар да, чаллылар да горурланмый калмас, чөнки гап-гади җырның «төп герое» – шушы як гөлләреннән күңеленә аклык алып үскән, аклык алып яшәгән Мәндәй егете Азат Фәтхетдинов. Гомумән, бу җыр – ак чәчәкләргә тиң ак күңелле табибларга безнең рәхмәтебез.

Фото: Лайсән Хажиева

PRESSA



Зәңгәр шәһәр

Зәңгәр шәһәргә аяк баскач, беренче мәлдә югалып каласың, үз күзләреңә ышанмый торасың: бу чын түгелдер кебек. Әкияттер, йә булмаса төштер... Зәңгәр төснең нинди генә төсмере юк монда! Кала – тау итәгенә урнашкан, әлеге күренеш тә аңа үз матурлыгын өсти.

Раушания
ПОЛОСИНА-СӨЛӘЙМАНОВА



Марокколылар базарда шактый бәйләнчек: «Аны ал да, моны ал...» – диләр. Әмма бу ачуны чыгармый, тәэсирләргә яңа төсмер генә өсти.

Европаның иң көньяк ноктасында – Испаниянең Тарифа дигән шәһәрендә ял итеп ятабыз. Гибралтар бугазы аша көн саен каршыдагы Африка ярларын күзәтәбез. Анда – Шәрыкның бар матурлыгын, бар төсмерен үзенә туплаган Марокко. Ул шундый ымсындыра... Тарифа белән Танжера арасында бөтен уңайлыклары булган паромнар йөреп торуын белгәч, шунда ук хәл иттек: барабыз! Дусларыбыз Шефшауэнда – Зәңгәр шәһәрдә тукталырга киңәш бирделәр.

Юл күп вакытны алмады – бер сәгать тирәсе дигәндә каршы ярда идек инде. Миграция кәгазьләрен паромга кергәч кенә тутырдык: барысы да бик тиз булды – паспортларыбызга мөһерне дә шунда ук суктылар.

Автовокзалга кадәр җәяү генә тәпиләдек: бер рәттән Танжера шәһәрен дә бераз булса да күрәсе килә бит. Юл өстендә валюта алыштыру пунктына кереп чыктык – евроларыбызны дирһәмгә алыштырдык. Алдан әйтеп куйганнар иде инде: валюта алыштыру пунктлары барысы да хөкүмәтнеке һәм аларның һәммәсендә дә курс бертөрле. Чагыштырып, эзләп йөрисе юк – тыныч кына иң беренчесенә керәсең дә, күпме кирәк, шуның кадәр алыштырасың.

Марокконың төньягында юллар күбрәк таулар аша уза, шуңа күрә бездәге кебек зур автобуслар йөрми монда. Җиде урынлы зур булмаган автомобиль – иң киң таралган транспорт. Шунысы кызык – аларда теләсә кайсы машина җиде урынлыга әйләнә ала. Иске генә «Мерседес»ка кереп утырдык: мин – алгы утыргычка, ирем һәм дустыбыз – арткысына. Шофер кузгалып китәргә ашыкмады, алгы утыргычның – ике, арттагыларның – дүрт кешелек икәнен аңлатырга кереште. Алай икән... Өстәвенә, моның билет бәясенә бер катышы да юк булып чыкты: иркенләп утырсаң да яки банкага тыгызлап тутырган кильки балыгы кебек барсаң да шул ук хакны түлисең. Төшәргә ашыктык. Машиналарның икенчесенә – урыннар, чыннан да, җидәү булганына утырдык, үзебез исә тәрәзәдән теге автомобильне күзәтәбез. Юан гына биш хатын һәм бер ир-ат кереп утырды аңа. Ничектер сыйдылар! Җайлап утырып баруда гына түгел бит әле монда хикмәт. Әйткәнемчә, таулар аша барасы, йөртүчеләре куркуның ни икәнен белми, юлда бер кисәтү билгесе күренми... Өстәвенә, саклык каешын да эләктереп торма. Юк инде!



Зәңгәр шәһәргә кадәр өч сәгать барасы икән. Бөтен нәрсә белән кызыксынган турист өчен озак вакыт түгел ул. Тәрәзә артындагы күренешләр гел алышына. Юл буенда сатучылар күренеп кала: күбесе бакчага куя торган керамика әйберләр һәм җиләк сата.


Шәһәр нигә зәңгәр?

Шефшауэнга аяк басуга ук шәһәрнең иске өлешен – Мәдинәне эзләп киттек. XV гасырда нигез салына аңа. Испаниядән куылгач, мөселманнар һәм яһүдләрнең күбесе биредә килеп урнаша. Каланың архитектурасына шушы вакыйга бик нык тәэсир итә. Башта үзләренең йортларын яһүдләр генә зәңгәр төскә буйый: алар өчен бу – изге төс. Зәңгәр төс аларны күккә һәм Аллаһка якынайта дип саныйлар. Кайдан килгән ышанудыр бу, анысы билгесез. Аннан яһүдләр күчеп китә, ә монда яшәүче халык зәңгәргә буялган йортларның туристларга бик тә ошавын сизеп ала. Алар да, ашыгып, йортларын зәңгәргә буйый башлый. Йортларын гына да түгел! Баскычларны, капкаларны, хәтта юлларны! Бөтен нәрсәне!

Ничек адашмаска?

Без алдан ук maps.me кушымтасыннан регионның картасын күчереп алдык, һәм үзебезгә кирәк булган урыннарга тамга куеп чыктык: автостанциягә, Зәңгәр шәһәргә кергән җиргә... Кая кире борылып кай-

Зәңгәр шәһәр мәхәббәт талисманы дип санала: зәңгәр диварлар арасында гашыйкларның ярату сүзләре башкача яңгырыйдыр, мөгаен.



■ Иске шәһәр зур бер базарны хәтерләтә. Кайсы ягына күз төшерсәң дә – кемдер нәрсәдер сата. Кая карасаң да – сатулашу.



тырга телисең – шул урынны картада билгелисең һәм саклыйсың. Әйтик, дуслар белән бер сәгатьтән очрашырга сөйләштегез ди (көтү кебек гел бергә йөреп булмый бит), картада саклап куясыз икән, адашмыйча, берәүдән дә сорашмыйча шул урынга кире әйләнеп кайта аласыз. Ә монда адашу бик җиңел! Кайсы якка карасаң да – зәңгәр йорт та зәңгәр йорт.

Нәрсә сатып алырга?

Иске шәһәр – тоташ базар ул. Адым саен нидер саталар. Сувенирларның кайсына тотынсаң да шушы урынның рухы чагыла. Безнең каланың күркәм урыны дип әйтерлек урыннар Казандагы кебек бармак белән генә санарлык түгел монда. Йортларның теләсә кайсысын фотога төшер дә сувенир яса – Зәңгәр шәһәрне барыбер таныйсың. Шуңа күрә шәһәргә аяк басуга аның эченә кереп чумасың. Менә ул урынны, шул бинаны күрим әле дип эзләп йөреп мәшәкатьләнмәсәң дә була: күзең күргән, аягың атлаган якка барасың да барасың...

Кайда тукталырга?

Торак ягын баргач кына хәл итәрбез дип уйладык, шуңа да алдан бронь ясап маташмадык: апрель ае – туристлар күпләп йөри торган сезон түгел анда. Танжерадан Зәңгәр шәһәргә машинада бергә барган юлдашларыбыз французлар булып чыкты. Шефшауэнда бик еш булалар икән. Тукталырга менә дигән урыннарны беләбез, борчылмагыз, диделәр. Алар тәкъдим иткән аппартамент, чыннан да, искиткеч булып чыкты. Ә тәрәзәдән ачылган күренеш!.. Шуның өчен генә дә аерым акча түләрсең... Бүлмә җылы, залдагы каминны кабызырга кирәкмәячәк, ул матурлык өчен генә, диделәр. Иртәнге як иде әле бу, барысыннан да бик канәгать булып, шәһәр карарга чыгып киттек.

Кич арып-талып кайтып керсәк, бүлмәләр шактый салкын, дым тарткан. Җылы якларның бер үзенчәлеге инде бу – йортлары җылытылмый: өйгә кайткач киенеп кую алар өчен гадәти күренеш. Каминны кабызырга вәгъдә иттеләр, тик ул гына безне коткармаячак иде – йокы бүлмәсенә кадәр аның җылысы барыбер килеп җитмәячәк.

Җылы номерлы отель эзләп чыгып киттек. Әмма отельләрнең берсе дә җылытылмый булып чыкты. «Кондиционерны гына җылыга көйли алабыз», – диделәр. Дымлы урынҗиргә бу гына ярдәм итмәячәк иде, әлбәттә... Унлап отельне карап әйләнгәч, берсенә тукталырга булдык: тәрәзәләре урамга түгел, бары ишегалды ягына гына чыккан номерны сайладык. Өстә нинди кием бар, берсен дә салмыйча юрган астына кереп яттык һәм, ниһаять, йокыга талдык.

Ачы, әмма әйбәт тәҗрибә булды бу: моннан соң җылы якларга бары тик җылы вакытта гына барачакбыз.

Әмма шәһәрдән алган тәэсирләрне бу гына берничек тә боза алмады. Һәр отельнең үз матурлыгы монда. Персональ гаҗәеп итагатьле, хәер, шәрыкта башкача була да алмыйдыр. Иртәнге ашны бүлмәбезгә үк китерделәр. Ун төрле баллы һәм балсыз камыр ризыгы, бер термоста – каһвә, икенчесендә сөт... Барысы да искиткеч тәмле иде! Тик моның кадәрне ничек ашап бетерәсең?!

Нилләр карарга?

Алдарак әйттем инде: күзең төшкән кай тарафка китсәң дә карар әйбер җитәрлек монда. Адым саен туктыйсы, озаклап карап торасы, фотосурәткә төшерәсе килә. Шәһәр гүя катлы-катлы: алдагы борылышка җитәсең дә, күз алдында яңа, гел көтелмәгән күренеш ачыла... Бер карыйсың – монда бар да туристлар өчен генә кебек, ә икенче карыйсың – шәһәрдә чын тормыш кайный, ул үз дөньясы белән яши. Без хәтта ниндидер туй тамашасына да эләктек: кунаклар урам буйлап бара, үзләре җырлый. Күңелле!

Тар урамнардан барганда агач эшләре остасының остаханәсен күрергә мөмкин. Ярымподвалда гаҗәеп матур тукымалар тукып утыручылар да игътибарыгызны җәлеп итүе бар. Минем үземә гел тукучы ир-атлар гына очрады. Сатучылар да үзләре үк: мактый-мактый саталар да, туристлар артыннан ишек ябылуга кабат тукырга утыралар. Ул тукымалардан капюшонлы, зур кесәле бик матур кофталар тегәләр биредә.

Мавританиянең барлык шәһәрләрнең үзәк урыны – Әлкасаба. Илбашлары резиденциясе бу. Гадәттә, ул ныгытма белән әйләндереп алынган була. Шефшауэнның Әлкасабасы каланың башка урыннары кебек төсләргә бай түгел. Әмма җай чыкса, анда да сугылырга кирәк: беренчедән – парклары матур, икенчедән – манарасына менеп, шәһәргә башка ракурстан күз салырга мөмкин. (Онытканчы әйтим әле: Әлкасабага керү түләүле, әмма кыйммәт түгел.)

Шәһәргә югарыдан күз сала торган нокталар тагын бар әле: без аларны maps.me картасында таптык. Күбесе шәһәрдән читтә – тауларда. Анда менгәч ачылган манзараны күрсәгез!.. Тау сукмагыннан җәяү генә күтәреләсең, зур-зур ташлар арасыннан барасың, кактустан торган коймалар яныннан узасың, ишәк көтүен күрәсең...

Картада берничә шарлавык та күрсәтелгән. Аларның берсен дә зур дип булмый. Иске шәһәр читендә үк урнашканын без дә карап уздык: минем үземә шарлавыктан бигрәк, яр читендә келәм юган хатын-кызлар кызык тоелды. Андагы колорит! Андагы төсләр байлыгы!

Кайда ашарга?

Зәңгәр шәһәрдән туристлар өзелми, шуңа күрә монда утырып чәйләп алырлык кафелар адым саен: ул яктан борчылырга кирәкми. Менюлар да шактый бай! Кафелар иң күп булган урын – Әлкасаба һәм Зур мәчет алдындагы мәйданнар. Кайсыннан шәһәргә матуррак күренеш ачыла – кафеның шунысын сайларга булдык. Шефшауэндагы кайбер биналар Истанбулны, аның Босфор яр буен хәтерләтә: үзләре тар гына, әмма биекләр – биш-алты катлылары очрый. Хәтта йорт түбәсендәге верандалары да икешәр катлы.

Без кергән кафеның исеме «Аладдин» иде. Меню да күңелебезгә хуш килде, интерьер да ошады, тәрәзәдән ачылган шәһәр күренешләре турында әйтмим дә! Күңелегезгә ятып бетми икән, кереп утырып, менюны караганнан соң да кафедан кире борылып чыгып китәргә була. Моның бер куркынычы да юк. Заказ биреп өлгермәгән булсагыз инде, әлбәттә.

Мәчеләр турында

Мөселман илләренең барысында да мәчеләргә аерым мөнәсәбәт инде аларда. Юкка гына хайваннардан бары тик мәчегә генә мәчеткә керергә рөхсәт ителми бит. Истанбул мәчеләре, мәсәлән, бик кадер-хөрмәттә, ашаталар, алар өчен махсус йортлар ясыйлар. Алар анда бик иркәләр, сыңа сырпаланырга гына торалар. Мароккода да мәчеләр бик күп, ләкин кыргыйлар, кешедән, нигәдер, куркалар. Читтән генә фотосурәткә теләгән кадәр төшерә аласың, ә янларына килеп сыйпап булмый – шундук качалар.

Йомгак

Кеше бу урынга кабат әйләнеп кайтырга телиме-юкмы – туризмның уңышы турыдан-туры шушыңа бәйле. Шефшауэнны мин, һичшиксез, тагын бер барып күрер идем! Тик бер көн генә аз – кунарга калырга да кирәк. Төнге Зәңгәр шәһәрнең үз матурлыгы – әкияттәге кебек тылсымлы ул... Телефоныгызда яки фотоаппаратыгызда буш урын күп булсын – моны алдан ук кайгыртып куегыз: анда һәр адымыңны фотосурәткә төшерәсе килә. Туктап булмый! Берничә адым элек кенә фотога төшергән җирдән узып китеп артыңа борылып карауга, кулың кабат фотоаппаратка үрелә – ул йорт, ул урын инде бөтенләй башкача күренә! Гаҗәп!



■ Йортлар арасындагы тар юллар, гомумән, лабиринт кебек. Алар шундый тар – монда бары тик җәяүлеләр генә йөри ала.



Балалар үстергән вакытта әлеге диагноз белән һәрбер әни диярлек очрашадыр. Сабыйның бит алмалары алсуланып, янып тору менә шул диатез башлану билгесе булырга мөмкин. Баланың да, әти-әнинең дә тынычлыгын алучы, төн йокыларын калдыручы бу чир турында Республика балалар клиник хастаханәсенең Сәламәтлек үзәге мөдире, югары категорияле балалар табибы Гүзәл ЯРУЛЛИНА белән сөйләшәбез.

БАЛАДА ДИАТЕЗ

Диатез (аллергияле дерматит, ягъни баланың һәртөрле аллергик чирләргә бирешүчәнлеге) күп очракта бер яшькә кадәрге балаларда очрый. Бит алмалары кызарудан тыш, күп вакыт аның башка билгеләре күренми дә. Әмма кайчак ул тәннең башка өлешләрен дә зарарларга мөмкин. Кызарган урыннарда тән тиресе кубалаклана, кычыта. Баланың аппетиты начарлана, йокысы кача, ул көйсезләнә, елый...

Сәбәпләре:

• нәселдәнлек факторы һәм һәртөрле иммун чирләргә, тире авыруларына бирешүчәнлек;
• йөкле чакта әнисенең дарулар кабул итүе;
• әйләнә-тирәлекнең промышленность калдыклары белән пычрануы, һавадагы тузан һәм газлар;
• йокы режимын сакламау;
• балага өстәмә азыкны иртә бирә башлау;
• инфекцияләр, организмга бактерия һәм вируслар тәэсире;
• эчәклектәге микрофлораның бозылуы;
• имезүче әнинең диета тотмавы.

Диатезның билгеләре:

• бит алмалары кызару һәм кубалаклану;
• кайбер урыннарда тән тиресе юешләнеп тору;
• тәнгә чыккан таплар җете кызыл төскә кереп, вак-вак куыклар белән каплану;
• кычыну;
• авыз-борын эче ялкынсыну;
• баланың баш түбәсендә соргылт төстәге касмак барлыкка килү;
• аллерген белән контакттан соң, чабырган урыннарның бөтен тәнгә таралуы.

Ничек кисәтергә:

■ әлеге патологияне фәкать комплекслы гына дәвалап була. Диета һәм көндәлек режим бик мөһим;
■ балага сыер сөте бирмәскә. Коры смесьнең бер өлешен оетылган сөт ризыкларына алыштырырга;
■ катгый график белән генә ашатырга; рационын витаминнар белән баетырга;
■ майлы ит һәм майлы шулпалар, цитруслы җимешләр, банан, җир җиләге, бал, помидор, чикләвек, какао, шоколад, ысланган ризыклар бала рационында булырга тиеш түгел;
■ балага антигистамин дарулар, гормональ мазьлар билгеләнергә мөмкин.

Халык медицинасы киңәшләре:

■ тәннең чабыруын, кычытуын эт тигәнәге (череда), ала милүшә, ромашка, имән кайрысы төнәтмәләре кушып ясаган ванналар басарга булыша;
■ 10 г вакланган үләнгә 200 мл бүлмә температурасындагы кайнаган су салып, «су мунчасында» 15 минут төнәтергә, һәм 45 минут суыткannan соң, сөзәргә. Бала ваннасына 1 стакан төнәтмә салына. Имән кайрысын исә 20 г итеп алырга кирәк;
■ Үләннәрнең күбесе үзләре үк аллергия китереп чыгарырга мөмкин. Даруларда да аллергия кузгатучы компонентлар була.

БУ МӨҺИМ: табиб белән киңәшләшмичә сабый балага дарулар бирергә һәм хәтта үлән төнәтмәләре дә кулланырга ярамый!

ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



ИГЪТИБАР!

■ Бала киеме бары тик табигый тукымалардан гына булсын.

■ Баланың кием-салымын махсус порошок яки балалар сабыны белән генә юарга һәм үтүкләргә.
■ Бала үскән йортта йорт хайваннары булмасын.

■ Балага йөнтәс йомшак уенчыклар бирмәгез. Калган уенчыкларның да сыйфат сертификаты булырга тиеш.

■ Бала үскән бүлмәнең тузаннарын көн дә сөртергә, идәнен ешрак юарга кирәк.
■ Бүлмәдәге тузан чыганакларын: келәмнәрне, калын пәрдәләрне, китапларны, ачык шкафтагы кием-салымны, кресло, диваннарны чыгарып торыгыз.

Фото: www.pixabay.com





Исеме колакка ят яңгыраса да, әлеге диагноз белән хатын-кызлар шактый еш очраша. Бигрәк тә яшьләрне аямый ул. Кубесенчә нәкъ менә хатын-кызларга янаучы нинди чир бу һәм аны ничек дәваларга? Республика клиник хастаханәсенең неврология бүлеге мөдире Марат ХӘЙРУЛЛОВ белән шул хакта сөйләшәбез.

МОРТОН НЕВРОМАСЫ

Нервтагы барлыкка килгән шешләрне медицина телендә неврома дип атыйлар. Әмма Мортон невромасы шеш түгел, ә табан астындагы нервның билгеле бер урында калынаюы. Аяк бармаклары төбендәге нерв зарарлана, ул шешә, тышчасы калыная һәм табанга басканда бик көчле авырту сизелә. 3 нче һәм 4 нче аяк бармаклары арасыннан узучы нервның күп тапкырлар микротравма алуы, җәрәхәтләнүе чирне кузгатып җибәрүче фактор булып санала.

Баштагы стадиядә невроманы кул белән баскалап кына ачыклап булмый. Ул үзен бары тик тар һәм җайсыз аяк киеме кигәч кенә сиздерә. Аяк киемен салгач, табан астының сызлавы басыла. Әмма нервның зарарлануы алга таба да игътибарсыз калса, сызлану даимигә әверелә, йөргәндә генә түгел, хәтта ятып торганда да табан асты бик нык авырта. Дөрес диагнозны бары тик табиб кына куя, дәвалау чараларын да ул билгели. Диагнозны раслау өчен рентгеноскопия яисә компьютер томографы билгеләнергә мөмкин. Болар невроманың булу-булмавын күрсәтми, сөякләрнең бөтенлеген ачыкларга ярдәм итә. Шулай ук УЗИ билгеләүләре дә ихтимал.

Сәбәпләре:
- аяк киемен дөрес сайламау – артык биек үкчә, тар башлы кысан туфли, аяк киеменең размеры туры килмәү;
- ялкынсыну патологиясе;
- аркылы яссы табанлылык;
- йөргәндә табанны эчкә таба бору;
- организмда инфекцион яки аутоиммун чирләр булу;
- аякларда атеросклероз;
- кан тамырларының кысылуы;
- нерв үткән урында сөякләрнең сынуы яки гематома барлыкка килү;
- артык авырлык һәм аягөсте күп йөрү;
- табанның алгы өлешенә көч китереп йөгерү.

Билгеләре:
- аяклардагы бармак төпләрендә авырту, кызышу, бармаклар ою;
- аяк табанын кысканда кискен авырту барлыкка килү;
- йөргәндә уңайсызлык тою;
- аяк киемендә таш булгандай тоелу;
- биек үкчәле аяк киеме кигәндә табан астының сызлавы, салгач, авыртуның юкка чыгуы.

Киңәш:
- дәвалану процессының беренче мөһим этабы – аяк киемен уңайлыга алыштыру.
- Аяк бармаклары арасына аергыч кую.
- Яссы табанлылык күзәтелсә, ортопедик аяк киеме куллану.
- Аягөсте булуны чикләү.
- Табан астына җиңелчә массаж ясау (аяк бармаклары белән кечкенә туп тәгәрәтергә мөмкин).
- Табиб киңәше белән аякны ромашка төнәтмәсе кушылган җылы суга тыгып тору.
- Авырту бик көчле булса, табиб авыртуны һәм ялкынсынуны басучы препаратлар билгеләргә мөмкин.

Ничек булдырмый калырга?
- Аякка көч китерүдән сакланырга.
- Аяк киемен дөрес сайларга.
- Яссы табанлылыкны кисәтү өчен махсус күнегүләр башкарырга.
- Гәүдә авырлыгын нормада тотарга.
- Организмдагы ялкынсыну процессларын вакытында дәваларга.
- Спортның травмага китерә торган төрләре белән шөгыльләнмәскә.
- Кечкенә генә имгәнүләрне дә игътибарсыз калдырмаска.



Халык медицинасы киңәшләре:
- әрем үләне белән компресс. Ул табан астындагы ялкынсынуларны басарга ярдәм итә. Яңа өзгән әрем яфракларын төеп, авырткан урынга ябарга һәм киҗе-мамык тукыма белән бәйләп куярга. Моны ятар алдыннан эшләсәң яхшырак.
- Әрекмән тамыры төнәтмәсе белән компресс. Ике аш кашыгы вакланган тамырга 2 литр кайнар су агызып, 5 минут сүрән утта төнәтәсе. Киҗе-мамык тукыманы шушы төнәтмәдә чылатып, аяк табанына компресс ясарга.
- Кәбестә яфрагы белән компресс. Кәбестәнең яңа өзгән яфрагын йомшарганчы уып, аяк табанының авырткан урынына бәйләп куярга.

БУ МӨҺИМ: аякта ачык яра, үлекле җәрәхәтләр булса, компресс куярга ярамый. Алдан табиб белән киңәшләшегез!



Республика клиник хастаханәсенең җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча әйдәп баручы белгече Валерия Белова ярдәмендә әзерләнде.



Меренгалы рулет



Шундый тәмле, кетердәп авызда эрегән, аз гына чикләвек һәм җиләк тәме килеп торган меренгалы рулет. Карап торырга шактый катлаулы, әмма һәрбер уңган хуҗабикәнең кулыннан килерлек тәмле француз десерты. Аны һәркем ярата, ул – иң популяр тәм-томнар рәтендә. Аш-су остасы Ландыш СӘЛИХҖАНОВА «Сөембикә» укучылары өчен бүген бу десертны әзерләп күрсәтер. Ул үзе аны беренче тапкыр бер ел элек әзерләп карый һәм интернетта язылган рецептта нәрсәдер туры килмәгәнне аңлый. Үзенчә үзгәртеп, камилләштереп, яңадан яза ул аны. Чөнки Ландыш – азык-төлек өлкәсен әйбәт белгән инженер-технолог, аңа ышанырга була! Үзенчәлекле бу рецептын безгә дә тәкъдим итә. Әзерләп карыйбызмы?

Кирәк

Меренга өчен:

- 5 йомырка агы (170 г);
- 260 г шикәр пудрасы;
- 1 чәй кашыгы аш серкәсе (уксус);
- 1 чәй кашыгы лимон кислотасы;
- 20 г кукуруз крахмалы.

Эчлек өчен:

- 300 г эремчекле сыр;
- 200 г сөт өсте (сливки);
- 50 г шикәр комы;
- 200 г җиләк.
- 70–80 г шикәр пудрасы;





Фото: Анна Арахамия

Эш барышы

■ Йомырка агын савытка салып, 3–4 минут блендер белән туглыйбыз (туглау процессы ахыргача өзелергә тиеш түгел).

■ Йомырка агы күбекләнә башлагач, аңа лимон кислотасы һәм кашыклап шикәр пудрасын салып, блендерда 8–10 минут туглыйбыз. Бу вакытка ул шактый куера.

■ Башта уксус, аннан кукуруз крахмалы кушып, тагын 2–3 минут туглап алабыз. Рулетның нигезе – меренга шуның белән әзер.

■ Меренганы пергамент кәгазь җәелгән табага 1,5–2 см калынлыгында тигезләп җәябез. (Өслекнең тигез булуы бик мөһим.)

■ Өстенә вакланган чикләвек сибәбез. (Чикләвекне теләгән кеше генә куллана ала, рецепт буенча аның булу-булмавы әһәмиятле түгел.)

■ 160 градуска кадәр җылытылган мичкә 30 минутка куябыз. Ул арада эчлек өчен крем ясый торабыз.

Эчлек өчен

■ Эремчекле йомшак сырны, таралып китсен өчен, башта үзен генә 1–2 минут, аннары шикәр пудрасы, соңрак сөт өсте кушып, 5–6 минут блендер белән туглыйбыз. (Шикәр пудрасы һәркемнең баллыны ничек яратуына карап кушыла.)

■ Әгәр дә рулеттан пешергәч үк авыз итәргә телисез икән, ул очракта җиләкләрне вак телемнәргә кисеп кенә дә тезәргә була.

■ Эчлекне әзерләүнең икенче варианты да бар. Моның өчен җиләкләрне талгын утка куеп, азрак пешереп алабыз. Кайный башлагач, шикәр комы өстибез. Кайнатмабыз куерып китсен өчен, алдан аз гына суга салып болгатылган крахмалны кушабыз, үтә күренмәле төскә кергәч, уттан алабыз һәм суынырга куябыз. Җиләкле кайнатманы эш башланганчы ук ясап куйсаң уңайлы.

■ Ярты сәгатьтән мичтәге меренганы алабыз һәм җайлап кына тактага күчереп, суынганын көтәбез.

■ Суына төшкәч, чикләвекле ягы тышка карап калсын өчен, меренганың астын өскә әйләндерәбез.

■ Рулетыбыз хуш исле булсын өчен, өслеккә җиләк кайнатмасын ягабыз.

■ Өстенә рәсемдә күренгәнчә крем сөртәбез. (Кашык белән сөртергә дә ярый.) Крем өстенә берничә буй җиләк яки җиләк кайнатмасын салабыз.

■ Рулетны төрү – иң җаваплы мизгел. Кәгазьне әйләндерә барып, тиз-тиз төрергә кирәк. Рулет әзер булгач, аның өстен үзебез теләгәнчә бизибез һәм 50–60 минутка суыткычка куябыз.

Рулетлы чәйләрегез тәмле булсын!



PRESSA

Сусыл витамин

Кура җиләгенең салкын тигәннән файдасы булуын, инфекцияләргә каршы торучанлыкны арттыруын беләбез. Кайнаткан вакытта күп җиләк-җимешнең витаминнары таркалып, файдалы үзлекләре кимесә, кура җиләгенеке – киресенчә, кайнатмасы хәтта файдалырак та. Бу җиләкнең без белмәгән тагын әллә никадәр сыйфаты бар әле.

■ Аскорбиннан тыш, кура җиләге А витаминына бай. Йөрәк-кан тамырлары чирләреннән, яман шештән саклый, организмның картаюын тоткарлый. PP витамины йончуны бетерә, йокысызлыкны җиңәргә булыша, аппетитны яхшырта, тән тиресен шомарта һәм нәфисләндерә. Е витамины исә яшәртүче кремнарның төп компоненты. B_2 витамины да матурлык витамины – битне чистарта, чәчләрнең шомалыгы, куелыгы, ялтыравы өчен җавап бирә.

■ Артык авырлыгы булганнарга да бу җиләк белән дуслашырга кирәк. Ул ашказаны эшчәнлеген көйли, гастритны дәваларга булыша, яфракларыннан ясалган төнәтмә ашказаны эшләмәгәндә шифа бирә. Моның өчен дүрт чәй кашыгы җиләк яфрагын 400 мл кайнар суда төнәтеп, көненә дүрт тапкыр яртышар стакан күләмендә кулланалар.

■ Кура җиләге – менә дигән бәвел кудыргыч та. Күз төпләрендәге шешенкелектән, аякларның шешенүеннән арынырга булыша.

■ Кәефегез төшсә дә, кура җиләгеннән авыз итегез. Бакырга бай булуы аның депрессияләргә, стрессларга каршы тору үзлеген көчәйтә.

ДӨРЕС ТУКЛАНУЧЫЛАР ӨЧЕН

Җиләкле-алмалы крамбл

100 г солы лачавы (озак әзерләнә торганы), 40–50 г чистартылмаган бөртектән тарттырылган он (кокос яки миндаль оны булса, тагын да яхшы), 200 г алма, 100 г кура җиләге, 40 г атланмай (чикләвек пастасына яисә үсемлек маена алыштырырга мөмкин), 20–30 г бал, ярты чәй кашыгы дарчин (корица), 1 чәй кашыгы крахмал.

Мичне 180 градуска куеп, крамбл өчен әчлек әзерлибез. Җиләкне юып, урталай бүләбез. Алманы чистартып, вак шакмаклап турыйбыз. Туралган җиләк һәм алманы формага яисә таба төбенә салабыз. Өстенә крахмал сибәбез. Бер савытта – солы лачавы, он һәм дарчинны, икенчесендә бал белән майны катнаштырабыз. Баллы-майлы катнашманы солы лачавына кушып, яхшылап туглыйбыз. Дымлы-валчыклы камырны туралган җиләкләр өстенә тигезләп җәябез. Крамбл 180 градуслы мичтә 25 минут чамасы пешә. Аны табынга бер йомарлам туңдырма яисә табигый йогырт белән бирергә мөмкин.

Җиләкле-үләнле смузи

Ярты стакан җиләк, үзегез яраткан үләннәр, 1 аш кашыгы җитен һәм 1 аш кашыгы көнҗет орлыгы кирәк. Үләнне эре итеп турыйбыз, җитен орлыгын кофетарткычта ваклыйбыз. Блендерга җиләк белән туралган үләнне, орлыкларны, 2 аш кашыгы су салып, 5–7 минут яхшылап туглыйбыз. Баллырак яратсагыз, бал да өсти аласыз. Смузи әзер! Тәмле булсын!

Серле кайнатма

Кура җиләге үзенең яшәртүче, организмны ныгытучы үзлекләрен җуймасын өчен, кайнатма әзерлисе ширбәткә чирек стакан гына чөгендер суы салалар. Чөгендер суын кызыл карлыган сутына алыштырырга мөмкин. Кайнатманың төсе дә матуррак була, җиләктәге минераллар һәм витаминнар да яхшырак саклана.



Фото: www.pixabay.com

Кучкар. Үзегезгә ял бирмәсәгез, финанс һәм эш проблемаларының шактый катлауланып китүе бар. Шуңа күрә мөмкин кадәр ял итәргә тырышыгыз, табигатькә чыгыгыз, кино карагыз, тәмле итеп туклаНЫГЫЗ.

Үгезбозау. Оригиналь фикерләү һәм активлык көтелә сездән! Шул чакта гына тормышыгызга яңа үзгәрешләр, танышулар үтеп керә алачак. Якын киләчәкне планлаштыра торган вакытыгыз бу.

Игезәкләр. Вакытыгызны, көчегезне якыннарыгызга, гаиләгезгә багышлау чоры. Лидерлык сыйфатларын сыный торган чак. Үзегезне кайгыртырга да онытмагыз. Җәй кояшының шифасын тоеп калыгыз.

Кысла. Тормышыгыз акча энергиясе белән тула торган чор. Сатып алулар турында түгел, акча туплау турында уйларга тырышыгыз. Башкалар белән аралашканда басым ясамыйча гына уртак фикергә килү сорала.

Арыслан. Бу айны йолдызлы сәгатегез дип кабул итегез. Һәркайда уңыш елмаер, үзегезне тәхеттә утыргандай хис итәрсез. Онытмагыз, иң мөһиме – дөрес уйлар дулкынында булу.

Кыз. Ирешкән уңышларга рәхмәтле була белегез. Ашыгырга, беренче планга чыгарга омтылмагыз. Бу айда сезнең төп бурыч – тынычлык саклау. Үзегезне аңлау, киләчәккә планнар кора торган вакыт.

Үлчәү. Эш энергиягез артып китәр. Дәртләнеп, яңа эшләргә, проектларга алыну уңыш китерер. Тирә-юньдәгеләр белән аралашканда акыл өстенлек итсен, хисләргә юл куярга иртәрәк әле.

Чаян. Йолдызлар уңыш һәм карьера вәгъдә итә. Җитәкчелек тырышлыгыгызны бәяләми калмас. Карьера баскычында алга атларсыз. Сәләтләрегезне чынга ашыру юлларын уйлагыз.

Укчы. Сәяхәтләр һәм фәлсәфи уйлар чоры. Һәрвакыт информациягә, белемгә омтылырсыз. Игътибарыгызны гаиләгә, якыннарга юнәлтегез. Матур үзгәрешләр көтелә.

Кәҗәмөгез. Бу ай төрле акча мәсьәләләре белән бәйле булыр. Хезмәт хакы арту, премияләр, бүләкләүләр... Сәяхәт планлаштырсагыз да була. Кояш җылысы һәркемгә файдалы вакыт.

Сукояр. Мәхәббәт һәм дуслык ае. Күп сорауларга җаваплар табылыр, гаилә кору өчен дә сезнең өчен уңай вакыт. Тирә-юнь белән уртак тел табарга тырышыгыз.

Балык. Эшне һәм сәламәтлекне кайгыртуга багышлый торган ай. Һөнәри тәҗрибәгез үсәр. Үзегезне кайгыртыгыз. Ял итеп, җәйнең соңгы аеннан ләззәт алып калырга тырышыгыз.

СЕЗ НИНДИ ӘҢГӘМӘДӘШ?

Сорауларга «әйе» яки «юк» дип җавап бирегез

1. Башка кешеләрне кабатлау бик авыр дип уйлыйм.

2. Тирә-яктагыларның игътибарын җәлеп итәр өчен теләсә нинди юләрлекләр эшләргә дә ризамын.

3. Миннән әйбәт актер чыгар иде.

4. Минем турыда, бөтен нәрсәне йөрәгенә якын алып, артык борчыла дип уйлыйлар. Чынлыкта бу алай түгел.

5. Аралашканда мин бик сирәк игътибар үзәгендә булам.

6. Төрле ситуациядә, төрле кешеләр янында үземне һәрвакыт төрлечә тотам.

7. Үзем бик ышанган әйберләрне генә чын күңелдән яклый алам.

8. Эштә, дуслар белән мөнәсәбәттә уңышка ирешер өчен, мине нинди итеп күрергә телиләр – шундый булырга тырышам.

9. Үзем яратмаган кешеләр белән дә дус булып йөри алам.

10. Мин ничек бар – шулаймын.

Ә хәзер балларны саныйбыз.

1, 5, 7 нче сорауларына «юк» җавабы өчен берәр балл куегыз.

2, 3, 4, 6, 8, 9, 10 нчы сорауларына «әйе» җавабы өчен берәр балл языгыз һәм балларның суммасын карагыз.

Нәтиҗәләр:

0–3 балл – гамәлләрегез тотрыклы, ситуациягә җайлашып, үзегезне кайчан ничек тотарга кирәклеген әйбәт беләсез. Аралашканда, ихластан ачылып, әңгәмә кора аласыз. Кайберәүләр сезне аралашу өчен «уңайсыз» кеше дип саный. Бу – турысын әйтә белүегез белән бәйле ризасызлык.

4–6 балл – сез – ихлас кеше, әмма эмоцияләрегезне тышка чыгармаска тырышасыз. Башкалар белән аралашканда әңгәмәдәшегезне ишетә өйрәнергә, читтән ничек күренүегезне дөрес күзалларга өйрәнергә кирәк.

7–10 балл – Дөрес мөнәсәбәтләр урнаштыра белүегезне үзегез дә яхшы беләсез. Теләсә нинди рольгә кереп, ситуация кайсы якка үзгәрүгә карап, аңа җиңел генә җайлаша аласыз. Хәтта әңгәмәдәшегездә нинди тәэсир калдырасыгызны да алдан сизеп тору сәләтенә ия сез.

тест

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Раилә ХӘЯЛИЕВА, Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.







ХИССИЯТЛЕ СУРӘТЛӘР

Новосибирск архитектура-сәнгать академиясендә рәссам-монументалист дипломы алганнан соң, Руслан Ибраһимов Нефтеюганск шәһәрендә бер-ничә ел гына иҗат итә дә Татарстан башкаласына килеп урнаша. «Зарыгып кайтуымның сәбәбе – кан тарту», – ди ул.

Рәссамның хиссиятле сурәтләр ясау рәвеше яңа юнәлеш түгел, Руслан да үз иҗаты өчен шушы алымны сайлап алган. Аны үзенчә – «чәчрәвекләр белән ясау» ысулы дип атый. Башта киндергә кирәкле фон, ягъни кылкаләм белән төсле буяу чәчрәвекләре ясала, шуннан соң гына күренеш яисә кеше образы пәйда була башлый. «Иң төп тойгылар-ны тапкач, иҗади дәрт белән эшкә керешәм, әсәр-ләрем тиз языла», – ди портретлар остасы. Аның бу аңлатмасына шуны өстик: аларны шулкадәр дә җан-лы һәм җылы итеп, күңел күтәренкелеге хисенә төреп бары Руслан Ибраһимов кына яза бүген башкалада!

«Хатын-кыз сурәтләрендә экспрессив штрихларны ешрак кулланам, чөнки аларның күбесе төрле хисләр өермәсендә, – ди ул. – Мин – профессиональ рәссам, кешеләрне яисә шәһәр күренешләрен башкалардан үзгәрәк күзалларга тиеш. Күңелдә туган картина... киндергә язылганы белән чагыштырганда һәрчак күпкә яхшырак!» Аның киндергә күчкән хисләре дә картинасындагы ауган кәрзиннән коелган җиләкләргә тиң! Хисләр байлыгын шәһәр күренешенә дә мулдан өсти ул! «Мине динамика, экспрессия, хәрәкәт эффек-ты илһамландыра! Портретлардагы күз карашында да күңел хисләре чагылырга тиеш!» – ди Руслан Әлим улы. Аның шушы кагыйдәләргә таянып иҗат итүе «Ышаныч. Өмет. Футбол», «Алга! Спорт легендалары» кебек бик уңышлы шәхси күргәзмәләрен ачарга да булышты инде. Спортта да чемпионнар әнә шундый эмоциональ кичерешләр югарылыгында була бит!

Рәссамның Казан архитектурасына булган мәхәббәте шактый әсәрләре аша расланды, Татар-станның иң булдыклы шәхесләренә багышланган портретлар рәте дә тулылана бара.


Әйтик, Русланның тагын бер уңышлы эше – «Вафирә» кинофильмы өчен махсус иҗат ителгән җырчы Вафирә Гыйззәтуллина сурәте дә зур осталык белән языла. Ә киләчәктә иҗатын яңа кинофильмнар төшерү өлкәсенә багышларга җыена ул. Һәм менә Галимҗан Ибраһимовның «Алмачуар» әсәре буенча куелачак фильмга рәссам итеп тә билгеләнгән инде. Буш вакыты табылганда рәссам Нурихан Фәттахның тарихи романнарын укый, шуларга иллюстрацияләр ясый.

«Себердә үстем, әмма бар да үзгәрә, хәзер инде әти-әнием дә Баулы районының Кече Урыссу авылы-на кайтып төпләнде, энем Рамил – галим, физик, ул да Казанны үз итте. Бүгенге көндә бары тик татар телендә генә сөйләшүемә сөенәм!» – ди Руслан.


Иң сөйкемле, иң нәфис, иң уңган, иң камил, иң зирәк... Руслан Ибраһимов әнә шундый татар кызларының гомуми милли образларын да тудыра әле.


«Хезмәт кешеләре». Аның бу яңа сериясе дә эшче һөнәрләр буенча Бөтендөнья чемпионаты вакытын-да һәм аннан соң да шәхси күргәзмәләре кысала-рында тамашачыларга тәкъдим ителеп, аларның бар игътибарын үзенә җәлеп итеп, рәссамга зур иҗади уңыш китерде!


Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА














РУСЛАН ИБРАҺИМОВ

Фото: Зөләйха Камалова

ТАССР

Празднование 100-летия
Татарской АССР

Татарстан АССР төзелүнең
100 еллыгын бәйрәм итү

1920-2020



Фердинат ДӘҮЛӘТШИН,
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
башлыгы

Чирмешәндә – печән өсте, тургайлар сайрый. Чирмешәндә – җәй уртасы, җиләкләр пешә. Чирмешәндә – уттай кызу эш өсте, уракка төшәргә әзерләнәләр... Авыл мәңгелек матур мәшәкатьләре белән яши бездә шулай.

Ә быелгы ел тагын да үзенчәлеклерәк. ТАССР төзелүнең 100 еллыгына зур эшләр, матур башлангычлар белән килгән булсак, тиздән районыбыз оешуның 90 еллык бәйрәмен лаеклы каршыларга әзерләнәбез. Ерак 1930 елның көзендә Беренче Май районы булып оешкан Чирмешән төбәгенең, авылларының горурланырлык шанлы тарихы бар! Татарстанның иң көньягында, Самара чигендә урнашкан Чирмешән җире Габдрахман Утыз Имәни, тамырлары Лашманга барып тоташкан Гаяз Исхакый кебек бөек шәхесләре белән горурлана. Районда татарлар, руслар, чуашлар, мордвалар тату бер гаилә булып көн күрә. Уңган-булган Чирмешән халкын әллә каян танып була: алар туры сүзле дә, киң күңелле дә, зирәк тә, ихлас та. Безнең якларга юлы төшкән һәркемне Чирмешән туграсы, Чирмешән әләме сәламли. Туградагы дивар – ышаныч, ныклык, мөстәкыйльлек символы. Ябалак – уяулыкны, алдан күрә белүчәнлекне, акыллылыкны аңлата. Әләмебездә сурәтләнгән ачык капка да хикмәтле: җирле халыкның кунакчыллыгын, яхшылыгын белдерә ул. Геральдикадагы көмеш төсе исә затлылык билгесе. Бездә менә шундый сыйфатларга ия халык яши!

